*Рифә Рахман*

# Айлы күлдәвекләр

**Хикәяләр һәм кыйссалар**

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2006

УДК 821.512.145-3
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Р28

**Рахман Р.Ф.**

Айлы күлдәвекләр: Хикәяләр һәм кыйссалар / Рифә Рахман. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 190 б.

ISBN 5-298-03976-6

Әдәбият сөючеләргә мәхәббәт темасын үзенчәлекле яктыртучы шагыйрә буларак таныш Рифә Рахманның прозасына да шигърилек, аһәңле яңгыраш, отышлы әдәби детальләр, кызыклы күзәтүләр хас.

Китапка тупланган әсәрләрнең күпчелеге — үсмерләр, яшь гаиләләр тормышына багышланган хикәяләр, кыйссалар һәм җитмешенче-сиксәненче елларда барган реаль вакыйгаларны авторның иҗади хыялы белән кушып яктырталар, шунлыктан аларда яшьлек романтикасына, мәхәббәткә урын мул бирелгән.

ISBN 5-298-03976-6
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Рахман Р.Ф., 2006

## ХИКӘЯЛӘР

### Адашкан җан

— Үз гомеремдә нинди генә күзләр белән очрашканым булмады, — дип дәвам итте сүзен яңа танышым. — Нинди генә күзләр белән һәм нинди генә халәттә...

Менә синең белән җиде төн уртасында ялгызың яшәгән фатирда чәй эчеп утырабыз…

Әфлисун төсендәге мамык тәлгәшләре төшерелгән үзбәк пыяласы* аның уч төпләрендә боргаланудан туктап калды.

— Курыккангамы, кара күзләреңне яшерергә тырышасың... Ә бит мин бу күзләргә, үзең теләгәндә дә, кагыла алмас идем. Алдый белмәгән, адаша белмәгән күзләрдән куркам мин.

Кунагымның сул битендәге кара тап җыерылып, бөрешеп кала. Калын кашлары урынына кайта. Зур кара күзләре кебек чәч бөдрәләре бер-берсенә сыенышалар. Әллә туңа, әллә...

Җирән үзбәк пыяласында зарыккан һинд чәе аның күкләр күкрәгән тавыш белән сөйләшүче тамак төбенә ыргыла.

— Гомерем буе зәңгәр күзлеләргә, сары чәчлеләргә гашыйк булып яшәдем мин... Беләсең килсә, син минем хыялдагы мәгъшукаларга һич тә туры килмисең. Теләсәң дә, сөяркә дә итә алмас идем. Алдый белмәгән күзләрдән куркам мин.

— Алайса...

— Ник ишегемә кактың, дисеңме? Ни өчендер миннән шүрләгән күзләрең белән генә чыга алырмындыр кебек бу төнне.

Сары чәчле, сыек төстәге күзлеләрне яулау ир-ат өчен берни түгел. Чын-чынлап әсир итәләр, җиңел генә синеке булалар һәм сине өрфия томанга төреп яшәтәләр. Мин үз өемнән еракта да кап-кара күзле ха-

тынымның, кайсы тәрәзә төбенә утырып, мине нинди уйлар белән көткәненә кадәр белеп торам, ә көн дә очрашкан сөяркәмнең кайсы, ничәнче ир-атка ишек ачканын әйтә алмыйм.

Сеңлем, булдыра алсаң, күзләремә туры кара! Сөйләгәннәремә кырыс хөкем көтәм мин алардан.

Ерак Себер авылларында концерт куеп йөргән чак. Көннәр буе талгын елгаларда коенабыз. Җиләкнең ниндие генә юк! Кеше аягы басмаган бу як табигате тәмам әсир итте. Кайтасы көнне ничек тә сузасы килә, үз белдегебез белән маршрутларны озынайтабыз, үзгәртәбез. Шулай йөри торгач, әллә Киндеркүл, әллә башкачарак исемле зуррак кына бер авылга килеп чыктык без.

Вак борчулар белән көн үтте. Кич җитте. Инде программа шомарган. Кабатлаулар кирәкми. Әллә Казаннан ерак булганга, үзебезне көндезен дә, сәхнә артында да, төннәрен дә шактый иркен тотабыз — тамырлар киңәеп, каннар кайнарланып киткән кебек...

Бу концерт көтмәгәнчәрәк башланды. Миннән алда чыгыш ясыйсы иптәшебез, уйламаганда-нитмәгәндә, җир убылган төсле юк булды. Мине сәхнәгә ашыктырып, эткәләп-төрткәләп чыгардылар.

Җәйли дә генә печән чапмадым,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Бөрлегәннәр өзеп капмадым.
Бик күп сөйдем, җаным, күпне күрдем,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Синнән матурны мин тапмадым.

Аның бөркеттәй тавышы, чәчләремне аралап, муен чокырын йомшак кына сыйпап үтте дә, юка кофтамны санга да сукмыйча, тиргә баткан аркамнан көчле ирләр кулыдай кысып алгандай булды. Мин шушы җыр иясенең күзләренә терәлдем дә каттым. Тын алырга куркып, җырның азагын көттем.

Карлыганнан кара кашларың,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Бөрлегәннән кызыл йөзләрең.
Шикәрләрдән тәмле, балдан татлы,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең.

Күңелне әйтеп бетермәслек шом, ниндидер хәвеф басты. Җыры, көе, сүзе, сүзләренә салынып бетмәгән мәгънәләре дә миңа багышлангандай тоелып, серләр чолганышында калдым.

Ә ул, һаман да әфлисун чәчәкле үзбәк пыяласын кулларында уйнаткан килеш, җырның өченче куплетын башлады. Мин дә янәдән калын гәүдәле, калын тавышлы, инде олыгаеп барган бу ирнең үзеннән дә картрак күзләренә төбәлдем.

Бара гына торгач юл буйлап,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Юл гынаем китте су буйлап.
Уйсыз гына егет түгел идем,
Мәдинәкәй, гөлкәй, бөдрә чәч,
Уй гынаем бетте, сине уйлап.

— Моңга сусаган халык мине дәррәү алкышларга күмде, — дип дәвам итте сүзен кунагым. — Алдагы уң рәткә утырган зәп-зәңгәр күлмәкле кыз гына миңа рәхмәт әйтергә ашыкмый иде. Шомырт кара күзләрен миңа текәгән дә мәрткә киткән кебек кымшанмый тора.

Алардагы сагышның тирәнлеге, хисләренең миңа гына төбәлгәнлеге! Төн урталарында шул карашны тоеп уянып китәм дә шыбыр тиргә батам. Ничә тапкыр, үземне белештерми, шәһәрнең таш урамнары буйлап чыгып йөгергән бар. Җырдагы юлларга чыгып йөгергән...

Мин ул күзләрне һәр сәхнәдән, дөньяның һәрбер почмагыннан эзлим. Эзләмәсәм, үзләре табып алырлар да: «Юл гынаем китте су буйлап...» — дип елап җибәрерләр шикелле. Хәер, ул җырны әле шуннан соң җырлаган да юк иде.

Нигә җырларга уйладың, дисеңме? Ул күзләрне бүген синең йөзләреңдә таптым. Беркемнән дә шүрләмим дигәндә, качар урын эзләгән кара күзләреңнең алдый белмәгәнен күрдем. Теләсәң дә, аларга кагыла алмасымны аңлатасым килде.

Шул кечтә сәхнә артында миңа кош теле кадәр генә язу кисәге тоттырдылар. «Мин Сезне басу капкасы янында көтәм. Мәдинә». Шунда ук минем күз алдыма зәп-зәңгәр күлмәкле кыз килеп баса. Клуб мөдиренә:

— Кем ул? Күрсәт! — дип, куанычымнан кычкырып җибәргәнемне дә сизми калам.

Ул, мыек төпләренә аңлаешсыз бер елмаю җәеп, әлеге кызга күрсәтә һәм колагыма:

— Вакланып маташма. Турыдан бәр. Түгәрәктә йөри торган бернәрсә шунда... — дип, серле пышылдап та өлгерә.

Бу сүз кайнар тәнгә салкын су сипкән кебек тәэсир итсә дә, сиздермим. Эчемнән, гөнаһлану кемнән калмаган да, без кемнән ким, дип куям.

Мәдинә мине кешеләр ялгыз калдырган клуб ишеге төбендә үк көтә. Басу капкасына без бергә атлыйбыз. Аны үзем генә таба да алмас идем, ахрысы. Әллә нинди бормалы урамнар буйлап барабыз да барабыз.

— Сез мине адаштырмакчы бугай, — дигән булам.

Мәдинә янәшәсендә бару рәхәт. Серле. Ымсындыргыч.

— Юк ла. Менә болынлыктагы күлне генә күрсәтәм дә. Анда шундый матур урыннар бар! Кечке якта, айга карап, суга аягымны салындырып утырырга яратам мин. Күңелгә төрле җырлар килә. Сезнең матур тавышыгызны ишеттем дә күрсәтәсе, сөендерәсе килде. Ә чыны... Ошаттым мин Сезне!

Мәдинә кинәт туктый да, үрелеп, иреннәремнән йомшак кына үбеп ала. Авыл кызыннан мондый батырлык көтмәгән мин, сукбай, кабаланып, шунда ук аның күлмәк изүләренә үреләм. Тик Мәдинә:

— Кирәкми! — дип этеп җибәрә, аннан ай нуры яктысында ялтырап күренгән басмага таба йөгерә. Нәкъ басма уртасында мин аны кабат көчле кулларым белән эләктерәм. Ул каршы тора алмый, гөрс итеп кытыршы такталар өстенә килеп төшәбез.

...Мәдинә һаман елауда. Ул инде нинди дә булса аваз да чыгармый. Аның сулкылдавын мин басма такталарының дерелдәгәненнән тоям.

— Ник әйтмәдең? Ник кыз икәнеңне әйтмәдең? — дим мин, өзгәләнеп. — Өйләнәм! Мин сиңа бүген үк өйләнәм! Менә кайтабыз да... Әниләреңә сәбәбен дә әйтми генә, хәер-фатиха сорыйбыз...

Бераздан без кайтыр юлга күтәреләбез. Инде тынычланды дип уйлаган Мәдинәм кинәт аңын югалтып егыла. Мәдинәне ике чакрым күтәреп алып кайтам. Басу капкасы янына җиткәндә, кыз күзләрен ача. Кулларымнан төшерәм. Бер-беребезгә күтәрелеп карарга да оялып атлыйбыз. Бераздан:

— Мин Сезне бик тә ошаткан идем бит... Бу инде безнең өй. Башка беркайчан да... — дип, нидер сөйли генә башлый, киң итеп ачылган урыс капкадан бөеренә таянган бер апа килеп чыга.

— Аһ, ыштыр бит, гомер булмаганны, атаң ни әйтер, төнне керфек какмый чыктык! — дип зәһәрләнеп чәпчергә тотына.

Мәдинә яңадан, аңын югалтып, инде аның аяк астына ук егыла. Мин, әле яңа гына өйләнергә вәгъдәләр биреп кайтканымны да онытып, караклыкта тотылган мәче сыман, алныартны күрми чабам. Кая барганымны, ни булганны белештерми чабам.

Һәм... әлеге су янына килеп чыгам. Ә басма өстендә... чәчләрен иңнәренә таратып, Мәдинә утыра!

— Юл гынаем китте су буйлап... — дип җырлый ул.

Кирегә йөгерәм. Тагын адашам. Тагын Мәдинәгә килеп чыгам. Тагын, тагын... Мине, таң аткач, хәлдән тайган килеш егылган җирдән табып алалар. Өстемдә — бөгәрләнеп беткән чалбар, яшелләнеп беткән күлмәк, йөзем — яшьле туфракта, имеш. Куркыныч бер төш кебек узган төнне аңлый алмый торам. Якынайган клуб мөдирен күрү генә айнытып җибәрә. Барып, якасына ябышам:

— Ник кыз икәнлеген әйтмәдең? Ник әйтмәдең?!

Ул, бер дә исе китмәгән кыяфәттә:

— Минеке булмаганга! — дип җавап бирә.

Бугазга тыгылган төерне аңа төкереп ташлыйсы килә. Иптәшләрем төялгән автобуска сикереп менәм дә:

— Шофер, мөмкин кадәр тизрәк! — дип әмер бирәм. Бу урыннан качасы, бу төнне онытасы килә.

Басу капкасын чыгып бераз баргач, уңга бормаланып киткән юлга карыйм. Анда шул ук зәңгәр күлмәктән башын кыңгыр игән Мәдинә басып тора. Еракτан миңа аның күзләре күренми, әмма мин аларны тоям. Алдарга өйрәнмәгән ул күзләргә ни дияргә белмим.

Гашыйк идемме мин аңарга? Юк! Рәнҗетергә теләдемме? Юк! Нинди кыргый хис мине адаштырды?

Ә нигә өйләнмәдең, диярсең? Анысын да белмим. Бары бер нәрсә минем башымны аңгырайта: нинди уйлар белән килгән Мәдинә күл янындагы сукмакка?..

Әлеге вакыйгадан соң чирек гасыр Киндеркүл якларына аяк басмадым. Чирек гасыр! Шулай да бервакыт, бөтен батырлыгымны җыеп, мин шул авылга барып чыктым. Инде клуб мөдире икенче икән, Мәдинә турында аннан сорашырга кыюлыгым җитмәде. Концерт башланыр алдыннан, пәрдәдән кечкенә генә тишек бөреп, залга күз ташладым, иң беренче рәттә зәп-зәңгәр күлмәкле, нәкъ Мәдинә төсле кыз утыра. Бәлки, туташ, бәлки, ханымдыр...

Миңа начар булып китте. Сәхнәгә чыгарлык хәл калмаган иде. Алып баручы, бер артистыбыз авырый, дип гафу үтенде.

Концерт тәмамланыр алдыннан, соңгы көчемне туплап, пәрдә кырына килдем. Залда чибәр кыз утырган бердәнбер урын буш иде...

— Кирәкми, сөйләмәгез! — дидем мин, кунагымның касәле кулларын үземә таба тартып. — Кирәкми, сөйләмәгез... Пыяланың таш сурәтләренә кадәр сулдылар бит инде. Кирәкми, сөйләмәгез... Мин Сезгә ышанам.

*1995*

## Айлы күлдәвекләр

Давытның кызгылт көрән костюмы эченнән әллә нинди серләр эзләгән шикелле, җил, чишеп, сәдәфләрен йолыккалап уйный. Ул, аңа тар булмаса да, буйга кечерәеп, утырып калган. Әллә каян, егет, син инде мәктәп баласы түгел, үскәнсең, ирәйгәнсең, дип әйтеп тора.

Давыт быел нигәдер гел әлеге костюмында гына йөрде. Шомырт кара чәчле, ыспай гәүдәле бу егеткә башка берәүне койрыксыз тавык итәрдәй кием дә килешә. Менә ул шул костюмында клубка килеп керде дә, беркемгә дә сәлам бирмәстән, туп-туры миңа таба атлады.

Безнең яңа салынган зур мунчабыз кадәр бу агач йортта миңа җитәргә — нибарысы биш адым. Соңгысы минем туфли очларына ук килеп терәлә. Юньлерәк кино булганда, авыл кешесенең яртысы, ишек ачып, урам яктан карый. Аларга акча түлисе булмый, шуңа күрә андый көннәрдә бала-чага, зал тулганны көтеп, ишегалдындагы чирәмлектә мәш килә.

Егерме-утыз кешелек кичке уеннар өчен дә урындыкларны ян-якларга җыялар монда. Мин һәрвакыт диярлек аларның уңдагысына утырам. Шәһәрдән кайтып, клуб ишегеннән баш белән сөзеп кенә, кыз эзләгән егетләр күзенә дә чалынмыйсың, биик әле, дип аптыратучылар да каршы яктарак.

Давыт моны белә. Озын аякларын берсе өстенә берсен чалыштырып утырган Саниягә бәрелми генә, минем янга уза.

Бөтен авыл Саниянең әнисе тәрбиясендәге кызын әнә шул чибәр егетнеке саный. Инде утызы тулып килә торган бу ханымга нинди мөнәсәбәттә булуын Давыт беркайчан да, хәтта миңа да сиздерми. Ә мин, үҗәтләнеп, сүзне гел аңа әйләндерәм дә кайтарам, әйләндерәм дә кайтарам:

— Сания бүген бигрәк килешле күлмәк кигән иде, Давыт.

— Әллә тагын.

— Туфлиенә кадәр туры килә. Каенсарда иң зәвыклы кыз бит ул.

— Ә-ә-ә…

— Аларның урамнары сезнеке кебек чокыр-чакырлы түгел шул, клубта бутыйлар кочаклап утырмый, — дим мин, уфтанып һәм кулымдагы аяк киемнәренә ачу килеп.

Без, шул рәвешчә сөйләшеп, тагын берничә йортны узабыз. Мин, күптәннән әзерләнгән сорауны бирер өчен, җайлырак вакытны эләктермәкче.

Менә ул, барган җиреннән туктап, ике кулымны кушырып, иреннәренә китерә.

— Саниянең куллары бигрәк тә эре име, Давыт?

— ...

— Күзләре дә зур, борыны да дугалы... Нәкъ бәрәңге бакчасында үскән кавказ кызы инде менә.

Давыт көлә генә:

— Шулаймыни?

— Шулай шул! — дим мин, әллә нинди бер зәһәрлек белән, Давытны аңламамышка, белмәмешкә салына санап.

— Шулайдыр шул, — ди Давыт бераздан. — Үзе дә озын буйлы бит. Мин хәзер кечкенә гәүдәлеләрне ошата төшәм. Кызлар кулга күтәреп йөртерлек булсын ул!

— Озын буйлыларны күтәрә алмыйм, диген, Давыт, гел әйләнечтән киләсең.

— Әйдә, синеңчә булсын. Күтәрмәс өчен качуым дип аңламагач...

Күз алдыма яшел күлмәк, зәңгәрсу-яшькелт кофта кигән Сания килеп баса.

— Саниянең карашы гел синдә, — дим мин, тагын да мәкер беләнрәк.

— Ә Илдарныкы кемдә? Аныкы да синдә бит.

— Илдар Илдар инде ул. Ул мине ярата. Ә менә Сания...

— Син алайса, ул кемнедер яратмый дип уйла.

— Менә мин аны сине ярата мәллә дип уйлыйм, Давыт! Синең мин яратмаган өтек костюмыңа кадәр ярата!

Төрттерүләремнән тәмам алҗыган Давыт, аерылып, алгарак китә. Алҗыпмы, әллә үпкәләпме — белмәссең тагын. Баскан урынымнан кымшанмыйм да. Үтә дә үҗәт холкым мине айлы күлдәвек янында тезләндерә. Аның янында гына язгы ташуларда акмый калган йомычкалар ята. Мин шуларны йөздереп уйнарга керешәм. Артыннан бармасымны аңлаган Давыт кирегә борыла.

— Йә инде, Нургөл, кайтыйк, үпкәләмә. Сине генә яратканымны беләсең ич. Үзем үпкәлисе урынга...

— Бар, кайта тор, Илдар белән кайтырмын әле. — Аннан әкрен генә җырлап җибәрәм:

Әнә килә ак пароход,
Ак билләрен бумаган.
Мине каратыр егетләр
Бу дөньяга тумаган.

Көрән пароходчыкларым, икенче күлдәвеккә илтер бугазда тыгылышып, түбән якка ага алмый торалар. Аксалар, алар Илдарның резин итекләренә килеп-килеп бәрелерләр иде... Бездән әз генә арттарак аның кайтканын беләм мин. Озак та үтми, кара шәүләсенең якынлашканы да күренә.

Илдар бер аякка аксабрак атлый. Әле генә, идәннән тузан күтәреп, бөтен клубны дер селкетеп биегән егет димәссең. Кайбер озын телләр, кызлар өчен сугышканда, Илдарны Давыт имгәткән, дип сөйлиләр. Мин исә Сания өчен дип фаразлыйм.

Чүгәләп утыруымны күреп, Илдар да туктала. Айлар буе шәүлә булып кына йөргән бу егет бүген нигәдер якынга ук киләсе, сүз башласы итә — әле Давыт белән танышканчы колакларымны иркәләгән бәрхет тавышы белән:

— Ходай шулай язган шикелле, юлларыбыз гел кисешә безнең, — ди.

Егетем, туры карамыйча гына, аның сүзләрен кырт кисә:

— Бер үк кызлар өчен сугышып яшәрбезмени гел?!

Аяк асларында җыелган суларда — ай шәүләсе. Давыт та, мин дә, Илдар да шуңа текәлгәнбез. Сүзләр булса да, сөйләшәсе, тын да аласы килми.

— Мин китәм инде, — ди аннан Илдар, авыр сулап. — Китәм. Армиягә. Тәки аласы иттеләр. Кайтуыма, бәлки, аксавымның эзе дә калмас.

— Китмә лә, Илдар, — дим мин, тиле шикелле.

Ул миңа, куртка кесәсеннән чыгарып, бөгәрләнеп беткән чакыру кәгазе суза.

— Иртәгә кил. Озату кичәсенә. Көтәрмен.

Аннан аз гына уйланып торгандай итенә дә:

— Давыт, син дә кил. Ачу йөртмә. Ул әле беркемнеке дә түгел! — дип өсти, миңа ишарәләп.

Салкынча апрель җиле Илдарның чәч бөдрәләрен тузгыта.

Ул үзләренең урам чатында кала. Баганадан төшкән тонык ут яктысында әле бик озак басып тора. Җыелган сулардагы ай шәүләсенә карап, мин гел аны уйлыйм. Олыгаеп барган бу егетнең, үзе теләп, Хезмәткә китүенә гаҗәпләнергә дә, бу хәлне ахмаклык санарга да, аңа сокланырга да белмим.

Капка төпләрендәге суларда да — шул ук ай. Киселеп атылган өрәңге ботагын табып алып, мин аның судагы йөзен бозмакчы булам, ә ул һаман элеккечә елмая бирә.

— Айга да усал булма инде. — Давытның бу сүзләре шундый да әрнүле, мин, исәнгерәп, юка колготкиларымны юешләтеп, җиргә тезләнәм дә айның ерык иреннәреннән үбеп алам. Әле ул яшь, әле ул җебек.

— Әй лә, ай да салкын икән бит, менә синең шикелле. Үзе якты. Яктысыннан җанга җылы юк, — дим аннан, көлә-көлә.

— Синең киемнәрең калын булганга ул, ничек итеп аркылы үтеп керсен?!

— Гел шушы изүе ачык костюмнан йөргәч, үз җылың җитмәдеме икән?

— ...

— Киләсе елга кимәссең инде яме, Давыт?

— ...

— Син менә бу аяк астындагы айны да тимер табанлы итекләрең белән таптап китәрсең шикелле. Ә мине...

— Ә сине яратырмын гына!

— Сезнең авылда айсыз төн буламы, Давыт? Давытсыз төн буламы? Адым саен — чокыр, чокыр саен — су, су саен — бер ай... Шул ай янында — Давыт! Сез никадәр икән бит!

Чүгәләгән җиремнән генә Давытның өстенә айлы су сибеп алам.

— Тик менә әтәч костюмың гына берәү.

— ...

— Киләсе елга кимә инде, яме, Давыт?!

— Ә мин аны яратам, ияләнгәнмен. Башкасы әллә ничә юкса.

— Яратсаң, балагын бөкләтеп, җәен шортик итеп киярсең. Костюмы да әбиеңнең күкрәкчәсе кебек кенә калган бит инде!

Ну бу айны! Чекерәеп карап торуында.

Ә бит айлы сулар Илдарның серле күзләренә охшаган.

— Айлы күзем, әйдә биергә чык, — дим мин аңа кайвакытларда, соклануымны яшермичә, үземне авыл кызларыннан көлдертеп.

Менә мин тураям да, урам суларындагы айларны санап, апамнарның капкасында югалам.

— Бер, ике, өч, дүрт...

Резин итекләремә кереп утырган айлардан — аякларым юпь-юеш.

Давыттан капкага кадәр нәкъ унбиш ай. Миңа да шулкадәр үк яшь. Кирегә таба сикерсәм, Давыт яшенә җитәр идем дә... ул инде, үпкәләп, өенә китеп баргандыр. Капканы яңадан ачып, Давыт басып калган җиргә карыйм. Өтек кызыл костюмының әле һаман да шул урында калуын күреп:

— Иртәгә! Клубта! — дип кычкырам.

Өйдә мәчедән кала барысы да йоклаган. Ул тәрәзә төбендә мине яраткан айга карап утыра. Мәчегә, айга зур итеп телне чыгарып күрсәтәм дә юрган астына кереп чумам.

Миңа үпкәләгән ай икенче көнне тәүге тапкыр Каенсар өстенә күтәрелми. Уку китапларымны чак өстерәп, тагын авылга кайтам. Караңгы. Пычрак. Шыксыз. Үзле балчык аякларны тагын да авырайта, көне буе яуган яңгырдан баткакка әверелгән юл, үзәгенә суырып алырдай булып, үзенә тарта.

Клубка, теләр-теләмәс, сүз биргәнгә генә төшәм. Караңгы сазлык булып калган урамнарда эт тә юк дияр идең, алар кисешкән чатта — ниндидер карачкы. Якынгарак килгәч, мин аның Илдар икәнлеген таныйм.

— Нишләп торасың син монда, Илдар? — Соравым мәгънәсезрәк, әлбәттә.

— Менә сине көтеп.

— Мин бит клубка барам — вечерга.

Давыт янына, дип, дөресен әйтергә мәллә?

— Озатырга да килмәскә булдыңмыни?

— Давыт... — дип кенә сүз башлавым була, ул сүзне ишетүдән үк корт чаккандай, Илдар ирексезләп күтәреп ала да, кыргый җанвар шикелле, сазлы юллардан да курыкмыйча, мине кочаклаган килеш, үзләренә элдерә. Капка төпләренә җиткәч кенә, хәле киткәнгә, җиргә бастыра.

— Үз аягың белән кер, Нургөл, анда сине көтәләр.

— Ничек, бер белмәгән кешеләрме?

— Мин аңлаттым. Сөйгән кызым, дидем.

— Үзе генә сөйми, дип тә өстәдеңме?

— Анысы нәрсәгә соң аның? Вакыт күрсәтер әле. Шундый көнне...

Әйе шул. Иртәгә инде Илдар булмас та. Бер чынаяк чәй эчеп чыкканнан укам коеламы?

— Оялам мин, Илдар... Беркемең дә түгел килеш. Башка кызны чакырсаң ни була инде...

— Бу төн генә минем янымда утырчы, Нургөл. Юкса мин өйгә кереп тә тормыйм, менә хәзер үк биштәремне алам да китәм дә барам.

Безнең бәхәсне ишеткәннәр, ахрысы. Ачык капкадан Илдарга охшаганрак бер ир-ат килеп чыга:

— Сеңлем, кермисезмени?

— Ю-у-у-к, — дим мин, сузып, еламсырап. Шул арада пәйда булган өч-дүрт егетнең, мине курчак кебек кенә күтәреп, өйгә алып кереп китәселәрен сизенгән шикелле.

Өй тулы халык. Мине түрдә калдырган артлы урындыкларның берсенә ипләп кенә утырталар. Пар фужерларга икебез өчен салынган, сүрелгән шампан өстендә Илдарның күзләре йөзәдер кебек, мин гел аның алдындагысына карап утырам. Илдарның күзләре Давытныкына бөтенләй охшамаган! Каенсар өстендәге айларга охшаган, дим ич!

Мәҗлес тынып калган. Менә ишектә Илдарның әти-әнисе һәм туган-тумачалары күренә. Абыйсыдыр дип фаразлаган ир-ат үзенә сүз сорап ала:

— Кайчандыр шушы өйдә мине Нургөл шикелле чип-чибәр, япь-яшь кыз Хезмәткә озатып калган иде. Бер-беребезне мәңге онытмаска, хатлар алышырга вәгъдәләр биреште без. Хушлашу мәҗлесендә әйтелгән әлеге вәгъдәләрнең барысы да ялган булып чыкты.

Нургөлнең бөтен йөзе башканы сөйли. Мин аңа карыйм да, Нургөлдән дә сафрак кыз бар микән, дип уйлыйм. Мондый зур кара күзләрдә нигәдер ялган булмас шикелле.

Нургөл сеңлем, минем япа-ялгыз яшәвемнең серен син аңлагансыңдыр инде. Энемнең дә минем язмышымны кабатлавын теләмим. Син аны көт. Хатларыңнан мәхрүм итмә. Сине уйлап, ул болай да йокламый, төннәр буе көрсенеп чыга.

Минем хактагы сүзләрне кире кагып, Илдарның беркеме дә булмавымны аңлатырга теләсәм дә, безнең дуслык, мәхәббәт хакына күтәрелгән чәркәләр моңа мөмкинлек бирми. Аларга яңа теләкләр өстәлә, бүлмәне шау-шу күмеп китә.

Илдар җиңелчә генә яңакларымнан да үбеп алгач, бик тә көлке бер хәлдә калуымны аңлыйм. Кызарганымны тоям. Аска карап кына утырам.

Бу авылда күзләре төшкән кызга алмадан чәчәк ясап җибәрү гадәте бар икән. Өстәлдә минем турыга өем булып җыелган алмаларны Илдар бушап калган савытка сыпырып төшерә дә иң матур, иң кызыл бөтен алманы кулыма китереп тоттыра.

— Көтсәң, мин сине алма гына ашатып яшәтермен, — ди ул, шаяртып.

Кунаклар тәнәфескә чыгып киткәч, безне Илдарның туганнары чорнап ала. Мәхлук бер чыпчык баласы шикелле кечерәеп, алар уртасында хәер-фатиха тыңлап утырам.

Бүлмә бөтенләй бушап калгач, сораулы карашларымны Илдарга төбим. Нинди тамаша булды инде бу, янәсе.

— Мин сине яратырмын, менә күрерсең. Тик хат кына яз, оныта күрмә. Бер истәлегемне калдырам. Әгәр шуны югалтсаң, мәңге кавыша алмабыз, син мине бөтенләй онытырсың... — дип, ул иңбашларыма элгән җәйге пәлтәм кесәсенә медальон салып куя.

— Илдар...

— Бер сүз дә кирәкми. Вакыт күрсәтер. Мин башкача булдыра алмадым. Ачуланма инде. Һәм минем яратуыма ышан.

Иртә таңнан авыр Хезмәт юлын башлаячак егеткә ничек ачуланасың?! Ә бәлки, мин язачак хатлар шул юлларны җиңеләйтә төшәр, дигән уй белән аңа вәгъдә биреп ташлыйм.

Бөдрә чәчләреннән мәхрүм калган башына башка бер чакта тигәнәк кадап китәр кыз булсам да, назлап, үз итеп маңгай турысын сыпырам:

— Чирләмә, исән-сау йөр, Илдар, кем белә...

Артыграк сүзләр әйтелмәсен дип, шул урында туктап калырга акыл җитә. Туган апаемнан рөхсәт сорамаганлыктан, инде бу йортта кала алмасымны аңлатам да мәҗлестәгеләр кергәнче дип кузгалам.

Яңгыр туктаган. Болытлар таралган. Мине яраткан ай малайлары тагын җыелган суларга төшеп утырганнар.

— Сиңа аларга басарга ярамый. Күзләреңне таптап китәрсең кебек тоела миңа...

Озата килгән Илдарны һәр сүзем гаҗәпкә калдыра.

— Бигрәк тә сәер кыз инде син, Нургөл. Бездә болай серле итеп сөйләшмиләр. Әллә шуңа авылның бар егете синең арттан чаба. Алай миңа күлдәвеккә басарга да ярамагач, үзең ник айдан айга сикереп йөрисең?

— Минем аякларым — күбәләк аяклары ич алар. Моннан соң ай санаудан да туктармындыр, ахрысы...

— И-и-и Нургөл, түш кесәңдәге истәлегемне генә сакласаң да, бик җитәр иде әле. Күккә менеп, айны йолкыган кеше юк. Бездән соң да кала ул. Сиңа карап кала...

Капка төбендәге соңгы күлдәвектәге айга төртеп сөйләгән бу сүзләргә үпкәләргә дә булыр иде. Юри генә, үртәп, котыртып. Тик нигәдер алай эшләмим. Утыргычка басып, Илдарны муенынннан кочып алам.

— Син, үзең дә ай күзле егет, кемнән соң кемнең, нәрсәнең каласын каян беләсең? Әллә болытлы көндәге ай кебек китеп барырсың да югалырсың...

Үз сүзләремнән үземә үк авыр. Ичмасам, ул да дәшми генә хушлаша. Икенче көнне укырга бернинди теләксез барам. Авылдан райүзәктәге мәктәпкә кадәр ара бер-ике чакрымнан артмаса да, юлда көннәр узгандыр күк. Тәнәфес вакытында, мәктәпнең ачык тәрәзәләре янына килеп, бездән якында гына комиссариатка җыелган егетләрнең җырларын тыңлыйм. Башкасын белмәгән шикелле, махмырлы тавышлар әледән-әле:

Через две, через две зимы-ы-ы,
Через две, через две весны-ы-ы...—

дип үкерә.

Илдар белән ике арада адымнар гына ятса да, минем аны озата бармавым күңелне тырный. Ничек кенә эшләсәм дә, ялгышырмын кебек тоела. Чишенү бүлмәсенә кереп, пәлтә кесәсендәге медальонны барлыйм һәм... аның урланганлыгын беләм.

Әгәр сакласаң... әгәр сакласаң... ди миңа эчке бер тавыш, нәкъ Илдар шикелле. Алар әле машинага да төялмәгәннәрдер, инде кесәдәге истәлегеннән җилләр искән.

Көннәр, атналар, айлар уза. Илдардан хат юк та юк. Минем хакта, аны озатып калган икән, дип ишеткән Давыт та авылларыннан чыгып китте. Алай да хушлашырга киләсе иткән үзе. Элеккечә, гадәттәгечә, кулларымны кушырып, иреннәренә китерде дә, башта бик озаклап җылы өргәч, кисәктәнрәк:

— Сания өчен китә икән дип уйлама, аның баласы Илдарныкы иде, болай да күп сүз ишеткән кызны җәлләп, ни дә булса аңлатырга гына теләмәдем, ныклап кочканым да булдымы икән аны... — диде.

— Ә Илдар, Илдар нигә шулай эшләгән?

— Яратмагандыр ул аны, Нургөл, яратмагандыр. Яратса, рәнҗетер идеме икән?! Ә бәлки... Рәнҗетмәгәндер дә! Шулай булуын Сания үзе теләгәндер... Яшь түгел иде бит инде. Илдар да авылның менә дигән егете. Күз төшмәслекмени?! Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, диләрме әле? Гаепләргә генә җиңел ул.

— ...

— Менә үзең… Илдар да сине ничек ярата иде бит, Нургөл! Минем кебек үк диярге генә тел бармый…

— Илдар да Илдар, дисең. Аның миңа хат та язмаганлыгын белмәгән шикелле... Юкса нинди сүзләр сөйләгән иде. Үзе әйтмешли, вакыт күрсәтте...

Давыт, чынлыкта да, безнең хат алышмаганыбызны белмәгән икән. Аптырап ук китте.

— Ә син почта бүлекчәсенә барып белеш, — дип киңәш итте ул. — Син безнең авылда яшәмәгәч, бәлки, кире борганнардыр. Үз адресыңны биргән идеңме?

Менә акыллы баш! Чыннан да! Кайда торганымны әйтмәгәч, кая җибәрәсен кайдан белсен инде Илдар?! Апамнарга — Каенсарга язса гына. Давытка башка сүз өстәрлек тә итмичә бәхет теләдем дә урам буйлап район почта бүлекчәсенә йөгердем, әмма, ишегенә «Сортировочная» дип язылган бусаганы атлаганда, йөрәгем жу итеп китте дә, корт чаккан шикелле, кире атылып чыктым. Анда, Каенсар дип язылган ящик янында, әлеге дә баягы Сания хатлар аралап тора иде.

Әгәр аны югалтсаң... Әгәр аны югалтсаң... Кем кемне, нәрсәне югалтты соң? Кем тапты?.. Кайсыбыз кайсыбызны берни белмәстән гаепләде? Инде һичнәрсәне үзгәртеп булмый иде!

Үсмер кызны яраткан айлар да, шул айлы күзле медальон да, аның иясе Илдар да, мине шулар хакына калдырган киң күңелле Давыт та тормыш күлдәвекләренә мин табып алмаслык төшеп югалдылар, ахрысы.

...Асфальты ватылып беткән тротуардан әкрен генә атлыйм. Кала юллары мине Каенсар сукмакларына алып чыкмый. Мондагы суларда кайчандыр мин санап шаярган ай малайлары юк. Илдарның күзләреннән ай качкан...

*1996*

## Умырзаая

Узган ел җәй буе су коенган бала-чага аякларыннан үләннәре кырылып, шадраланып беткән текә яр өстендә утырабыз. Җил исеп куйган саен, ерактан, каршы яктагы таулар итәгеннән, эреп бетмәгән карлар кочагында калган умырзая исе килә.

— Сизәсеңме? — дим, Язиләнең нәни бармакларын учларымда сикертә-сикертә.

— Нәрсәне?

Ул шулай, һәрвакыт аңламаганга, исе китмәгәнгә салыша. Мин үпкәләмим.

— Умырзаялар әле дә чәчәктә икән. Җилдә аларның хуш исе бар.

— Хыялый. Умырзая ерак тауларда гына була ул. Аның исе дә көчле түгел. Гомере дә кыска. Бездәге кар астыннан баш төрткән тәүге чәчәкләр дә шундый. Тик алар умырзая түгел. Умырзая дип әйтәләр генә...

Язилә аркасына таратып салган чәчләрен, көтмәгәндә ява башлаган яңгыр итеп, кискен бер җитезлек белән, минем кояшка чытылып утырган йөземә сибеп ала. Аннан алар, кара дулкын булып, кызның күкрәгенә яталар. Елык-елык, дерт-дерт килгән бу дулкыннар минем карашымны үзләренә чигеп куя.

Елык-елык, елык-елык... Тау итәгеннән, умырзаялар тамырыннан ук агып төшүче чиста-саф суларда гына була торган серле бер каралык бу. Инде мин җил искәнне дә көтмим, үзем тирәнрәк итеп суларга, яз исен күкрәгемә күбрәк сеңдереп калдырырга тырышам. Язиләгә карамый гына, кабат:

— Сизәсеңме? — дип сорыйм. — Килә бит, килә!

Кыз:

— Умырзая хушбуе ич ул, хыялый да инде син, дим ич! Үзең бүләк иткән хушбуй исен дә аермагач! — ди дә, сикереп торып, яр буеннан йөгереп тә китә.

Күпме тырышсам да, мин аны тиз генә тота алмыйм. Без, хәлебез бетеп, әле яңа гына сыенышып утырган ярыбызга килеп егылабыз.

Узган елгы үлән арасыннан тырпаешкан каты сабаклар күзләремә, иреннәремә төртелә, әйләнеп чалкан ятам.

Рәхәт…

Күктә болытлар. Агылалар да агылалар. Бу болытлар кайдадыр якында гына бөялерләр дә, бер-берсе өстенә менә торгач, инде күктә асылынып тора алмас хәлгә килеп, өстемә ишелерләр...

Без йөгерешкән арада, кояш калын болытлар астына кергән. Хәзер шуның каерылып киткән бер читеннән кемнәргәдер, нәрсәгәдер мәкерлерәк елмаю чаткылары ташлый. Мин аның пәрәнҗәдә калган ягыннан да куе кызыл иреннәрен, сап-сары күз-керфекләрен төсмерлим...

— Күрәсеңме?

Язиләгә борылган чакта авызыма килеп кергән язгы үлән бөртеген җәлт кенә тешләрем белән эләктереп алам да миңа хас булмаган бер зәһәрлек белән өзеп ташлыйм.

Болытлар, кояш хакында сөйләү теләгем каядыр китеп югала. Торырга, качарга кирәк. Булдыра алмыйм. Бер сәбәпсезгә янымда утырган Язиләдән башка беркем, бернәрсә кирәк булмый башлый.

Ап-ак икәннәрен белсәм дә:

— Күрергә дә теләмим мин сезне, яңгыр болытлары! — дип кычкырам.

Җил исеп куя. Ерактан, каршы яктагы таулар итәгеннән, эреп бетмәгән карлар кочагында калган умырзая исе күкрәгемә ята, Язиләнең нечкә беләкләреннән тотам да үземә тартам, сулышым кабып:

— Умырзаям... — дип пышылдыйм.

Аның чырык-чырык көлгәне чәчәк исенә һушланган борын яфракларымны тагын да киңәйтә.

— Күрәм, күрәм... Бу болытлар өстемә ишелерләр дип ышыкланасың син миңа. Болыт дымында чирканчык алудан куркасың. Әле үзең, сөйли китсәң, кояштан да ояласыңдыр. Хыялый бит син!

Әйттем ич, аның белмәгәне, аңламаганы юк, дип, мине үртәр өчен генә беркатлылана ул.

Тагын җил исә. Тагын болытлар бөтерелә. Тагын умырзая исе килә... Башым әйләнеп китә, үземнең көчлелегемне расларга теләпме, Язиләне кочагыма каты итеп кысам да татлы иреннәреннән суырам. Ул, чит хуҗа кулына эләккән кош шикелле, йодрыклары белән бертуктаусыз күкрәгемне дөмбәсли. Әүмәкләшә торгач, без, үзебез дә аңышмастан, тып-тын яткан Бөрнең тынычлыгын алып, салкын кочагына килеп төшәбез.

Әле кайчан гына калын-калын бозларны йомычка урынына күчереп йөрткән агымга безне чуерташлы, комлы ярга илтү берни түгел. Өсләребезгә сыланып калган киемнәрдән шабырдап су ага.

Әле беркемнең дә быел Бөрдә коенганы булмагандыр.

— Без — беренчеләр, — дим мин, Язиләнең ничек тә булса күңелен табарга тырышып.

Каз тәпи эзләре дә төшәргә өлгермәгән яр буенда, су тулы күзләрен дерелдәтеп, миңа карап тора ул. Бөрешеп, кечерәеп калган. Иреннәре зәңгәрсу умырзая чәчәге кебек булса да, чәчләреннән хушбуй исе югалган... Каршы як таулардан җилләр итәгендә очып килеп борын яфракларына кунганына да инде үземнең дә исем китмәс иде.

Башларыбызны иеп, үрдәк бәбкәләре шикелле, тыкрыктан гына кайтып керәбез. Язиләнең умырзая таҗы кебек итәкләре капкадан югалганчы карап торам да инде кызурак адымнар белән үзебезгә таба атлыйм.

Ярый әле өйдәгеләр һәммәсе эштә. Тиз генә чишенеп, киемнәремне суынырга өлгермәгән мич өстенә таратып салам.

***

Рафикъ абый, хикәясе шушы урында өзелергә тиеш шикелле, кулындагы таягы белән учактагы кузларны тараткалый башлады. Аның учак кызыллыгы төшкән күзләрендә әйтеп бетермәслек моң күреп, мин дөньяның һәр кешесендә, табигатьнең һәр иясендә әллә нинди серләр барлыгы турында уйладым.

Күккә үрләгән зәңгәр җылы төтенгә ияреп, бәлки, бу сагышлы хикәя болытларга менәр дә Язилә апа торган якларга китәр. Рафикъ абыйның яшьлеге белән генә яшәве хакында сөйләр. Ак болытлар, өелешсәләр, чыннан да, аның кочагына ук ишелеп, шуып төшәрләр. Рафикъ абыйны сөендерәсем килепме, ни дияргә белмәгәннәнме, җилкенүле тавыш белән:

— Телисезме, мин бу вакыйганы хикәя итеп язып бастырам. Сезнең якларга барып чыгарга бер-бер сәбәп тә булыр. Әле матур бетәчәк дәвамын белмибез бит. Үзегез дә минем белән туган нигезегезгә кайтырсыз. Язилә апа белән күрешеп сөйләшү — инде бу яшьтә, ул кем белән генә яшәсә дә, гөнаһ түгелдер, — ди генә башлаган идем, ул җилкәләремә кулын салып туктатты:

— Кирәкми, энем... Аның ахырын болай да белерсең. Язилә дөньяда юк инде. Әле ул сиңа апа да булмаган килеш җир куенына кереп ятты. Шул салкын суда коенганнан бирле тернәкләнә алмады. Авылда, утырып торган яры ишелгән икән дә, суга төшкән, дип сөйләделәр... Электән дә сәламәтлеге какшаурак

булган, ахры. Ә мин ярым ятим үскән бу кызның җитезлегенә, көчлелегенә шаклар ката идем югыйсә. Умырзая булган шул ул, умырзая... Умырзая кыска гомерле, дигән иде бит үзе дә...

Умырзая дигәннән, икенче язда Язилә апаң, шуны иснисем килә, дигәч, каршы тауга җан-фәрманга йөгердем мин. Каекка да утырмыйча, үземне сынарга да, акларга да теләгәндәй, бозлы салкын суны йөзеп чыктым. Менә, аннан гына берни булмый, янәсе!

Йөгердем, болыннарга умырзая исе таралмаган булса да, шул искә ияреп баргандай, җан-фәрманга йөгердем. Юк иде ул умырзая, юк! Әллә ул элек тә бөтенләй үк булмаганмы?

Буш кул белән ябышып, ишек яңакларына сыланганымны күргәч, Язилә көрсенгән итенде:

— Әйттем ич, хушбуй исе генә, дип... Син бүләк иткән хушбуй исе… — дип куйды.

Нигә чагыштырдым мин аны һәрвакыт умырзая белән? Күзләрен дә, чәчләрен дә, кигән күлмәкләрен дә. Шул чагыштыруым белән аңа кыска вакытлы гомер күрәзәлек кылдыммы? Әллә нәрсә дә булса алдан ук сизенгәнмемме? Шул уйлар йөдәтә, тынычлыгымны ала. Бу үкенечле хикәятне сөйләвем дә шулардан бер арыну өчен генә иде. Кирәкми, яза күрмәгез тагын.

— Ничек телисез инде, Рафикъ абый.

— Мин берни дә теләмим. Миңа умырзая исе җитә! Их, көне бит, көне! Җитмәсә, яз... Кояш.. Җил... Ул йомшак уч төпләрендә умырзая исе сузадыр шикелле…

Мин, сәерсенеп, Рафикъ абыйга карадым. Әллә тагын саташа инде ул? Җил сизелер-сизелмәс кенә. Учактан бөтерелә-бөтерелә таралган төтендә нинди дә булса ят исләр барлыкны тоемларлык та түгел. Саташканга да охшамаган болай.

— ...Инде авылны кабат күрмәскә дип чыгып киткәннән соң, күп еллар үткәч, әни карчык та Казанга килеп вафат булгач, ялгызлыктан каңгыраксап яшәгән көннәрнең берендә миңа яшь кенә ханым белән танышырга туры килде. Үзе чибәр, үзе акыллы. Гомер буе болай дуадакланып яшәү килешми инде, дигән уйга килеп, ныграк аралашырга, холкын-фигылен өйрәнергә теләдем.

Ул вакытта да яз көннәре иде. Автобус тукталышында очрашырга сүз куештык. Түземсезлек белән аны көтәм. Эчтә әйтеп аңлата алмаслык сагыш. Бер-бер сәбәбе дә юк шикелле. Тиктомалдан күзгә яшь килеп терәлә, бугазга төер утырган.

Менә берзаман яңа танышым да күренде. Өстендә — кап-кара пальто, башында — күзләрнең явын алырлык ап-ак шарф.

Килеп тә җитте, инде якын бер кешесе исәпләпме, ул да ялгызлыктан туйган идеме, минем кочагыма да ташланды. Хатын-кыз күкрәге тоймаган, кочмаган тәнемне җиңелчә калтыравык алды, аны кысып-кысып сөясем,чәчләреннән үбәсем килде.

Менә ак шарфы башыннан шуып төште, менә чигә бөдрәләре битемә килеп бәрелде... Мин, шашыпшашып үбәсе урынга, танышымнан ычкынып, уттан-судан качкан шикелле, кая барганымны үзем дә белми, бер якка йөгердем.

— Ни булды? — дидем мин, Рафикъ абыйның көтелмәгән бу адымына сәерсенеп.

— Ни булсын, ханымның чәчләреннән умырзая исе килә иде. Умырзая исе!

Инде шактый олы яшьтәге кешенең, сабый бала шикелле, кулларын кая куярга белми угалап утыруын, керфекләре дерелдәвен күргәч, тынычландырырга теләп:

— Ә, бәлки, хушбуй исе генә булгандыр, — дип куйдым. Бу сүзләрем белән Рафикъ абыйны рәнҗетермен дип уйламаган идем.

— Ихластан тыңлыйсың дип торам тагын. Кайдан килүендәмени хикмәт?! Язилә исе иде бит ул! Гомеремдә бер тапкыр җанымны кешегә ачтым, анысы да язгы суга тотып ыргытты, — диде ул, ачынып.

Бик озак сүзсез генә утырдык. Инде кузлар да сүрелеп, учак урынында көл генә калды. Рафикъ абый да басылган сыман булды.

— Умырзаялар бар микән? Әле дә чәчәктә микән? — дип куйды ул, яз һавасыннан шуны ачыкларга теләгәндәй. — Их, мин бит, шул исне тоюым белән, яңа танышыма да умырзая гомере китерермен дип курыктым... — диде аннан үзалдына гына.

*1988*

## Чәчкә абый

Җәяүләсәң, каршы искән җилгә чыдамаслык. Япан кырда, ышыкланыр җир булмагач, тик торсаң да — эңгер-меңгер салкыны үзәккә үтәрлек. Юлда бер җан иясе күренми дияр идең, оясына кайтырга соңлаган ике-өч карга нәрсәдер чүпләнеп йөргән була. Ата кошлардыр инде дип елмайды Рита.

Каргаларның иптәшләре зур бер төркемгә оешканнар да авыл өстендә бөтереләләр. Авылга моннан шактыйерактыр, ахрысы, кош өере умарта күче кебек кенә шәйләнә, әмма бер урыннан икенчесенә күченгәндә салган авазлары тын һавада аермачык ишетелеп тора.

Рита киң фасон белән тегелгән күлмәгенә төренеп куйгандай итенде дә, ике күзен дүртләп, Арча ягына карап тора башлады. Юлның аргы башыннан, ут шәүләсе биетеп, нәрсәдер килә иде.

Чүмәләләп кирпеч төягән йөк машинасы — «КамАЗ» икән. Машина көтеп тәмам талчыкканга, Рита кул күтәреп маташмады. Хәлемә керегезче дигән кебек, кабина эчендәгеләргә текәлде.

Алпан-тилпән су буеннан кайтучы йорт үрдәгедәй тырт-пырт килеп кенә якынайган машинадагылар аңлады булса кирәк — әле Рита янына җиткәнче үк, ябык йөзле, каратутлы, сирәк мыеклы бер адәм, ишекне ачып:

— Сәлам, кызый, утыр әйдә! — дип кычкырды.

Өч-дүрт сумкасын кабинага дыңгычлап тутыргач, үзенә урын калмады диярлек. Рита юлдашы белән әйберләре арасына кыймылдамаслык итеп кереп кысылды.

Мыеклыга шул җитә калды.

— Ай-яй кайнар кызый булып чыктың әле син, — диде ул, эчке бер ләззәт белән һәм, тагын да кысарга теләгәндәй, аңа табарак елышты.

— Андыйлар белән туп-туры мунчага керергә инде, — дип өстәде шофер да.

— Чәчкә абыеңнан ычкынган кыз юк әле, өлгерербез...

Ир-атларның кыланышы кәефенә бер дә хуш килмәгәнне белдереп, Рита читкәрәк этелгәндәй иткән иде, терсәкләре Чәчкә абый дигәненең кабыргаларына ук төртелде.

— Әйттем бит, кайнар кызыйга охшаган, дип, әнә ничек итеп кабыргаларымны кыздырырга тотынды! — дип күз кысты мыек, көзгә аша елмайган булып.

Шоферның да карашы бер — анда, бер — юлда. Машина тагын да әкренәйде.

Ирләрнең сүзе кыз-кыркын тирәсеннән ерак китә алмады. Аларның матурлыгын кушып, тамак ялгадылар, су эчтеләр, мәзәкләр сөйләделәр. Рита тора-бара бу сөйләшүләрнең хатыннары рөхсәтеннән башка кызлар белән кул тотып күршегә керергә дә курыккан авыл агайларының тел чарлавы икәнлеген аңлады һәм, хәвеф көтүдән арынып, үз уена батты.

Йөз чөергәндәй, аның ян тәрәзә аша кырга карап баруын юлдашлары өнәп бетермәде булса кирәк. Чәчкә исемлесе кап-кара майга баткан кулы белән кызга шоколадлы вафли китереп тоттырды.

— Шудыр! Исемең ничек соң, чибәркәй?

— Биктимер, — диде Рита, аныкына төрттереп.

— Менә бит ничек, миңа — кыз, сиңа малай исеме кушканнар. Тәмам пар килгәнбез.

— Мунча керергә генә инде, — дип өстәде тагын шофер.

— Түлке минем исем икәү бит. Монысы — үземнекеләр өчен. Казанның бөтен танылган кешесе Чәчкә дип йөртә мине! Хотя... в прошлом. Татарча әйтсәк.

Рита, кызыксына башлавын аңлатып, йөзен көзгегә таба борды.

— А как же! Абыең — гел шагыйрьләр, рәссамнар тирәсендә генә чуалган нәрсә! В убшым-то, шушындый чибәр кызның үзебезнең якта яшәгәнлеген белмәгәнгә ул.

— Сезнең як дигәнегездә бөтен чибәр кызлар утыздан узганмы? Үзе кадәр баласы бармы? — дип көлде Рита.

— Укытучыдыр әле син?! Телгә бик оста.

— Әйе шул. Укытучы.

— Нәсел-нәсәбең дә укытучыдыр әле... — диде ул, тагын төрттеребрәк.

— Булса соң, аның нәрсәсе яман?

— Алар артык тәртипле була. Менә синең шикелле. Шухыр-мухырга юл куймый. Ир-ат халкы бит ул әзрәк читтә тити-мити уйнарга ярата.

— Мунча керергә, диген, — дип өстәде шофер үзеннән.

— Тити-мити, агайне, авыл җирендә шул мунчада инде ул! Чәчкә абыең төшеп калганнардан түге-ел... Тити-митине Казан общакларында күп уйнады! И притом — шагыйрьләр дәрәҗәсендә!

— Менә мин дә — шагыйрә...

— Сиңа тагын! Укытучы инде. Тач укытучы. Бөгештермә! — дип кырт кисте шофер. — Түлке мин үзем нәкъ менә укытучыга өйләнер идем. — Аннан, яньып иреннәренә кадәр килгән тәмәкесен теш арасыннан тартып чыгарды да, эре бер кыяфәт белән лачкылдатып төкергәннән соң, тәрәзә ачыгыннан юлга ыргытты.

— Өйләнүен мин дә өйләнер идем. Хатының тәртипле булса, мишәйт итми анысы... — диде Чәчкә.

— Тәртип беркемгә дә мишәйт итми!

Әмма Рита эченнән башкачарак уйлый иде. Кычкырып торган укытучылыгы аның үзен дә туйдырды. Ул, әллә нинди бер үчлек белән, моңа кадәр кагылырга да җөрьәт итмәгән вафлиның шоколадын умырып алды да тел артына ыргытты.

— Ну ирегезнең бәхет бар инде!

— Шушындый чибәр, акыллы хатынны үзеңнеке ит тә, ничек бәхет булмасын?!

— Ашыктык шул, брат, өйләнеп ашыкты-ы-ык! Әллә ул ир куенына иртәрәк сеңгәнме?

— Ничек итеп шушындый чибәр хатынны юньле ир кара төнгә каршы юлга чыгарып җибәргән диген әле син?

— Үзе төнлә йөрергә курыкмаганга инде, — дип авыз кыйшайтты Рита.

— Син дә курыкма: акыллы, матур хатыннарны өенә кадәр кайтарып кую — безнең гадәт... — Чәчкә сүз уйнатудан әле һаман туймаган иде.

— Мунча керергә җай чыкты, — диде шофер.

— Иренә кирәк булмагач та, бездән арткан кеше юк...

Рита сүз агышын үзгәртергә уйлады:

— Менә шулай. Мактыйсыз да мактыйсыз. Ә бит матур да, акыллы да түгел мин. Иремә дә кирәгем юк икән. Һәм, әйтсәм дә, урталай өзәм: һам!

Чәчкәнең ике арада, һавада, хәрәкәтсез калган кулын эт тешләдемени — дертләп куйды да, айнып киткәндәй, каршысындагы тотынгычка үрелде. Дәррәү көлешеп алдылар.

— Минем шаяртканнарга үпкәләмәгез инде. Бәлки, күңелегезгә тигәнбездер, — диде Чәчкә, кинәттән үзгәреп.

Ә бит Рита Чәчкәгә һич кенә дә үпкәләмәгән иде. Аның бердәнбер хәсрәте — тизрәк авылда калган кызы янына кайтып җитү. Сагынуына, ялгызлыгына түзә алмыйча, төнгә каршы юлга кузгалды шул. Уйламаганда-нитмәгәндә төенчекләрен төйнәде дә ерак юлга чыгып китте.

— Балагыз бармы? — дип сорады Чәчкә нигәдер моңсу гына.

— Бар. Кызым. Әле шуның янына кайтыш.

— Без сине өеңә кадәр илтеп куярбыз. Но юлыбыз —Балтачка гына.

Рита, кирәкмәс дигән сыман, баш чайкады. Шофер сүзне башкага күчерде:

— Сеңлем, машина сатучы танышларыгыз юкмы? Базарга сугылган идек тә, бер рәтлесе дә күренмәде. Бәяләр дә юнь түгел.

— Үзем сатам. Йөрергә кешесе дә юк, — дип җавап бирде Рита. — «Жигули». «Җиделе».

— Сине каян табарга соң?

— Кәгазегез булса, адресымны язып калдырыр идем дә... Өйдә телефон юк шул.

Һичкемдә бер кисәк кәгазь табылмады. Аптырагач, Рита, сумкасындагы китабын алып, адресын шунда язды.

Чәчкә абыйсы, китапны күргәч, беравык сүзсез калды. Әле тышындагы сурәткә, әле Ритага карап, нидер әйтергә азапланды, аларның бик тә охшаш икәнлеген аңлагач:

— Ә бит минем монда язылган исемне кайдадыр ишеткән бар! — диде, нәрсәнедер тәгаенрәк исенә төшерергә тырышкан бер кыяфәттә.

— Иремнәндер инде, — дип куйды Рита битараф кына.

— Туктале, кайда гына ишеттем соң?..

— Кызлар яратам, дисез, бергәләп кызлар янына баргачтыр инде, — дип көлемсерәде ханым.

— Син нәрсә-ә-ә... Минем иптәш шагыйрьләрдә мондый чибәр хатын бар идемени?! Җыенысы аңгыра-ахмакка өйләнеп беткәннәр дә йөриләр шунда теләсә кайда кайгы бушатып...

— Гадел Кутуй урамындагы общагаларда, дип тә өстәгез инде, — дип көлде Рита.

— Ә син аны каян беләсең? — Чәчкәнең күзләре маңгаена менде. Куллары, кыбырсып, кайракланган чалбарының тез башларын ышкырга тотынды.

Рита һични белештермәстән сөйләшә иде. Әйтерсең аның теле белән кемдер җавап бирә, әйтә. Ул боларга Чәчкәдән битәр аптыраган.

— Исеме Рәистер инде аның? Шагыйрь дустыгызның...

— Әлбәттә! Әйт, аны каян беләсең? Точно! Мин бит исемеңне аннан ишеткән!

Чәчкә шофер тәрәз төбенә ыргыткан пачкадан үзләре кебек таушалып беткән бер сигарет тартып чыгарды. Бик озак әвәләгәннән соң, кабызып та тормыйча, кире урынына кыстырды.

— Әйт, кызый, син каян беләсең?

— Ә нәрсә дип әйтәсең...

— Кызый, син юри туктаткансың безнең машинаны. Мине оялтыр өчен!

— Оят — мунчада гына, — дип, шофер сүзне кабат уенга борырга чамалаган иде, Чәчкә аңа кул гына селтәде.

— Ә бит миңа, чыннан да, оят...

Юллар, кук, агачлар — барысы бергә буталды. Батып баручы кояштан һәрнәрсәгә күчкән кызыллык әлеге бөтерчектән шомлы, серле бер күренеш ясаган. Шул бөтерчекнең уртасында — шундый ук хәвеф төсендәге Чәчкә. Үзе сөйли дә сөйли.

— Чәчкә абыеңа синнән оят. Синең булдыксыз, ямьсез, аңгыра һәм тагын әллә нинди начар якларың барлыгына ышанып яшәгән өчен оят! Эх, үзем күреп гашыйк булмасам икә-ә-н...

Ниһаять, эңгер-меңгерле кыр үз урынына утырды. Сөяркәләрдән ир хатыны турында яман сүз ишетү бик тә гади бернәрсә бит ул. Чәчкәнең соңгы сүзләренә Рита әллә ни илтифат та бирмәде. Әгәр Рәис... Әгәр Рәис тә шулай алдаган булса...

— Сине тетеп, күпме шәраблар эчелгән! Хатыннар куенында, элек очрашкан кызларыбызны татлы телгә алганда да, сине каргап, күпме уртак төннәр уздырылган. Билләһи, оят!

— Һе, минем иман, дип сөйләнгән шагыйрем...

Чәчкә,Ританың үзалдына әйтелгән сүзләрен ишеткәч, бик үк өнәп бетермәгән булса кирәк:

— Бушка аракы эчертүченең күңелен күреп, нәрсә сөйләнмәс... Эш андамыни? И-и... шагыйрьләр турындагы дөньямны үзеңне күрсәтүең белән җимердең син, кызый... Әйт, белеп туктаттыңмы? Юри юлыбызга чыгып бастыңмы? — дип сорады ул кабат.

— Юк. Мин туктатмадым да бит. Үзегез ишек ачтыгыз. Аннан... Кешене ертыкка ямау итеп буламыни? Тормышның җөе үзе китмәсен икән ул...

— Балконнарга чүпрәк буйлап менәбез бит. Адәм көлкесе. Шундый хатыным булсамы? Минме? Хәер, үземнеке өчен үкенмим. Без гөрләтеп яшибез. Менә синең алда оят. Шагыйрьләр диген, ә?.. Гашыйклар диген, ә? Дөресен сөйләүчеләр диген. Имеш, кеше карамаслык хатынга өйләнгән дә артымнан чаба, дип сөйли бит әле чәчбие дә, — дип, торган саен ныграк өзгәләнде Чәчкә. — Без — нәрсә?! Без — кара халык. Безгә дә килешеп бетми әле ул, менә болай, чит бер хатынга, гашыйк булдым, дип сөйләнеп утыру. Гаепләмә инде. Уеннан уймак чыкты.

Шофер сүздән арыды. Ул болай ук буласын көтмәгән иде, ахрысы.

— Без сине хәзер өеңә кадәр үк... — дип сөйли башлаган иде, Рита аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

— Кирәкми! — дип бүлдерде дә машинаны туктатырга кушты. Оялаган бушлык йөрәген урталай ярсын өчен, тагын бер сүз җитә иде.

Олы юлдан, әйберләрен күтәреп, кара төнгә кереп китте ул. Кешесез кыр, хәсрәтсез төн, уйсыз адымнар һәм бердәнбере — кызы гына кирәк иде җанына. Күпмедер киткәч, тау башында басып калган машинага таба карады. Ул әле кирегә, үз юлына таба борылмаган, кызыл күзләре белән Рита киткән якка текәлгән...

*1998*

## Көзге каеннар

Кар ява да ява. Аның туктарга уйлаганы да юк. Кай көннәрдә, болытлар таралып китсә, тагын да яманрак. Әлеге кар, эреп, бөтен урамны баткакка әйләндерә. Сыйныф җитәкчебез, олаеп кияүгә чыкмый калган Рәйсә Сабировна, таң тудымы, бот төбеннән эш бутыйларында, кулына озын гына таяк тотып, юламан кебек, безне кырга алып бара. Ә без... Карлы-яңгырлы җилне җиңәрбез шикелле җырлыйбыз да җырлыйбыз. Мондый чакта җырлар күбрәк русча:

Как войдешь за порог, всюду — иней,
А из окон...

Бактачы хатын-кызлары, калын шәлләренә төренеп, сырма-пәлтәдә капка төпләрендә баш селкеп кала:

— Йә Хода, әле дә җырларлык рәтләре бар микәнни соң боларның?

Яннарына чүмәшеп махра тарткан ирләр күзендә — көлемсерәү. Киленгә ярарлык кызлар килгән бу ел. Әле кайчан гына алар үзләре дә авылга бәрәңге җыярга җибәрелгән училище укучылары артыннан чапканнардыр...

Аларга да сәлам биреп үтәбез:

Бактачының кибетендә
Папируслар санаулы.
Шакир абзый, кич клубка
Җибәрә күр малайны.

Ә кич җитеп эшләр беткәч, ашап-эчеп алгач, тагын җырлыйбыз без. Җырлый-җырлый резин итекләребезне юабыз, өстәл җыештырабыз, урын җәябез.

Әйтерсең карлыккан тамакларны җыр белән язабыз:

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,
Боты озынга күрә, —

дип башлый Сүрия, безнең, уртага чыгарып, уенга куйган бармакларны саный-саный.

— Трактырис, майлы керис... — Монысы — Рамилә җыры.

Рәйсә апабыз чырык-чырык көлә. Татарча белсә дә, русча гына сөйләшәсе дип инанганга:

— Ой девчонки, умора-а-а... — ди ул, сузып-сузып.

Бераздан укытучы дәрәҗәсендәге кеше өчен ялгыш сүз ычкындырганлыгын чамалап һәм бәрәңге бу-разнасына салган дәресләребезне кызганып:

— Давайте-ка заниматься правописанием, оставьте всю эту чепуху, — дип өсти һич кенә дә акцентсыз. Күрше авыл марҗалары да татарчарак сөйләшкән яктан булгач, шуның белән үтерә дә куя ул мине. Ничек каршы әйтәсең?! Бу бит, кем әйтмешли, ата марҗа! Башкалар да килешә. Кичен клубка җибәрмәс дип уй-лыйлар, ахрысы.

Төркемдәшебез Салават, куратор турында сүз чыкканда, безгә вакытлыча булса да түзәргә куша, ни-чек тә, үзем булса да китәрлек итәрмен мин аны, ди. Нервлары какшаган инде, алдагы елгы студентлар белән эшләргә дә сабырлыгы бер генә атнага җиткән, имеш. Якты өметләр белән, безнең тыңлаусыз ма-лайлар чыгырыннан чыгарыр да менә китәр, менә китәр, дип, ай да үтте, икенчесе дә үтәр, укытучыбыз үз-үзенә бу елда нык ышанып килгән кебек тоела... Русча аралашырга әйдәштергәли, әмма безнең татарча җырларга да ияләшеп бара инде ул.

Сәгать теле тугызга якынлашса да, кулларга каләм алабыз. Кем — өстәл тирәсендә, күбебез, идәнгә ятып, дәфтәрләребезгә «а», «б» хәрефләрен тырмыйбыз, «әни», «әти» кебек сүзләр язабыз. Рәйсә Саби-ровнага кәгазьдә минем каләм калдырган эзләр ошый, әмма артыгын мактап ташлавыннан курыккандай:

— Даже странно, что так ровно у Вас получается, однако, если у меня четверку получите, считайте, вам повезло, — ди.

Алдамаганы хәйләкәр җыерылган күзләреннән ап-ачык күренә. Сарандыр ла, сарандыр...

Тырактырис, майлы керис,
Майлый да карап тора.
Башкалары булмаганда,
Ансы да ярап тора.

Бишле куймагач, дүртлесе дә ярар инде!

«Нам везет» — матур язып, хуҗабикә Суфия апа ярдәме белән дә, клубка чыгарга рөхсәт алабыз. Инде үзеннән дә зуррак баянын иңнәренә асып, сазлыклар аша узганда да, бармакларын баскалаудан тукта-тмыйча, ирләрчә адымнар белән алдан Сәрия бара. Эх, әгәр баяны булмаса, әтиемнекеннән дә зур йод-рыклары белән теләсә кайсы егет кисәгенең башын ярырлык бит ул, дим, эчтән генә көнләшеп. Ул тездән су булганда да, чаңгыда йөргән кебек, урам уртасыннан шуып, куллары белән һава этеп кенә, авыл урам-нарын уза.

Җыр дигәннәре! Телгә килә дә тора бит:

— Дурманом сладким веяло...

Фирдәвеснең тавышында тимер чыңнары бар. Дөрес көйләсә дә, мишәркәйне җыр укытучылары ап-тырата. Тавышың башкаларныкына кушылмый, диләр.

Мин борылыштан узганда, җырлаганга салынып, авызны селкетеп кенә барам. Күз — гел читтә. Ша-милнең берәр капка ышыгында сагалап торуы, эләктереп калуы бар. Мондый утсыз урамнарда өстеңә килгән атны да күрерлек түгел. Ул да булмый, лампочкасы махсус алдан ук ватып куелган багана яныннан үткәндә, аның капыл гына икегә әйләнгәнен шәйлим.

— Әйтәсе сүз дә, бирәсе әйбер дә бар, кал әле, — ди Шамил, авыл малайларына хас эрелек белән. Эшем кешесе!

Төке... Юк, килешми, әйтә алмыйм. Һич югы, кычкырып җырга кушылырга кирәк:

Вся жизнь впереди, надейся и жди!

Кызлар әкренәя. Алар хәлнең нинди борылыш алачагын көтә. Бәхеткә, клуб турысына килеп тә җит-кәнбез.

— И-и-х! — ди Шамил, кеше рәхәте өчен эшләп арган ат үкенече белән. — Синең хакка Арчага кадәр барган булам бит әле! Менә дигән мари кызлары барында!

Бу авыл егетләренең гадәтен әйтер идем! Ни булса, шул мари кызларын телгә алалар. Кочтырмасаң, сөйләшмәсәң дә, тәкәббер булсаң да... Миндә кирелекнең болардан тышы да — артыгы белән. Клуб ише-геннән үткәндә, Шамил, чия төсендәге балонья курткамның тукымасын истәлеккә ертып алырдай булып, җиңнәремнән эләктерә:

— Каласыңмы син, юкмы?!

— Фи! Торна!

Клуб эченнән Сәрия дә инде «Ак кәгазь торналар»ны җырлап маташа. Бу Шамилне тагын да үтерә.

Киң итеп ачылган ишекнең як-ягында, эштән кайтып, киемнәрен дә алмаштырып тормаган авыл егетләре. Андыйлар эчкә бик узмый. Тәмәке пыскытып, кызлар таралганны тышта көтеп тора. Караңгыда киемнең ниндилегендә кемнең ни эше бар?

Ыспай да инде бу Шамил! Авыл егетләренә һич кенә дә охшамаган. Кара күзләрендә әллә нинди серле чаткылар бар! Маңгай өстенә шук күзләр кебек бөдрәләнеп-бөдрәләнеп төшеп торган чәчләрендә әнә көз көнендә борынны ярып керерлек хуш исләр... Иреннәрендә — мин аңларга курыккан мәгънәләр...

Түгәрәкләнешеп басабыз да шейк биибез. Баянга, рус,татар көйләренә. Шамил күзләреннән ераграк торыр өчен, кешеләр артындарак биим. Ул түгәрәккә керми. Тешен кысып күзәтә. Мине матур бии дип саный микән ул? Әллә юкмы? Мәнсез, авыл гыйбады — танцыга да чакырмый бит!

Шамилнең тешләре, мин башкалар иңенә таянып биегәндә, тагын да ныграк кысылалар. Бу тешләр арасында менә үземә ничек тә кысылмаска! Иреннәрне сак кына да үптермәскә... Аның матурлыгы хакында уйламаска! Оялмыйча сөйләшеп торган дигән яманатны чыгармаска! Башта — Шамилдән котылуның мең төрле планнары.

Без кайтабыз. Тотынышып. Бер-беребездән һава торышының теләсә кайсы шартларында да аерылмаска сүзләр бирешеп. Шамилләргә, Камилләргә өстән көлеп эндәшергә җөмләләр хәзерләп.

Бу якта мари кызлары белән бергәләп егетләр мунча керәләр икән, дигән сүзләр йөри. Шул сүзләрдән дә куркыта, өшетә. Мунчалары урамга якын торган каралты тирәсеннән узганда, әллә нинди куркыныч хәлләр күз алдыннан үтә. Без бер-беребезгә тагын да ныклабрак ябышабыз.

Капка төбендә кайсыбер көннәрдә, әлеге озын таягын күтәреп, Рәйсә Сабировна көтә. Ул булмаса — Бактачы егетләре. Төрле ялганнар сөйләп, вәгъдәләр биреп, дөресрәге, мәңгелек сөюләр турында фәлсәфә сатып, без капкадан керергә рөхсәт алабыз. Алар да, шундый ук сүзләр ярдәмендә, безне туры юлдан яздырмакчы булалардыр шикелле...

Кай көнне — сугыш-тарткалаш, кай көнне хәйлә белән генә узарлык бу Суфия апаның биек капкасы да, хәерсез! Без тагын, җырлый-җырлый, бутый юабыз:

Минем иркәм Армиядә,
Сагыз кайнатам, дигән...

Иртәгә китәсе... Бу авылның бәрәңгесе бетте. Күлле Кимегә күчерәләр икән.

Таң атар-атмас, җәяүләп, укытучыбыз артыннан тезелеп, без шул якка юл тотабыз.

Мыш-мыш килеп, артыбыздан мескен Шамил йөгерә. Затлы киемнәрен дә киеп тормаган. Күзендә — яшь, кулында — утыз өч тиенлек шоколад. Аны кичә Арчадан минем өчен алып кайтканлыгын Салават әйткән иде инде, әмма, җанны өшетеп:

— Мари кызларына да алган, — дип өстәде.

Күчтәнәчне кире каккандай итенәм. Шамил мине янәшәмдәге каен белән кушып эләктереп ала. Күкрәкләрен дөмбәсләсәм дә җибәрми. Йорт казлары кебек тезелгән кызлар баралар да баралар.

Челтәрле күпер янына
Озата барган идем.
Ялгыз ак каен янында
Аерылып калган идем.

Челтәрле күпергә киләм,
Сине сагынган саен.
Янына бер имән үскән,
Ялгыз түгел ак каен...

— Җибәр инде, Шамил, артка калам бит, — дим миңа беркемгә дә әйләнергә өлгермәгән егеткә. Аның кара сырмасыннан, күңелгә шикләр салып, көзге агач төпләрендә күксегән яфрак исе килә...

Күзләремне чытырдатып йомам, карадан кызарып киткән куелыкта шушы шоколадны ашап торган мари кызы пәйда була. Менә ул сары яфраклы каенкайга әверелә. Керфекләремне күтәрәм: әлеге каен кызының арабызда торганлыгын күрәм.

* * *

Күлле Киме һич тә кочак җәеп каршыламады. Безне, башкалардан аерып, клуб каршысында диярлек салынган йортка урнаштырдылар. Хуҗабикә юмарт һәм сыйга оста, шаянрак та, батыррак та бер хатын бу-

лып чыкты. Маргаринлы бәрәңге белән сыйланып, бармак помадкалар белән чәйләгәннән соң, кич чыкканда кирәкле киңәшләрен биреп, җилкапка төбенә кадәр озатты ул.

Клубка барып җитәрәк, Сибгат агаларның тумачаларына урнашкан Рәмзияләр дә безгә килеп кушылдылар.

— Сак була күрегез инде, кызлар! — диде ул, бик тирән серлелек белән. — Авылның иң усал егете яшәгән йортта торабыз. Безгә тимәс тиюен, сезнең хәлләр шәптән түгел. Әнә үзе дә килә.

Клубка шәп кара курткадан, фырт кара эшләпәдән, менә без кем дигәндәй, йодрык кадәрле корсагын булдыра алганча кабартырга тырышып, таза бәдәнле бер «давай» кереп бара иде.

Егетнең, ишекне узганда, күзе белән кызлар исемлегенә мине дә алуын шәйләп, кот ботка төште дә, ничек тә исән кайтырга дигән уй «вечер» буе тынгы бирмәде. Ничек тә егетләргә бирешмәскә!

Электрон баянга да, яңа көйләргә дә исебез китмәде безнең. Бу зур клублы, заманчарак авылда күңелдән җыр китте. Җыр китте! Мәңге китмәс кебек шат кичләр юкка чыкты. Планнар, хыяллар гына үзгәрмәде.

Ничек тә исән кайтырга! Юаш Сибгат агайның усал кардәшенә бирешмәскә! Клуб ишегенә бергәләп атылырга да, чыккач та тизлекне киметмәскә, капкага кадәр йөгерергә исәп тоттык һәм шулай эшләдек тә. Эшләпәле егет белән иптәшләренең планы да шундыйрак булган, ахры. Алар, капка төбенә җиткәч, безнең һәммәбезне эләктереп тә алдылар.

Шул вакыт йортның урта тәрәзәсе ачылып китте, һәм аннан зур уклау тоткан хуҗабикә ханым сикереп төште дә моңа кадәр бик батыр күренгән авыл егетләрен йорт тирәли йөгертә дә башлады. Калай әтәчләр берәм-берәм качып та беттеләр.

— Әйдә чык! Сөйләш! — диде аннан апабыз, капканың чит баганасы артындагы караңгылыкка ишарәләп. Баганадан аерылган шәүлә әкрен генә миңа таба якыная иде.

Карале, Шамил, Шамил ич бу!

Шамил мине соңгы тапкыр күреп калу өчен килгән булып чыкты. Матур сүзләр дә сөйләмәде, гадәттәгечә, йөр, дип тә ялынмады, куркытмады да, үбеп калырга дип тә алгысынмады. Уфтанды, көрсенде, елмайды, өйалды ишегенә сөялеп, моңлы күзләре белән нидер аңлатырга һәм аңларга теләгәндәй, бик озак карап торды. Бактачының батыр егетен танымадым. Таңда мине кочарга җөрьәт иткән Шамил идеме соң бу?!

Юк, кирәргә — каеннар арасында юктан гына туа башлаган хисләрне уятмаска, үстермәскә! Тыныч күренергә тырышып, ишек келәсенә үрелдем. Шамил кулымны тотарга ымсынгандай итте дә, кире уйлады булса кирәк, юлымнан туктатмады.

— Хуш!

— ...

Шамил, Шамил... Ә бит матур, мур кыргыры! Бу көздә беренче мәртәбә кояшлы туган көннән дә матуррак! Юаш та, моңсу да икән әле — вакыты белән. Әдәпле дә. Әйе, матур, теләсә кемнең үзеген өзәрдәй матур!

Бер ай дәвамында бүгенге Шамил кайда булган ул? Итагатьле Шамил кайда булган? Узган таңда тупас итеп үземнән этәрмәвем үзгәрткәнме аны?! Күтәрелеп Шамилгә карадым. Юк, үкенмәскә, кире уйламаска! Яңадан аңа карамаска! Тиз генә кереп китәргә. Аның өзелә башлаган өметләрен терелтмәскә!

Үземне җыйдем. Кердем. Шамил дә киткәндер. Таңга кадәр йоклый алмадым. Каеннар арасында, кара сырмадан... моңсуланып калган Шамил сурәте; качканда — тотып ашардай булып арттан куып йөргән, көткәндә — сүз әйтергә дә батырчылык итмәгән Шамил холкы турында уйладым.

Икенче көнне иртүк йорт тирәбезгә трактор килеп туктады. Тиз генә утырырга кирәклекне, ерак басу түренә барырга кушылганны әйттеләр. Ашык-пошык кына хәзерләнеп, безнең йорт кызлары трактор арбасына төялде. Җырлар басынкы, күңел төшенке, көн күңелсез иде. Нигәдер гел хушлашу җырлары җырладылар. Алары да Күлле Кимедә дә үзебезнең барлыкны сиздерү өчен генә башкарылган кебек булды.

Килеп җиттек. Трактордан төштек. «Тырактырис, майлы керис» кул биреп кенә төшергән була, кемнедер күтәреп тә ала. Укытучыны, бригадирны көтә-көтә аргач, төш җиткәндә генә эшне аңладык. Үзләре белән йөрмәгән өчен, авыл егетләре безне басу түренә олактырганнар икән.

Идарәдә белгәннәр. Алып кайтырга трактор җибәргәннәр. Калай чиләкләребез белән шалтыр-шолтыр килеп, дизель тракторының чалшайган арбасына кабат төялдек. «Майлы керис» кул да сузмый, әйберчәйберләребезне дә җирдән алып бирми. Бер читкә китеп, ачу белән карап тора.

Юл нигәдер озынайган. Нәрсәдер юкка чыккан, көзгә матурлыклар кимегән кебек. Иртә яуган карлар эреп, матур көзгә кереп барган кырлар да сөендерми. Сәриянең дә күңел җырда түгел. Бөтен җитдилеге белән шаян егетләрне сүккән була.

Бактачы ягына карап уйланып кайттым. Шамилнең сырмасы кебек кырлар инде тәмам бушаган, безнең дә эш бер-ике көнлек кенә калган. Басу өстеннән, аерылу авазлары салып, Мари урманнарындагы күлләрдән күтәрелгән торналар оча... Шамил аларны күрә микән? Ул мине уйлый микән? Мине уйласа уйлар, авылның иң фырт егете кырда пычранып йөрмәс... Ясап куйган шәһәр кешесе... сөйләшергә дә өйрәнсә...

Эчтә бушлык. Җил көзнең соңгы яфракларын күңелнең бер почмагыннан икенче почмагына куып йөртә. Гадәтем буенча, күзләремне йомам. Ике авылны тоташтырган каенлыкны күргәндәй булам. Ак каеннар таш тәтәйләр тезгән күлмәкле мари кызларына әверелә. Алар арасында Шамил юк. Тел очыма ул ашаткан шоколадның яшь чыгарырлык ачысы килә.

*1996*

## Кәҗә ите

Муллагали Сәкинә карчыкның вафатыннан бихәбәр иде. Үзе бәйләнгән казык тирәсендә чирәм утлап йөри. Шулай да кәҗә күңеле белән сизенде: өйдә нәрсәдер булган. Икенче көн инде бөтен туган-тумача тыз-быз килә, ә карчыкның ишектән чыкканы күренми. Өченче көн дигәндә аңлады: карчыкның олы улы Сахалинда яшәүче Маратның капкадан керүенә ярты сәгать чамасы узгандырмы-юктырмы, Сәкинә карчыкны калай кабыкка чыгарып салдылар да Муллагали утлап йөргән чирәмлек кырыендагы зиратка алып кереп киттеләр. Авылдашларының кем өчен кабер казыганлыклары да Муллагали башына әнә шунда гына барып җитте. Чөнки зиратка якындагы шәһәрдән, көн саен ук булмаса да, ай саен мәет кайта иде. Бөтенләйгә дип туган нигезеннән чыгып киткән авыл кешесенең күбесе яңадан үз туфрагында урын таба торды...

Карт-карчыклардан гайре беркем яшәмәгән бу авылда, көтү чыкмаганга, Муллагали сөт бирүче бердәнбер җан иясе иде, шуңа күрә, Сәкинәттәйләргә чәйгә килүчеләрнең саны бихисап булып, Муллагали сөтенең тәмлелеге телләрдән төшмәде.

Муллагали мактауга лаек зат булса да, Сәкинә карчыкның уллыкка алган оныгы Рәшит белән генә дуслашып китә алмады. Дуслашыр иде дә, әти-әнисе үлеп, шулай ук әби-бабасы тәрбиясенә калган Зөләйха Рәшитне нәкъ менә аның аркасында яратмады. Кайсыдыр әдәби әсәрдә, сыер асрарга хәленнән килмичә, кәҗә генә тоткан геройдан авторның көлүен сизгән Зөләйха малайның кәҗәле йорттан булганы өчен эченнән генә гарьләнә иде. Аның бу хакта Рәшиткә теле белән әйткәне булмаса да, һәр нәрсәгә сизгер малай ике арадагы салкынлыкның сәбәбен шундук аңлады һәм якты дөньяга килгәненнән бирле үзенең яшәү чыганагы булган Муллагалине озын гомерлелеге өчен гафу итә алмады. Дөрес, бу авылда кәҗә халкыннан инде башка берәү дә калмаганга, ул үз токымының соңгысы иде.

Эре сөякле кәҗәләр бала чакта Рәшитнең сөт әнкәсе дә, аты да, дусты да булды, ә инде Рәшитнең күңеле күрше кызы Зөләйхага төшкәннән соң, күз көегенә әйләнде.

Муллагали, печән утлый-утлый, әнә шулар хакында уйланды. Ул боларның барысын да кайдан белә иде, дип сорарсыз. Муллакәҗә яшәгән һәр көне турында түкми-чәчми — Муллазәйнигә, Муллазәйни — Муллагабдрахманга, Муллагабдрахман — Мулласалихка, Мулласалих Муллагали кәҗәгә җиткерде. Бу авылда кәҗәгә исем бирү гадәте юк иде, аларның барысын да Сәкинә карчык ни өчендер ирләр исеме белән атады. Үләр алдыннан күрше авылдан кәҗә бәтие алып кайткан Муллаҗан абзый исеменә ятышлы булсын дигәндерме, әллә ирләрне олылыкларга күнеккән, нәсел умырткасы санаган мөселман карчыгының аңлы эше идеме — бу турыда сорарга хәтта Рәшитнең дә уена килмәде.

Җиргә сөйрәлеп барыр имчәкле кәҗәкәйләр әлеге хәл белән килешмәсәләр дә, кешеләр телендә сөйләшә алмаганга, ризасызлык белдереп мәэлдәп карасалар да, аларның нәрсә дә булса әйтергә теләве беркемнең дә башына кереп чыкмады. Шулай итеп, Аллаһыга тапшырып, бу нәсел ирләр исеме белән яшәп китте.

Хәер, буыннарны дәвам итүне ир кәҗәләргә тапшырсак, күпчелек очракта ул ике буыннан артмаган да булыр иде. Тәкәләргә дөньялыкта да рәт күрсәтмәделәр, соңыннан да... Көзен, суеп, йә хөкүмәткә тапшыралар, йә кыш буена өй борынча хезмәттә йөртәләр-йөртәләр дә язда итен этләргә ыргыталар. Авылда кәҗә ите ашау гадәте сакланмаганга, Сәкинә карчык та һаман шулай эшли килде.

Соңгы елларда Муллагали, казыкка бәйләнгән бердәнбер җан иясе булып калгач, бу җәфадан да котылды. Инде менә аркасыннан кага-кага сөтен сауган, сусыл бәрәңге, кипкән печән белән сыйлаган Сәкинә карчык та юк. Әбисе урынына җилемен тарткан Рәшитнең кулларын Муллагали өнәп бетермәде. Савытка төшәм дип ашкынган ярты сөтне калдырып аптыратты алар, ими төбендә җыелып калганы иң

куесы, иң татлысы, дип, малайга аңлата алмаганга, арт аягы белән тибенүдән башканы эшли алмады. Рәшит исә моны үзенчә — Муллагалинең сауган сөтне түгәргә теләве дип аңлый иде.

Сәкинә карчыкны җирләү белән үк, туган-тумача каралты-кура язмышын хәл итәргә кереште. Әбинең калада яшәүче алты улы, ике кызы, түгәрәкләнеп, өстәл тирәсенә утырдылар. Шуларның иң почмактагысы Рәшитнең әнисе булып, улын ташлап киткәннән бирле йорт ишегеннән беренче мәртәбә атлап керсә дә, аның Сәкинә карчык вафатын кемнән ничек ишеткәнлеген сораштырмадылар да. Әллә үлем-җитем кайгысы, әллә башка бер-бер хәсрәт оныттырды.

Рәшит әнисе үзен дөньяга китергәндә вафат булган дип белә иде, әллә шуңа гына малай янында кирәкмәгән нәрсәләрне кузгатмадылар микән? Шулай да бу көнне, көтмәгәндә-нитмәгәндә, Рәшитнең башында, әнкәм кабере кайда икән, дигән сорау туды.

Өйне сатып алырга теләүчеләр тиз табылды. Урыны да әйбәт, шәһәргә дә якын, дип, бер кала бае алырга булды. Рәшитне дә кертеп, аны тугыз тигез кисәккә бүләргә килештеләр. Малай бу чакта күрше кызы Зөләйха белән капка төпләрендә утыра иде. Үзенең язмышы башкача хәл ителгәнне белмәгәнгә:

— Чык миңа, Зөләйха! — диде ул. — Синең белән бергә ничек тә яшәрмен. Ялгызыңны гына калдыртып, армиягә дә алмаслар.

— Тиле! Укыйсы бар бит әле! — Рәшит сүзләреннән Зөләйханың күзләре маңгаена менгән иде.

— Булса соң! Хәзер закун ничә яшьтә өйләнсәң дә тыймый, диләр. Чык инде, Зөләйха...

— Кәҗәле егеткәме? Ни за что! Мин кә-җә и-те а-ша-мыйм! — Шулай диде дә кыз үз капкаларына кереп югалды.

Озакламый Рәшитнең үзен дә йортка чакырып алдылар. Өстәлнең тугыз җиренә тигез итеп өеп куелган акчаларның берсен малайга таба этәрделәр:

— Менә монысы синең өлеш.

— Нинди өлеш тагын?

— Без, йортны сатып, гадел рәвештә бүләргә булдык, алучысы барда, хәзер Мунчалыга авыл сәвитенә китәбез, — дип аңлатты Алма апасы. — Әбиең белән үскәнгә, сине дә катнаштырырга булдык.

Малайның башына тимер кендек белән суктылармыни. Беравык баскан урынында тирбәлеп торганнан соң, акчаны да алмыйча, өйдән чыгып йөгерде.

Кая, кем янына бара, үзе дә белми иде. Берникадәр ара үзгач, кемнеңдер тавышын ишеткәндәй булды. Ул, Зөләйха түгел микән дип, артына борылып карады. Шунда казыктан ычкынган Муллагалинең артыннан чабуын күрде. Туктады, көтәсе итте.

Шабыр тиргә баткан Муллагали, мәэлдәрлек тә хәле калмыйча, авырайган җиленнәрен тузанлы юлга салып, малай алдына килеп ятты. Күзендә бәхетсез моң иде. Бу гөнаһсыз җан иясенә нәрсә әйтәсең, дип уйлады Рәшит, әллә кайдан күңел түреннән миһербаны кузгалып. Шушы нәсел биргән сөттән ясалган кан ага иде аның тамырында. Ул бүген, үзе дә сәерсенеп, әнә шуны уйлады. Юл кырына утырып, Муллагалинең бераз хәл җыйганын көтте дә китәргә кузгалды:

— Әйдә, Муллагали, янәшәмнән бар, бавыңны ычкындырмыйм, йә шәһәрдә адашырсың.

Гомерендә дә кәҗә ите ашамаска сүз биргән малай инде бу көнне тагын бер кат күңеленә туганы урынына калган Муллагалине пычак астына куймаска дип сүз беркетте.

*1997*

## Үч

Бу үчне ул инде дистә еллар күңел түрендә саклаган иде. Менә-менә бәреп чыгам дигән вакытларында да тыеп, тагын да эчкәрәк кысрыклап яши бирде, иң-иң кирәкле мизгелгә хәзерләнгән сүзләр әрәм кебек тоелды аңа.

Гомер үтә, һәм зур әсәрләргә сакланган үчлекле сюжет үзенә җылы куыш биргән җан иясе белән уйламаганда-нитмәгәндә китеп тә барырга мөмкин иде.

Олыгая төшеп, тормышның гел шундый вак-төякләр белән ямьсезләнүен күп күргәч, ул әлеге үпкәләрнең мәгънәсезлеген, нигезенең шактый какшаулыгын да аңлады. Кайчандыр үз-үзенә биргән сүзләргә тугры калмаса, яшьлегенә үк хыянәт итәр санапмы, әллә чынлыкта да оныта алмый идеме, үч алу уен башыннан бер генә минутка да чыгарып ташламады.

Техникумга аяк баскан көннәре иде. Ниһаять, мәктәптә иң яраткан физкультура дәресе дә килеп җитте. Җәлпәк яңаклы, елтыр күзле, калынча гына гәүдәле мишәр мөгаллим төркемне тезеп бастырды да, укучыларга куелган гомум таләпләрне аңлатканнан соң, уку йортыннан бик үк ерак булмаган алма бакчасына

алып китте. Хәер, еллар узгач, ул анда нәрсә үскәнен дә хәтерләми башлады, әмма койма тирәли ниндидер агачлар тезелешеп киткәнлеге тәгаен иде.

Гәүдәгә күпкә буйлырак булсалар да, Равия белән ярышырлыклар аз икән. Сикерүдән башка һичнидә ул беренчелекне бирмәде, һәм, үзе теләгәнчә, аны шунда ук чаңгычылар секциясенә язып та куйдылар. Осталык сынаган беренче дәрес үтте китте.

Көзнең һәр киче елга-чокырлар, болыннар аша йөгереп, төрле күнегүләр ясап уза торганга әйләнде.

— Боламыклар, тагын бер круг!

— Пешкән шалканнар! Басыгыз тезелеп, ыштаннарыгызны күтәреп!

— Өч, ике, бер, марш! Кыршау тәпиләр...

Инде ярым татарчалаштырылган бу командаларга күнегергә, арт һәм ал якларның сүзлекләргә дә кертелеп бетмәгән атамаларына игътибар да итмәскә кирәк булгандыр. Сабырсызлыгы белән дан алган Равия түзмәде:

— Әгәр телегезне чистартмасагыз, Җәмил Зәйнетдинович, мин секция исемлегендә юк, — дип ычкындырды.

Замогы ватык зәңгәрсу спорт киеменнән урта тирәсе белән бүселеп үк чыккан Җәмил абыйсы бер агарды, бер күгәрде, әмма «тәпиеңә чуан чыккыры»дан артыкны җавапка кайтара алмады.

Равия, шуның белән эш бетте дип санап, фатирына китте.

Директор янына чакырып сүгүләр дә, гел бишкә генә укыган Равия турысына физкультурадан журналда дүрт куюлар да ярдәм итмәде. Кыз дәрескә йөрде, әмма спорт секциясенә шул көннән аягын да басмады, һәм әле кайчан гына аның артыннан мышкылдап чапкан ахирие чаңгы ярышларында уза ук башлады. Мондый көннәрдә Җәмил Зәйнетдинович кош тоткан кебек була һәм:

— Беренчелек очтымы? — дип хихылдап, күңелен күтәрә иде.

Ел узды. Бөтен техникум баласын тау астындагы уйсулыкка хәрби-спорт ярышларына җыйдылар. Равия командир булган «Г»лылар, курсташларыннан күп төрләр буенча алда барып, призерлыкка ныклы гына үтеп килә иде.

Инде палатка кору, сүтүне дә башкарсалар, өлкәннәрне дә тәмам артта калдырасыларына өметләнеп, зур тырышлык белән эшкә керешкәндә, әлеге дә баягы физкультура укытучысының мәкерле елмаюлы йөзе кешеләр арасыннан чагылып узгандай булды.

Тора-бара аңлашылды: Равияләр палаткасының казык-таяклары җитешми ләбаса! Ары сугылдылар, бире — ярыш узды, чара табылмады. Кызлар картайган карчык кебек янтайган палатка төбендә кул уып басып тордылар. Техникум буенча алгы урыннан да колак кактылар. Эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алган Равия түзмәде, спорт инвентарьлары җыеп йөргән мөгаллим янына килеп, эчтән ургылып чыккан чит бер тавыш белән:

— Сезнең кем икәнлегегезне белә идем бит югыйсә! — дип, укытучы эшләгән зыян хакында йөзенә бәреп әйтте.

Куллары йодрыкланган, тешләре кысылган бу кызга Җәмил Зәйнетдинович илтифат итмәгән бер кыяфәт белән генә:

— Әле белеп бетермәгәнсең икән, укып чыкканчы аңлатырга туры килер, — дип вәгъдә бирде дә үз юлы белән китте.

Көннәрнең каһәр сукканнары башланды, һәр бишле, журналга икеле кыяфәтендә кермәсә дә, калын нокта булып утырды. Шул ноктаroutines төзәтү өчен, ул укытучысы исеменнән район газетасына мәкаләләр язды, дәресенә күрсәтмә әсбаплар хәзерләде.

Шулай да иң авыры мәктәптә физкультура дәресе биргәндә булды. Секциягә бергәләп йөргән Сәкинә телгә кыюсызлыгы, колакка катыраклыгы аркасында ни аңлата, ни балаларны санлата алмады. Укытучы әйткәннәр белән килешмичә, менә диган дәрес биргән Равиягә дүртле төртеп, дустына бишле куйганда, Җәмил абыйсы, махсус рәвештә мишәрчәләп:

— Үцебец беләбец бец ницә цәпелдәтәсен, — дип, теш арасыннан гына кысып чыгарды.

Техникумда бер ул гына укытмый иде, әлбәттә. Аңа алмашка килгән һәр физкультурачы Равияне яратты, үрнәккә куйды, иң яхшы билгене дә кызганмады, әмма спорттан күңеле тәмам кайткан кызны ярышларга катнашырга мәҗбүр итсәләр дә, секциягә йөртә алмадылар. Алай гына да түгел, Җәмил Зәйнетдинович белән колхозга кыр эшләренә барасы елны ул:

— Тап бер юлын, җибәрмә мине шул мишәр белән! — дип, әтисе алдына кайтып егылды.

Җәен мотоциклда йөргәндә кулын имгәткән иде. Шуны сәбәп итеп, аны бәрәңге җыюдан калдырдылар. Ул көз буе дивар буяды, плакат ясады, алма киптерү эшләренә катнашты, һәр атлаганында әтисен рәхмәт хисе белән искә алды.

Менә Равиядән башка гына колхоз икмәген ашап тулыланган иптәшләре дә кайтып җитте. Кубага җибәрәбез дип, ап-ак капчыкларга бәрәңге җыйдыртты, үзебезнең районда сатып яткан, яз әле гәҗиткә, диделәр алар, бәрәңге хәлләрен сөйләгәндә.

— Юк! — дип кырт кисте Равия. — Бу эшегез белән бөтен техникумны аякка бастырасыз, йөзенә тап төшерәсез ич сез, ә мин нәкъ менә аның турында гына язачакмын! Һәм үземнең исемемнән генә!

Сыйныф гөрләште-гуләште дә язучы табылмагач тынды. Равия күңелендәге үпкәнең үзләренекеннән дә зурлыгын һичберсе төшенмәде. Ул, гомерендә бердәнбер яратмаган укытучысына үч итеп, язучы булам дип хыялланды, холкыннан детальләр җыйды, күзәтте, өйрәнде, зур әсәр өчен сюжетлар әзерләде, һәм чыгарылыш көнендә мөгаллименә елмайган килеш кенә, цәрелдәп:

— Бец әле Сезнең белән минем китапларда оцрашырбыз,— диде.

Казанда укыганда, аларның юллары еш кисешә, һәм электричкада калага баручы укытучысы, аны күрмәмешкә салышып, икенче вагонга узарга тырыша, ул утырганында тукталмый иде. Шулай да бервакыт ялгыш кына урыннары янәшә килгәч, Равия юл буе матур гына сөйләшеп барды да хушлашканда:

— Мин язучы булачакмын! — дип, аның күңеленә янә коткы салды.

Әллә әйткәннәре Ходайның «Амин» дигән сәгатенә туры килде, әллә шушы үч хисе үз эшен эшләде, ул танылды, язучы исемен алды. Әлеге тема гына, һаман да өскә калка алмыйча, сәгатен көтеп, күңел түрләрендә качып ятты.

Журналист булып эшли башлагач та, ул туган техникумына еш кайтты, тик хәзер үзе укытучысын танымаган шикелле узып китә торганга әйләнде.

Бу танымаулар чылбырын башлап мөгаллим өзде. Бәйрәмнәрнең берсендә килгән кунаклар арасында Равия дә бар иде.

— Аһ, мин Сезне укыттым, бик яраттым бугай бит, ялгышмасам, — диде ул, аны иттифакый туктатып.

Равия көлемсерәде, ризалашып баш селекте. Үч хисе кимүдән, укытучысы белән дуслашып китүдән курыккандай, сүзне дәвам итмәде.

— Юбилеема кил, мин сине көтәм! — дип өстәгән Җәмил абыйсына да, бәйрәмнең кайчанлыгын да сорап тормастан:

— Юк! — дип кырт кисте.

Инде күңелендәге сюжет тәмам өлгереп беткән көннәрнең берсендә авылыннан Казанга килешли район үзәгендә тукталган иде. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, музыкадан укыткан Фидарис абыйсы өйдә булып чыкмады. Күршеләрендә ниндидер бәйрәм, имеш, шуларга кереп киткән. Тышта матур, һава саф, күктә йолдыз мыжгыганга, бераз кичке гүзәллеккә хозурланып, урамда гына көтәргә булды, әмма озак хушланырга туры килмәде, койма аркылы гына яшәгән күршеләре капкасыннан кемнәрдер этләренең ярсый-ярсый өргәненә капкаларыннан килеп чыктылар да Равияне, танып алыпмы, мәҗлескә кодалый башладылар. Бераздан Фидарис абыйсы да күренде. Аның:

— Кер инде, ялындырма, Җәмил абыеңа — алтмыш бит, — диюенә кызның көтмәгәндә күз аллары караңгыланып китте. Укытучысының яраткан кәлҗемә-мәлҗемәләре, боламыклары, пешмәгән шалканнары, пешкән шалканнары — барысы бергә колагына тыгылгандай булды.

— Аның бәйрәменә кермим! — дип көч-хәл белән генә әйтә алды.

Инде тынычландык, кермәсәк кермибез дигәндәй, Равияне җитәкләп, Фидарис абыйсы кызу-кызу үз ишегалларына, аннан йортларына узды. Өйдәгеләр белән бергәләп өстәл тирәсендә кайнаша башлаганда, кызып, күңелләләнеп алган Җәмил Зәйнетдинович килеп керде һәм, мәҗбүриләп диярлек, Равияне үзләренә алып китте.

...Мәҗлес тынган. Зур кунакны каршылап һәм аннан зур сүзләр көтеп тынган иде. Бәллүр фужерларга болгар шәраблары, маҗар шампаннары коелды. Күңелдә шул шәрабларны эчертерлек сүз генә юк. Үпкә, рәнҗеш аша бер ноктага карап, Равия узган гомерен күз алдыннан кичерде һәм, үзе дә сизмәстән:

— Әле без сабый чакларда диярлек, техникум бусагасын атлап кергәч, мөгаллимем безне үз гомеребездә дә күрмәгән снарядлар белән таныштырды, — дип сөйләп китте.

Сүз әллә каян акты да акты. Күздәге рәнҗешне, үпкә яшьләрен юып алган чишмә суыдай, үзе дә көтмәгән, әйтермен дип уйламаган шифалы сүз иде бу.

— Шулай да мин Сезне нәрсә белән истә калдырдым соң?!

Равия беравыкка гына тукталгандай итте. Мөгаллимнең күзләрен шом баскан, ул нәрсәнедер куркып көтә булса кирәк.

— Хәтерлисез булыр, һәр дәресебез кечкенә генә тальяныгыз моңы белән башланып китә иде. Әле мин аннан соң да сез уйный торган бердәнбер көйне көннәр буена көйләп йөрим:

> Күпме күзләр күреп онытылган,
> Күпме йөзләр чыккан исемнән.

Күпме сүзләр киткән хәтеремнән! —
Ә син һаман, һаман исемдә!

Бу җыр әйтерсең бөтен бокаллардагы шәрабларны үз көенә уйнаклатты, тамырдагы каннарны икенче бер агыш белән тәннәр буенча йөгертте. Аңа бик таныш, бик якын, үзәкләрне өзгеч баян тавышы килеп кушылды.

Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
Мин минутлык хискә исердем.
Айныдым да, сөенеп туя алмыйча,
Тагын сине искә төшердем.

Мөгаллим баянын тезләренә куйган да онытылып җырлый иде.

Юк, болай яхшы уйнаган, моңлы җырлаган җан иясе начар буламыни, дип уйлады Равия. Минутлык хисләр аны сукмактан алып чыккандыр. Җырны да ничек аңлыйсың бит әле...

Кунакларның барысы да җырчылар иде, ахрысы — бераздан көйне дәррәү күтәреп алдылар. Кулына шампанлы фужер тоткан Равия генә башка һични сөйли алмаслык хәлгә килгән иде.

Үч онытылган. Ул әйтерсең булмаган да! Инде шушы картаеп беткән укытучы да, җыры кебек, бик тә, бик тә якын тоелды аңа. Рәхмәт хисләре әйтәсе, борчыганнары булса, гафу үтенәсе килде. Юк, кирәкмәгәндер дә.

Һәркем өчен әлеге җыр үзенчә сөйли иде.

*1998*

## Нигә елады?

Төнге икеләрдә ишекне шакыдылар. Ачык калдырып яткан булса да, Гәүһәрия, иренең ул килмичә кермәсен белгәнгә, ашык-пошык кына өстенә озын халатын киеп, чишенү бүлмәсенә чыкты. Гадәтенчә, шик калдырмас өчен генә:

— Кем ул? — дип сораган булды.

Ишек катыннан Хатипның боек кына тавышы ишетелде:

— Мин бу, җаным, ач әле, сөйләшәсе бар...

Ул башы белән ишеккә терәлде булса кирәк. Гәүһәриянең куллары тигәнче үк, ишек үзеннән-үзе ачылып та китте.

Икенче сорау да икесенә дә бик таныш иде.

— Нигә кайттың? — диде хатын.

— Сине сагынганга...

Мин сине сагынмадым, диясе килсә дә, Гәүһәрия эндәшмәде. Берара бер-берсе белән бик озак күрешмәгән кешеләр кебек карашып торгандай итенделәр. Ишекнең киңрәк ачылганын күргән Хатип ялт кына сузылды да иреннәре белән Гәүһәриянең иреннәреннән эләктереп алды. Ул ныграк суырган саен, хатын күңелендә ачу-үпкә арта гына барды. Юкса... Көч-хәл белән ычкынган хатын, соңгы тынын җыеп:

— Унбиш көннән соңмы? — дип сорады.

— Гафу ит, исерек баштан авылга илтеп ташлаганнар... Әйдә, кереп сөйләшик әле.

Үзе, кер соң, дигәнне дә көтмәстән, ишекнең эчкәрге ягына узды.

— Ә менә мине беркем дә беркая илтеп ташламый, — диде Гәүһәрия, ниндидер бер моңсулык белән.

— Син бәхетле шул. Мин генә — нишлисең, алкоголик. Туктарга кирәк, карчык, туктарга. Әле үзем дә юл буе шул турыда уйлап кайттым.

— Тукран тәүбәсе булыр ул дип тә уйламадыңмы? — Бу сүзләрдән бернәрсәнең үзгәрмәсен белсә дә, Гәүһәрия шулай диде. Әйтте дә стенага барып сөялде.

Өзелгән сүз кабат ялганмады.

Бераздан Гәүһәриянең күзе Хатипның керләнеп каткан, канга буялган күлмәкләренә төште. Эченнән: «И Ходаем, исән-сау», — дип сөенсә дә:

— Күлмәк алмаштырырга кайткансыңдыр инде, име? — дип куйды.

— Иртәгә үзем үк юып әләм мин аны, карчык! Син ял итәрсең. Башка керләрне дә җыеп куй. Мин аны-ы-ы!

— Иртәгә үк тагын шулай кайтам, диген, — дип дәвам итте Гәүһәрия.

— Йә инде, мин аны сагынып кайттым... Ул нәрсә сөйләгән була...

Хатипның арганлыгы күренеп тора иде. Кочакларга сузыла башлаган куллары хәлсезләнеп кире төште. Ул әчкелтем-төчкелтем исләр чыгарып уфылдады да, авыраеп, идәнгә чүмәште.

Хет кыйна, хет сүк, бер үзгәреш тә юк бит, әллә кереп ятыйм гынамы, дип, Гәүһәрия зал ишегенә юнәлде. Хатип, аның уйларын аңлаган кебек, утырган җиреннән аның аякларыннан эләктереп алды:

— Орыш инде, һич югы, орыш инде, карчык...

— Орышасым да килми шул.

— Миңа, син орышкач, җиңелрәк була. Гаебем юыла шикелле. Орыш инде.

Хатип, тыңларга хәзерләнгән кеше сыман күзләрен зуррак ачып, Гәүһәриягә текәлде. Кинәт кенә икесе дә кычкырып көлеп җибәрделәр. Бик якын, иң якын кешесе иде ул Гәүһәриянең. Орышса да, үзенә җан газабы гына ала ич. Әллә орышыргамы? Орышырга дип кыймылдаган иреннәре тагын шул ук сорауны бирделәр:

— Син нигә кайттың?

— Әйттем ич инде, карчык...

— Алайса, кем янына, дип үзгәртәм.

— Синең янга инде, синең янга.

— Мин бит, минем янга кайтсаң, аек кайт, дидем, Ха-ти-и-и-п!

— Ә мин бүген тамчы да эчмәгән, — диде Хатип, күзләрен дә йоммыйча, авыз эчендәге исләрнең хушрагын сайлагандай. Иреннәрен әле теге, әле бу якка кыйшайткалап, сулыш өрмәкчегә салынып торса да, аларның Гәүһәриядән ераклыгын аңлапмы, хатынны аякларыннан үбеп алырга булды.

— Яратам бит мин сине, яратам!

— Яратсаң, эчмәс идең.

— А-а-а! Анысы, матурым, башка мәсьәлә.

— Син бит, өйләнгәндә, бер дә рәнҗетмәм, бер авыр сүз дә әйтмәм, тартмам, тамчы да эчмәм, дигән идең...

— Анысы, матурым, инде икенче мәсьәлә.

— Синдә мәсьәләләр бик күп шул, Хатип, ә мин бәхет дигәнен генә беләм, менә шуны үзем генә чишә алмыйм.

— Кил әле монда, алай булгач, карчык, кил әле, кочаклап утыр әле.

Бик киләсе иде дә... Гәүһәрия тагын да читкәрәк киткәндәй итте.

— Унбиш көн бит, — диде ул, кабат Хатип булмаган көннәрне санап. Таш стенага терәлеп, почмакта утырган иренә карап куйды.

Хатип, аптыраган кеше төсле, учына тамган беренче яшен җентекләп-җентекләп күзәтә иде. Икенчесе үк тамгач, Гәүһәриягә кыен булып китте, аның янына килеп тезләнде дә Хатипның башын куллары белән кочты.

— Елама, Хатип, елама, миңа болай да бик авыр... — диде ул. Исерекләрнең тиккә дә еларга яратканын белсә дә, нигә елый, дип аптырады.

Инде Хатип чын-чынлап туарылган, әче яшьләре өзлексез Гәүһәриянең күкрәгенә тама иде.

— Елама, Хатип, елама, миңа болай да бик авыр.

Менә Хатип туктады. Җиңе белән яшьле күзләрен сөртте.

— Эх, син, нәрсә беләсең соң?.. — дип, инде яшьсез генә сулкылдарга кереште. — Яратам бит мин сине, карчык, яратам! — дип каты итеп кычкырды да йөзтүбән идәнгә капланды. Берничә минуттан аның авыр сулап йоклаганы ишетелә иде.

Гәүһәрия, иренең иркәләгәнне дә сизмәс хәлгә килгәнлеген аңлагач, әкрен генә керфекләреннән үпте. Дога укып, аркаларыннан сыйпады.

— Нигә еладың син?

Аңларга тырышып кына соравыннан күңеле тагын да йомшап китеп, үзе дә, тамак төбенә меңләгән мәсьәләләр килеп бөялгәнлектәнме, чарасызлыктанмы, әллә артык яратканлыктанмы, туктаусыз сулкылдап еларга тотынды.

*1989*

## Үзеңнеке — үзеңә

Көлешә-көлешә кунактан кайтып барыш иде. Сүзебезнең иң кызган чагында гына иптәш кызым Раилә нидер исенә төшергәндәй туктап калды да, суыктан кызарышкан бармакларына күрсәтеп:

— Гөлүсә, минем алтын балдагым кайда икән? — диде.

Аптырап киттем. Күңелле генә тәмамланган мәҗлес төсен югалтты. Күпме генә тырышсак та, алтын балдакның кичәгә барганда булганмы-юкмы икәнлеген исебезгә төшерә алмадык. Кире борылырга соң иде инде. Якын тирәдә генә төзек телефон да табылмады. Шулай аптырашып торганда:

— Әйдә, болай итәбез, — диде Раилә. — Минем менә бу йортта гына күрәзәче дустым яши. Кереп чыгыйк булмаса. Әйталмаса, шалтыратып сорашырбыз. Телефоны да бар.

Минем өчен күрәзәче ни дә, сихерче ни... Икесе — бер кием чабата. Чабата җылыта торгандыр, ә менә бу сүзләрдән тәнгә салкын йөгерде. Рус телендә сихерчеләр хакында бер китап укыганнан соң, өч тәүлек йокларга ятарга куркып йөргәнем исемә төште. Күз алдыма аклы-күкле чәчләре пыркыган бер кортка килеп басты. Юк ла... дидем мин үземне тынычландырып, күрәзәче генә ди ич ул. Җитмәсә, дусты, классташы да.

Тынчу лифт, без һавасына күнегеп өлгергәнче үк, дүртенче катка менгезеп тә куйды. Хәле киткән аякларым ахирием артына постылар. Гел көлеп, гел сөйләп торган иреннәрем тавыш-тынсыз гына кысылдылар.

Шалтыраган кыңгырау тавышына ишеккә кемнеңдер килгәне ишетелде. Йөрәк дөп-дөп тибә. Күз алдым караңгы. Менә сәер бүлмә яктысы сирпеп, ишек ачылып китте. Аннан гап-гади бер ханым килеп чыкты. Көчәнеп елмаюымны да күрмәмешкә салынып, ул куллары белән нидер эзләвен дәвам итте. Менә аның озын матур бармаклары, бөтерелә торгач, ахириемнең кулларыннан кысып тоттылар да бертуктаусыз йөренүдән туктап калдылар.

Үзе исә, аптыраган тавыш белән:

— Абау, Раилә, синме бу? — дип сорады. — Түземегез булса, көтегез. Бүген кешем бик күп шул. Алар китми торып, бүлмәмә дә чакыра алмыйм. Әнә кухняда бер-бер утыргыч калган булса, шул тирәгә чүмәшегез.

Ханым, кармалана-кармалана, түрдәге ишекләрнең берсенә юнәлде. Җанымнан куркыныч көтү тойгысы юкка чыкты. Инде бик бирелеп безнең шикелле өметсез җаннарны күзәтә идем.

Җиһазсыз, шыксыз бу аш бүлмәсеннән берәүләр чыга, икенчеләре исә алар урынына керә тордылар. Эчтә аларны ни каршылый, ни озата — берсе дә сөйләмәде, барысы үз язмышы белән мәшгуль, үз кайгысын кайда ташлап калдырырга белми иде.

Дөньяда күрәзәчегә кешене төрле хәсрәт йөртә икән. Әнә көлә-көлә чыккан яшь кызга күрәзәче тиң яр вәгъдә иткәнгә охшый. Янымда чират көтеп утырган апаның аяклары сызлый булса кирәк. Бармаган врачым, им-томчым калмады, ди. Яшь кенә бер егетнең бер машина товары юкка чыккан.

Күрәзәче, ниһаять, безне чакырды.

— Әллә, Раилә, син дә минем ялганга ышана башладыңмы?

Көлемсерәп әйтелгән бу сүзләргә мин аптырап калдым. Күрәзәче дигәнең үзе дә үз әйткәненә ышанмый икән ләбаса!

— Абау, бармагыңдагы гомер салмаган балдагың юк икән ич, сизми дә торам тагын, — дип тә өстәгәч, ни уйларга да белми аптырашта калдым.

— Менә шуның кайдалыгын белешеп кердек тә инде юл уңаеннан гына.

— Юкка шикләнәсең, Раилә, балдагың утырган җирегездә калмаган. Өй җыештырганда, бармагыңнан төшеп, кием-салым арасына кереп киткән. Эзләсәң, табарсың.

Раилә, уйлары укылганнан оялган кеше шикелле, миннән карашын яшереп, тәрәзәгә текәлде.

— Инде син кулыңны бир.

Куркудан тагын да кечерәеп калган кулларымны, үзем дә сизмәстән, күрәзәчегә суздым.

— Бир, бир. Елмаеп утырсаң да, синнән дә тынычсыз яшәгән җан юк. Иртәгә аерылышасыз ич. Ирсез дә, хәләл көчең кергән әйберләрсез дә калам инде, дип куркасың. Курыкма: үзеңнеке — үзеңә. Ай-яй яман хатынга эләккән мескенем. Аның белән дә торуы тору булмас. Анда барырга ярамас, болай эшләргә ярамас. Туганнарын, дусларын югалтыр, бер кешесез калып, гел сине уйлар. Кем белән булса да, гел сине яратыр. Аның да үзенеке генә — үзенә...

Шик-шөбһәләр белән аның күзләренә күтәрелеп карыйм. Чиста күк йөзе кебек күзләр көлемсериләр генә.

— Карама, барыбер күрмим ич мин. Кулыңны гына бир. Кулыңны гына.

Бирәм. Барыбер күзне аныкылардан ала алмыйм. Күрми торган күзләр дә матур була ала икән, дим эчемнән.

— Әтиеңә охшагансың. Уңган да кеше булган икән. Үлдемени инде? Үз үлеме белән түгелдер...

Бер белмәгән ханымның бармаклары кан тамырлары буйлап минем җанымны сытә.

— Бәхет тигезлектә генә дип ялгышасың. Әллә үзеңне бәхетсез димәкчеме? Шундый матур кызың, әтиең урынына калган абыең була торып. Бертуган кебек апаң ничек ярдәм итәргә дип кенә тора.

Шыттыра башлады, дим эчемнән генә. Кемнең абыйсы булмас та, кемнең туган апасы булмас.

— Сикерә дә соң йөрәгең. Машина моторы да болай эшләмәс. Куй бу уйларыңны. Куй кеше өчен януларыңны.

Ул бераз уйлангандай итә. Туктап калгач, туган тынлыктан авырсынып, мин инде кулларымны үзем аңа сузам.

— И-и-и... юләр, утызга кадәр укыган башың белән миңа килдеңме? Җитмәсә, ялганлый дип шикләнәсең. Аптырыйм мин синдәйләргә. Үзе ышанмаска өйрәтә, үзе күрәзәчегә йөри. Курыкма инде, йә. Болай гына әйтәм ич мин. Кан басымнарыңа кадәр төште. Миндә Татарстанның ярты галиме, ярты шагыйре лекция тыңлап китте. Шулай. Белем күтәрергә йөриләр. Болгаткан тормышларын җиз иләктән иләтмәкчеләр.

Менә әйтә, менә әйтә, дип, тагын ап-ак күзләренә карыйм.

— Синең дә ирең артист халкыннан ич, — ди ул миңа.

Бүлмәне каһкаһәләп көлү тавышы яра. Ул минем өчен кайчандыр иң якын булган кешенең исемен атый. Кем әйткән аңа? Каян белә ул?

Кулларымны тартып алам да, ауган урындыкны да күтәрмичә, ишеккә атылам. Коридорның салкын һавасында иреккә чыккан җаным тынычланып кала. Аякларым мине кире бүлмәгә алып керә.

Күрәзәче берни булмагандай сүзен дәвам итә:

— Тынычлан. Беркем дә, берни дә сөйләмәде. Моннан дүрт ел элек нәкъ син утырган урындыкка утыртып, мин аңа синең хакта үзем сөйләгән идем.

Моннан дүрт ел элек! Балам булыр чакта! Кем туса да, күтәреп кенә йөртермен, тамчы да эчмәм, сине бик бәхетле итәрмен, дип антлар иткәндә. Ул! Ул! Күрәзәчегә барган. Ни дип? Нинди кайгы белән?

Күрәзәче сөйли дә сөйли. Бер тыңлыйм. Бер онытылам.

— Нигә борчыласың? Үзен бозган кара хатынны да ташлаган ич. Башкаларын да. Монысы үзе өстеннән йөриячәк. Менә күрерсең! Эшендәге хуҗасы белән! Шул чагында, теләсәң, әйләнеп кайтыр ул. Итәге бик нык бозга ката икән... Юк, юк, тели күрмә: сиңа хуҗабикә булып калган ир кирәкме?

Яратсаң да, горур бул. Аның бозык хатыннарына охшаудан саклан. Алар беренче чирканчыкны күптән алганнар инде, шуңа күрә дә бер бәхет тә кулларында тормый. Сезне сагынып тилмерсен, әйттем ич: һәркемнең үзенеке генә — үзенә.

Күзләремә яшь тыгыла. Ничек инде? Аны... Аны тилмертергә?

— Ела әйдә, ела, шушы елавың соңгысы булыр. Ул сине җиңеләйтер. Судта еласаң, үзеңә дә чит кеше тавышы булып тоелыр. Кертәсеңә ышанса, кире дә кайтыр иде, дим ич... Кайтса, малай табарсың әле. Кайтару кирәк микән? Язганга каршы барып... Җаныңа тиң мәхәббәткә бу дөньяда барыбер урын юк. Эшеңдә дә, юлыңда да тиз гашыйк булырлар. Байлык та вәгъдә итәрләр. Кияүгә чыгарга ашыкма. Ireңне сагынып сөйләп, җаннарын биздерерсең. Юк ireңнән көнләшеп саргаерлар да, саргайтырлар да.

Ни сөйли ул? Кем кияүгә чыгарга җыена?

— Син киләсең әле тагын миңа. Аптыраган көннәреңнең берсендә машинага утырып киләсең. Ул көнгә дә озак түгел инде, әмма ашыкма.

— Ә ирем? Ул бәхетлеме?

Аннан артыгын сорарга хәл бетә.

— Минем караватыма капланып, башына чыдый алмый ятты ул. Бозыгын чыгарырга — мин бит сихерче түгел, күрәзәче генә. Ни буласын гына әйттем. Аңа гашыйк һәр кыздан саклау минем көчемнән килми. Ул алардан үзе дә арына бара бит. Арына бара — бозыла бара.

Бозыла, ди. Бозыла, ди. Мин аны ничек... яратырмын?!

— Кызын бик сагыначак, тик теленә дә алырга куркачак. Ә син онытты дип үпкәләп яшәрсең...

Онытты дип... Аны онытырга буламыни? Үзеңне онытырга буламыни?..

Ул соң мине, менә мине оныта алыр микәнни?! Онытса ни дә... Оныткан өчен үпкәләргә ярыймыни? Кешене акылы зәгыйфьлек өчен кызганырга гына була... Хәсрәтен оныткан сау кеше бар микәнни соң?

Әгәр, чыннан да, онытса... Бу ак күзләр, онытты, дип тәкрарласа да, ышанмаячакмын! Ышанмаячакмын!!!

— Онытуын онытмас... Оныттырырлар...

Ханымның нәфис озын бармаклары йодрык булып йомылалар.

— Менә бу йодрыкны күрәсеңме? Бик борчылганда, авыр уйларга батканда, тагын да ныклабрак кысам мин аларны. Минем уем бармак араларыннан чыгамы, юкмы? Юк шул. Ireң дә менә шундый бер йодрык эчендә яши. Учын ачса, чыгар. Кайсы хатын-кыз таш тәтәйне учыннан чыгарыр икән? Беркатлы да үзең. Бәхетле булса, миңа киләмени ирләр? Ач кеше шикелле, минем чикмәнле бәрәңгеләремә күзен текәп утырамыни? Бер белмәгән кешесенә, барысыннан да артык юкса үз хатыным, диямени?

Бәхетле булса, бәхетле булса... Мин аны кайчан да булса бәхетле иттем микән? Ул һаман да бәхетле түгел микәнни? Мин яраткан кеше дә бәхетле булмаса! Мине яраткан кеше бәхетле булмаса...

— Бәхетле ит, бәхетле ит аны, — дип, аның бәхетсезлеген үземдә тойгандай, яшьләремә буылам.

— Ела, ела... Соңгы яшьләрең булсын. Беренче судтан соң бергәләп миңа килсәгез, бәхетле булырсыз, бергә калырсыз. Икенче суд...

— Килербезме соң? — дип, сүз бүләм.

— Үзең генә барсаң, килерсез. Ә нәрсәгә? Ялгыз бәхет тә бәхет ич инде ул. Син бит башка дөнья кешесе. Үзең тудырган матур хыял эчендә калырга телисең. Ул хыялны яшәтү бөтен кешенең көченнән дә килми. Җир бар, күк бар. Син бәхетнең күктәгесен сайлагансың да җирдә үскән камышка үреләсең. Нечкә күңелеңне тормыш сазлыгына ташлама. Хыял эчендә ялгызың да бәхетле калып була. Хыялда ялгызлыгыңны тоймаска була.

Мин соң... мин соң шундый да хыялый микәнни? Ярату — хыял гына микәнни ул? Мин хыялларымнан да баш тартырга риза! Аның хакына күкләрдән төшәргә риза!

— Юрама миңа ялгыз бәхетне, юрама! Парлы булсын, диген!

— Мин бит яныңда парың булмас, димәдем...

Яндагы пар... Хыялдагы пар... Кирәкми миңа ике пар. Кирәкми! Миңа яратып яшәгәне дә бик җиткән! Күңелем төшеп, ишеккә таба атлыйм.

Әнә аның ак төстәге күзләре. Ул аклык артларында нинди хыяллар? Аның янында нинди ярлар? Бәхетлеме ул? Хыял белән бәхет янәшә йөриме? Бәхетле кешегә хыял кирәк микәнни соң?! Бәхетле кешегә җирдә дә күктәге кебек түгел микәнни?

— Килеп йөр миңа, — ди ак күзле ханым, ишектән чыгып барганда. — Син мин үз гомеремдә күргән бер генә кешегә дә охшамаган. Синең киләчәгең дә бер генә кешенекенә дә охшамаган! Синең бәхетең шулкадәр үзеңчә!

Минем бәхетем, аның бәхете... Бәхетебез икегә аерылды ук микәнни? Бар микән ул бәхет? Булса, ул кайда, дип, күкләрне ярып кычкырасым килә. Миңа бәхет вәгъдә иткән ханымның күзләрен каплаган ак пәрдәләрне ярырлык итеп кычкырасым. Ул бәхетне мин моңарчы күрмәгән кара алмаларыннан сорап, юратып аласым килә. Ишетәме ул минем җан авазын, юкмы? Шуны белергә теләгәндәй, тукталып, ябылып бетмәгән ишек ярыгыннан соңгы тапкыр берни аңлатмаган күзләргә текәләм.

...Минем бәхет. Аның бәхете. Аерым-аерым туган кешеләрдә бәхет тә аерым буладыр шул... Аяк астында чупырдаган көзге сулар, пыш-пыш килеп:

— Бәхетлеме ул, бәхетлеме ул? — дип йөдәтәләр.

Миңа кайчандыр бәхет вәгъдә иткән, инде миннән торган саен ерагая барган, әле һаман да сөйгән ярымның, әгәр булса, йөрәген ярырлык итеп кычкырам:

— Бәхетлеме син? Бәхетлеме?!

*1994*

## Репетиция

Таһир белән Сәвия шәһәр читендәге сазлыклар уртасында утырган яңа фатирларына узган ел гына күченделәр. Күченделәр дә бөтен кеше белән дуслашып та өлгерделәр. Биек таш биналар салынасы урында әле яңарак кына бер авыл кешеләре булып яшәгәнгә, күршеләр арасында һич сер тормый, ашаганнарыэчкәннәре уртак икән.

Кайсы ир кайсы ялгыз хатыннан иртәнчәк кайсы вакытта чыгып килгән, кемнең эштән соңарып кайтканда башын ярганнар, кемнең туганы танылган композитор да, кем баласы чит илдә акча эшләп ятучы рәссам — монда боларның барысын да беләләр, шулай да «сөяркә», «алимент» кебек сүзләр кергән темалар, ирләрнең китүе-кайтуы мәсьәләләре подъезд төбендә утыручы карчыклар, хуҗабикәләр телендә ешрак кабатлана иде.

Күрше-күлән сөйләшә, кеше язмышларын үзләренчә хәл итә, фаразлый, ә ирләр, гадәттәгечә, китәкайта торды. Әллә шулай тиеш дип санадылар, әллә чынлыкта да шулай тиеш иде — бу хакта беркем дә баш ватмады, әмма ләкин гайбәт өчен татлы саналган ризыктан да баш тартмады.

Карчык-корчык әле генә исен чыгарганчы селкесә дә, гаепле кеше ишек төбеннән узганда, андыйлар белән яшәүләренә, гәп сатарга тема барлыгына эчке бер сөенү белән, чын күңелдән сәламнәрен кабул итеп, аңа хәер-дога теләп калды.

Җае туры килеп, андый имеш-мимешләр колагына кергәндә, Таһирның хатыны Сәвия, фәлән-фәлән кеше китү уңаеннан, «ашаган җиренә сыер да кайта» дип кенә җибәрә иде. Әйе, «сыерлар» китә торды, кайта торды. Алар исемлегенә кермичә, башка хайваннар рәтендә йөргән Таһирның бу йортта дәрәҗәсе торган саен күтәрелде. Дәрәҗәдән алда корсак та калыная барып, тавышында вәкарьлек, йөрешендә сал-

маклык артты. Хәзер хатын белән кочаклашып чыгып китүләр, кочаклашып кайтулар шул сәбәпле шактый кыенлашты. Кешеләрне көнләштерү өчен, алар, яшьләр кебек, җитәкләшеп йөрергә гадәтләнделәр. Ишектән узганда, ниһаять, Таһир да, янәшә сыймаганлыктан, хатынын алдан уздырырга күнекте, ирлек горурлыгына тисә тиде, иллә мәгәр, тәртипне бозып, кеше теләнә керүдән уттан курыккандай курка иде.

Ирләрнең азгынлыгыннан диикме, сыерлыгыннанмы (хәер, аермасы юк) туйган кайберәүләр, аларга карап, эчтән генә тормышка ашмастай хыяллар белән яндылар.

Көннәр бер-бер артлы узды, кайдадыр сулар акты да акты. Бер китеп кире кайтканнар ни өчендер яңадан озакка китәргә ашыкмадылар, бөтенләйгә китүне башларына да китермәделәр. Күңеленә төн уртасында төрле вәсвәсәләр килгәнгә уянып киткән Таһир, боларны күреп торганга, шабыр тиргә бата да, имчәкне көчкә эзләп тапкан бала шикелле, ычкындырмаска теләгәндәй, хатынына чытырдап ябыша. Тегесе көтелмәгән хәлдән аклы-күкле булып уянып китә, көнаралаш кабатланганга, инде сүз әйтми, бер саташудыр дип, үз-үзен тынычландыра иде.

Сәвия кебек фикер йөртсәң, сыер көн дә китә, көн дә кайта да бит, дип уйлый иде борынына кызлар белән картлык исе буташып керә башлаган Таһир эченнән, әмма шунда ук, сыер иялəнгән шул, аның ияләнмәгәне тайга ияреп тә юк була, дип, фәлсәфәне икенче якка борып җибәрергә тырыша иде. Бу мәсьәләне уйланып-уйланып та үз файдасына чишә алмагач, кич урынга ятканда, ул, мыгыр-мыгыр гына килеп, бисмилла әйтәсе, хатынына тыныч йокы теләсе урынга:

— Сыер көн дә китә… Ияләнгән җиренә сыер да кайта… Мин сыермыни? Сыер гына китәмени... — кебегрәк сүзләр кабатларга гадәтләнде.

Эштән арып, шундук йокыга китүче Сәвия, әлеге сүзләрне аңларлык хәлдә булмыйча, Таһирның динлеләнә баруына юрап, иренә мәхәббәтен күңеленә тагын да ныграк беркетте. Бу хакта сүз арасында гына кыстырып җибәреп, күршеләре колагына да кертте. Инде юан корсаклы, чалара башлаган сакаллы Таһирны мулла-монтагай дәрәҗәсенә үк мендерделәр, затлы күршенең эчендә шайтаннар котырганы берсенең дә башына кереп чыкмады.

Таһир эшләгән кантурда очлы борыны белән гел иснәнеп кенә йөри торган бер сазаган кыз бар иде. Әллә шуның борынына кармак кидерергәме, дип уйлады ул көннәрнең берендә. Бу китү нәрсәдәндер, кемнәндер башланырга тиеш иде бит инде. Әллә соң, булгач-булгач, артистка-фотомодель кебекләрдән тотыныргамы? Әнә бөтен газеталар аларның кияү таба алмый тилмерүен яза. Әле берсе, безнең Сарманга килә-нитә калсаң, әниләргә кереп чык, чын ирнең ниндилеген күреп калсыннар, дип, куен кесәсенә уч төбе кадәр генә кәгазь дә тыккан, чигү чиккән кебек кенә, «Фәридә С.» дигән тамгаларын да калдырган. Кызганыч, Таһир ул якка ук барып җитә алмады, ишек катындагы элгечкә эленгән костюм кесәсеннән акчалары белән бергә әлеге адрес кисәге дә шул кичне үк каядыр юкка чыкты...

Массовка артисткасы гына мин, дип көлгән иде кызый, дөрес икән, гавам арасында югалды, аны башкала театрларының һичбереннән табарлык булмады. Күрә карау Таһир сәхнә артындарак торган массовка артистларын таный алырлык түгел иде.

Башланып та юк-бар сәбәп аркасында гына тәмамланмаган вакыйгаларны кырыйга куеп, Таһир репетицияне китүнең үзеннән башларга булды. Калганын соңыннан күз күрер, диде ул. Хушлашуның төрле вариантларын уйлаганнан соң, шомару өчен кулайрагына тукталды.

Башта ишекне зур ачып, хуҗаларча кайтып керә. Хатынының өйдә икенче ел инде бер үк халаттан гына йөрүенә бәйләнә. Аннан...

Бу китү нәкъ шулай башланды да. Ул хатыны Сәвиянең керләр үтүкләгән чагына туры килде.

— Тагын шул халатыңнан икәнсең, — дип ризасызлык белдерә генә башлаган иде, Сәвиясе:

— Алмаштырам, Таһир, алмаштырам. Сигезенчедә укыганда ук кигән киемнәремне синең күргәнең юк бит. Миңа әле алар һаман да таман гынадыр, тамчы да үзгәрмәдем ич! — дип сүзен түгәрәкләде. — Әле менә шуларны, сандыктан табып алып, рәткә китереп маташа идем.

План барып чыкмады. Инде нишләргә дип торганда, Таһирның күзе көзгедә эленеп торган кәгазь кисәгенә төште. «Килдем, өйдә булмадың. Рафил» диелгән иде анда.

Рафил, Рафил... Хәерсез, андый исем һичкемне хәтерләтмәде. Кара син аны, ул әле китәр өчен репетиция генә ясый, инде хатыны сөяркә үк әзерләп куйган!

Таһир авызын кыйшайтып кына:

— Кем язган моны? — дип сорады.

— Классташым ул минем. Рафилне белә идең ич. Безнең йортка слесарь булып урнашкан. Ишеккә икенче йозак куеп бирмәссеңме, бер белән генә ышанычсыз, дигән идем, өйдә туры китерә алмаган, — дип уфтангандай итте Сәвия.

Әле китеп тә бетмәгән, инде йозакны ук алмаштыра. Таһир шулчаклы ышанычсызмыни? Ике йозак кирәк дип ялганлап маташмаса! Андыйларны бездә, комган төбе куючылар, дип әйтерләр иде, гарьләнмичә, шуны чакыртмаса!

— Әһә, минем кирәгем калмаган икән сезгә! — Таһир китәргә хәзерләнгән сыман ишеккә борылды.

— Кирәк, бик кирәк, әнә ишеккә йозакларны куй! — диде берни сиземләмәгән Сәвия.

Таһирның күңеле-кулы эшкә бер дә ятмый иде шул. Ятса, кәгазь корты булып хатын-кыз арасында кантурда утырамы?! Аның яхшы ягы да бар барын... Анысы — соңыннан! Ул, ишетмәмешкә салышып, кухня якка борылды. Китәсең икән инде, хатының үзе гаепле калырга тиеш!

Өстәл өстендә кып-кызыл чәчәкләр утыра иде.

— Карчык, чык әле монда! Нинди чәчәкләр бу?! — Китәр өчен яңа сәбәп шундук табылды.

— Ник, бүген синең туган көнең ич! Кайтуга, сүзне әллә ничек кенә башладың да... Хәзер, хәзер, эшемне бетерәм дә, утырышабыз.

Ай, шайтан алгыры, ул репетицияне читтә төн куну белән тәмамлаячак, туган көн өлеше шуңа калдырылган иде бит әле...

— Алдама! Димәк, бу йортта мин кирәк түгел... — диде Таһир, сузып кына. — Тир агызып тапкан акчамны чәчәккә саласыз алайса?

Сәвиянең түземлеге төкәнде. Ул чәчәкләрнең студентлардан алган зачеттан ияреп кайтканлыгын аңлатып торырга кирәк санамады. Таһир, ник, сатып, акчасын гына алып кайтмадың, ипигә-сөткә ярар иде әле, дип бәйләнәчәк иде. Чыдамады:

— Барысын да үзебез эшләгәч, үзебез алгач, акча да тотарга ярамагач, кирәк тә булмассың инде, — дип еламсырарга тотынды. — Кешенең ирләре әнә...

Тагын кеше ире, тагын Рафилме?.. Таһир, ялыныр, тезләнер, дип көткән бер вакытта! Ул ишеккә әле, өметен җуймыйча, бик акрын гына атлады.

— Ярар, Сәвия, хуш... Чәчәкләрне сатма, яме. Матур булып утырсыннар...

— Китсәң, кире кайтма! — диде Сәвия, гомер булмаганча каты тавыш белән.

— Йозакны үзең генә куя алырсың микән соң?

— Рафил куяр әле!

Тагын шул Рафил ике арага килеп керде...

— Ярар, сәлам әйтерсең, яме, аерылышасын әле хәзердән үк сиздереп куйма. Командировкада, диген. Аныкын... белмәссең! Ни... Чәчәкләрне сатма, яме! Ипилек-чәйлек кенә акчаны үзем дә калдырам мин!

Таһир, кесәсеннән бөгәрләнеп беткән ун сумлыкны чыгарып, урындык өстенә генә куйды да түр якка юнәлде.

— Кызым белән генә хушлашам да...

— Син дә хуш, хуш-хуш, әтием!

Багалмасының битләреннән суырып үпкәч, тегесе:

— Фу, әллә кем исе килә, — дип, борынын җыерды.

Троллейбуста яшь кенә кызый, күңелен кытыклап, хушбуй исләре аңкытып, кочагында ук кайткан иде... Болай каршы аласыларын белсә, репетиция ясамыйча да, шуңа гына ияреп китәсе кана!

— Алайса, кызым, мин сиңа да кирәк түгел? — диде әти кеше.

— Кирәк түгел, кирәк түгел, синнән әллә кем исе килә!

— Ну алай да борының минеке синең, кызым, усал телең генә әнкәңнеке... Йә хуш, соңгы тапкыр күрешү! — диде ул, сәхнәдә нотык тоткан фыртагай кебек кыланып.

Кызы, идәнгә тезелгән тәтиләре белән мәш килгәнгә, борылып та карамады.

Елан кебек кенә түр бүлмәдән сузылып тышкысына узганда, Таһир, суелырга хөкем ителгәнен сизгәнгә, абзардан чыгарга теләмәгән яшь үгезнең яшелле-күкле тавышы белән үкереп җибәрде:

— Ху-у-у-ш!!!

Моның кадәр газапны тагын да озынайта алмый иде: кискен хәрәкәт белән ишеккә ташланды, озак кына ачкычын таба алмады, кабаланды, кармаланды, нәрсәләрнедер койды, нәрсәләрнедер җимерде... Артыннан килеп, китмә, дип туктатучы күренмәде.

Соңгы өмет өзелде, вакытны сузарлык сәбәп калмады дигәндә, түр бүлмәдән чыккан кызы фамилияле борыны белән чалбар чабуына төртелде:

— Китмә, әтием...

— Күрдегезме, маңкушлар?! Үзегез мине күралмыйсыз, миннән башка торалмыйсыз! Шулай ул! — диде Таһир, зур горурлык хисе белән, маңгай тирләрен сөртә-сөртә.

Репетиция көтелмәгәнчәрәк тәмамланды... Әле дә ярый Таһир файдасына бетте, үзе дә сыер хәленә калмады, дип уйлады ул соңыннан, атналар үткәч.

Алар бу төнне кабат электәге кебек гөрләшеп чыктылар. Сәвия, чүкеч-өтерге алып, йозак куеп маташты. Кызы әнисенең ташландык киемнәреннән курчакларына күлмәкләр текте, Таһир, ирләрнең авыр язмышыннан зарланып утыру белән генә канәгатьләнмичә, әле кызын, әле хатынын, син кемне яратасың, дип тинтерәтте. Ул бу сорауга җавапны, мең булмаса, йөз ишеткән, тик аның бүген колагын шул сүз белән аеруча иркәләндерәсе килә иде. Татарча аңлый торган янәшә күршеләр, таш плитәгә сыланып, «Мин сине яратам!» рәвешендәге — үзләре елга бер-ике генә, анда да бәйрәм көннәрендә генә ишетә торган җөмләләрдән ләззәтләнде.

Гел ишеткәннәренең ирләре китә торды, кайта торды...

*1992*

## Бер микъдар былбыл

Әле кайчан гына мәңге җитмәс кебек тоелган яз да җитте. Кырда эшләр башланды. Көн эссесенә, аның язгы матурлыгына чыдар хәл юк. Уку инде тәмам туйдырган. Без дәресләр беткәнне көтеп интегәбез, тизрәк өйгә кайтасы, кышлак читендәге үзәндә малайлар белән туп тибәсе, яшел борын төрткән үләннәргә ятып, дөнья хәлләрен сөйләшәсе килә.

Язда минем хәлләр бераз хөртиләште. Әни — хастаханәдә. Өйдә берсеннән-берсе кече дүрт бала бар, аларга күз-колак булу минем өскә төшә. Кызлар кебек, тизәк җыю да, мал-туар карау да — миңа калды. Атамның өйдә торганы юк дисәң дә була: туфрак тәмам кипкәнче, кыр эшләрен тәмамлыйсы бар.

Без күрше кызы Сөенеч белән кайвакыт тау битләренә кадәр барабыз. Аның җиңел чиләкләрендә пар былбыл рәсеме бар. Мин аны былбыл дип үртим. Ачуланмый. Күтәрелеп, кара күзләрен тутырып кына карый да яңадан җиргә иелә.

Сөенеч ханым* күзгә күренеп матурайды. Ул инде җиткән кызлар арасына кереп маташа. Кашларына сөрмә тарта, керфекләрен буйый, тырнакларына гелән кына йөгерткән булыр. Ә миңа болар һич кенә дә ошамый. Калын кашлы былбыл була димени?! Сөенеч усал күренә башлый, әнә шул бар усаллыгы маңгай уртасына җыелгандыр кебек тоела.

— Аҗаеп адамдар сиз, ханымнар, — дим мин аңа. — Гүзеллекне беллесе керек: кичани равшан итир йүзингне каронгуламак — увол-гунохтыр.**

— О хосуста тюшюнмәк үчүн махсус гыйлем йоктыр. Ман не дие билим?*** — Сөенеч, астыртынлык белән елмаеп, миңа карый.

Сүзне дәвам итәрлек осталык бирмәгән миңа Ходай. Хәер, үзбәкчәм дә шундый гына. Татар сүзләре белән буташкан. Бу якларга, әле мин туганчы ук, бик ерактан, салалары-калалары яшеллеккә төренеп утырган Кырымнан күчеп килгәнбез. Безнең белән берничә гаилә, бар булган байлыкларын калдырып, төенчек-фәлән генә кулларына алып, сабый балаларын күтәреп, ерак бер илгә чыгып киткән. Монда да алар бер тирәдәрәк төпләнгәннәр, авылга үз гадәтләрен алып килгәннәр, аларныкын да кабул иткәннәр. Атам ул заманнар турында искә алырга бик тырышмый. Ялгышып, уйлап бетермичә, арабыздан кем дә сүз башласа, ул аны икенчегә бора, күзләре яшьләнеп киткәндәй була яисә, бер-бер эше исенә төшкәндәй, эреэре атлап ишеккә таба юнәлә. Аның ата-баба туфрагын сагынганы, күңеле белән шунда яшәгәне күренеп тора.

Минем үземә Акболак кышлагы ошый. Аннан каядыр китәсем, мондагы дусларымны югалтасым килми. Акболак — туган җирем лә ул! Нигәдер ерактагы гүзәл илләр дә кызыктырмый, әмма шул ук вакытта кайдадыр икенче Ватанның барлыгын да, анда бөтенләй башка телдә сөйләшкәннәрен, башкачарак яшәгәннәрен дә тоям.

Үзбәкчә уку миңа шактый авырга килә. Гаиләдә дә, дуслар белән дә ниндидер уртак телдә сөйләшергә күнегелгән. Без яхшырак төшенсен өчен, остазлар да җөмләләренә татарга гына хас сүзләр кыстырырга, аларны үзгәртебрәк, аңлаешлырак әйтергә тырышалар. Ә менә үзбәк әдәбиятын яхшы гына аңлыйм. Күп укыйм, күңелгә ошаган шигырьләрне истә дә калдыргалыйм.

— Гулзори җамолини тилаб нола килурдим,
Чун булбули шуридә гулистона йулуктум…*

Сөенечкә Увайсиның бу шигыре бик ошый. Кычкырып көлә дә, кыр кәҗәсе кебек, су буендагы ташлардан ташларга сикереп, алгарак йөгереп китә. Аннан, мине чакырып, кул болгый.

— Чабук ол! — ди Сөенеч, татарчалап. — Яваш эркәк сеңерләнгән эшәккә бәнзуюр.**

Минме әкрен, минме ишәккә охшаган?

— Э, джынмы, шейтанмы сән шәхсән?.. Йок, татлы балмы сән? Ашыкма... Каптым йоттум олур!

Без бу көн Сөенеч белән тизәкне бик озак җыйганбыз, мин дусларым белән футбол уйнауны да, йортның башка эшләрен дә онытканмын.

* * *

Гайрәтнең үзе хакында сөйли башлаган хикәясе, дөресен әйтим, гел Казан татарчасына күчереп тыңлагач, мине туйдыра да башлаган һәм бик озакка сузылыр шикелле иде. Үзем белән су буена алып килгән җайлы ятагыма ипләбрәк яткач:

— Гайрәт, әдәбият дәресләрен читкә куеп тор әле, минем үзбәкчәм синекеннән дә чамалы. Кырымчагызны беләм дип тә мактанырлыгым юк. Ялкау колагыма аңлаешсыз шигырьләреңнең мине ярату хакында түгеллекне аңлар дәрәҗәдә генә. Бала чагың турында истәлекләргә бирелер өчен, көн дә бу тупыл янына киләсеңмени соң син? Әнә су коен, кызын...

Ирен — гөл, бәдән — гөл..., вөҗүдең гөлшанында бер микъдар гөл, дигәнме әле син яраткан үзбәк шагыйре? Син дә шуңа охшагансыңдыр. Сөенеч — былбыл, Нәсимә — былбыл, Зөббениса — былбылдыр... Бер микъдар былбыл арасында мин генә юктыр...

Сүзләрем Гайрәткә ошамады. Йөзеннән үпкә шәүләсе сызылып үтте, әмма ул бер башлаган сүзен өзәргә теләмәде. Аның эч бушатуга бик озак әзерләнгәне күренеп тора. Танышым кабат, инде миңа туры карамый гына, балачак истәлекләренә бирелде. Мин дә аның сөйләгәнен, авырлык белән булса да, үзебезчәгә күчереп аңларга күнектем.

* * *

Атамның да эштән кайтканлыгын абайлап, аяк очларымда гына үз бүлмәмә узармын дигән идем, язмаган икән. Ахшамда барыбыз да йимәк йияргә* җыела торган йортыбызда, табынлык янында, йомшак мендәрләргә таянып ул утыра. Аның авырдан алган тыны яманнан хәбәр кебек аңлашыла.

— Әниеңнең хәле авырайган, иртә таңнан алырга чыгып китәбез, әзер тор, — диде ул, кырыс кына.

Әнине алып кайттык. Ул, чыннан да, бик йончыган һәм инде беркайчан да аягына басмас кебек иде. Ни хикмәт, Алла рәхмәте беләнме, без, менә өзелә, менә өзелә, дип көткәндә, атна-ун көн узгач, караватн кырыена торып утырды һәм аш соратып алды. Шул көннән аның сулган йөзләренә төс керә, күңеле көрәя башлады. Моңаеп утырмасын дип, мин еш кына аның янына киләм, хәлләнә башлаган кулларыннан сыйпыйм. Аның күңелендә ниндидер сер бар шикелле, бигрәк тә шул серне белергә, аннан сөйләтергә телим. Әгәр соң, сөйләтмәгән булсам соң... Юк ла, ул инде минем тормышымда берни үзгәртмәс иде.

Әни терелде. Йорт эшләренә дә катнаша башлады. Шифаханәдә узган көннәре дә кат-кат сөйләнелде дисәм... дөрес булмаган икән. Бервакыт ул мине үз янына чакырып алды да аяктан егарлык хәбәр әйтте:

— Улым, авырып ятканда, ерак бер кардәшебезне очраттым. Аның Мәхәббәт атлы җиткән кызы бар. Шуның белән, исән-имин калсак, ирләребезнең дә ризалыгын алып, туганлашырбыз, дидек.

— Без соң болай да акраба** булгач... Килсеннәр, михмон*** булсыннар.

— Мәхәббәт — матур гына кыз, син аны яратырсың, — диде әнием, чәч бөдрәләремнән сыйпый-сыйпый. Сыйпау түгел, учмасы белән йолкып чыгарса да, мин риза! Шушы минутта мин аны сизмәячәкмен дә! Иң кадерле кешем җаныма иң олы ташны бәргән инде.

Атылып, сокак**** буйлап йөгердем. Ул мине без әле кичә генә Сөенеч белән җип-җиңел тизәкләр җыеп кайткан үзәнгә, су чәчрәтеп уйнаган арык буена алып чыкты.

— Сөенеч! — дип кычкырдым мин, күкләрне ярырга теләгәндәй. — Сөенеч!

Арык буендагы тупыл артына терәлеп, Мехмет картның хәл алган чагы икән.

— Ни дип шар ярасың, ахмак! — диде ул миңа, таягын селкеп. — Һәр сөенгән кырга, үзәнгә, урамга чыгып сөрән салса! Менә мин агач төбендә йоклап киткәнмен дә яраткан карчыгымны төшемдә күрдем. Шул сөенечне дә синең кебек болыт ярылырлык кычкырмыйм әле.

Сөенеч... Көенеч булганга, синең исемеңне кычкырам икән ләбаса. Мин инде иртәгә синең белән су буена да килмәм, ярәшелгән егет булып, ат җигеп, кыз катына барырмын.

Арыкның ташлар белән ныгытылган ярына килеп утырдым. Елау егет эшемени, дисәләр дә, буылыпбуылып еладым. Яныма килгән Мехмет карт сәерсенеп торды-торды да:

— Сөенечтән дә еласыннар әле... — дип, мыгыр-мыгыр килеп, кышлакка кайтып китте.

Аксакалга хөрмәтсезлек күрсәтеп, алай да ул инде тимәслек ерагайгач, су буеннан шомарган бер ташны алып, таякка таянып җилфердәгән шәүләсенә ыргыттым. Мине Сөенеч ханымсыз калдырган йолаларга, әнине алып китәргә килгән чиргә, аның шартлар куеп китүенә ыргытылган таш иде бу.

Нәзерен үтәтмичә, әнисез калудан курку, бер үк вакытта күрмәгән, ишетмәгән, белмәгән кызга ярәшелү минем үземне дә ярты хаста итте. Алай да әни, тынычландырып:

— И юләр, ошатмасаң, кем сине мәҗбүр итә, барып кунак булырбыз да кайтырбыз, — диде.

Мәхәббәт ханым ямьсез дә, ахмак та түгел иде, әмма күңелгә кереп оялаган Сөенеч, аның миңа ратып караган күзләре, усал шаяртулары тәмам үз булып беткәнгәме, мин кызга булачак кәләшем кебек карый алмадым. Хәл-әхвәл сорашып, ашап-эчеп алгач, аның карендәшләре белән урамга уйнарга чыгарга җыендым. Моны сизеп алган әни, ишеккә таба барган чагымда, башкаларга сиздермичә генә, күлмәк җиңемнән тартып туктатты да, башын икенче якка борып:

— Гөлҗамал, балалар кинога-фәлән барып кайтсыннар, без сөйләшеп утырырбыз, — диде. Аннан үтеп барышлый аның янында тукталган Мәхәббәтнең нәни кулларын минем кулларым белән тоташтырды. Сүзләр ризалашмый калырга мөмкин булмаслык итеп әйтелгән иде.

Клубка барганда да, кайтканда да Мәхәббәт тә, мин дә бер-беребезгә ник бер сүз әйтик тә, ник бер караш ташлыйк. Учымда тирләгән бармаклардан гына мин Мәхәббәтнең дә бик дулкынланганын, ундүрт яшьлек акылы белән дә безне хәзер ни көткәнлеген аңлап ук бетермәгәнен тойдым.

Акболакка кайтуыбызны каршылап капкадан чыккан әтигә:

— Минем сезнең Мәхәббәтегезгә мәңге өйләнәсем юк! Мин аны яратмыйм! — дип кычкырдым.

— Улым, ни сөйлисең, сабыр... — дип туктатты әни. — Син аның кулларыннан тоттың лабаса. Урам буйлап та шулай бардыгыз. Баш тартсаң, аның турында туган-тумачалары, танышлары ни уйларлар? Бу хәлләрдән соң кыз баланы кабат кем сорап килер? Гыйффәте югалыр лабаса!

Мин үлдем. Нинди гыйффәт? Нинди намуссызлык? Кулыннан да куркып кына, әни тоттырганга гына тоттым лабаса. Хәзер менә, яратмаган булсаң, җитәкләр идеңмени, ди. Мин үлдем. Бер гаепсездән явыз дәрәҗәсенә җиткерелдем. Әни хакына ундүрт яшемдә корбанга китерелгәнемне, алдагы гомеремнең сызып ташланганлыгын аңладым. Ул исә «Сөенеч... » дип сүз башлавымны эләктереп кенә алып китте:

— Әйе, сөенеч, ә син, яратмыйм, дип, керә-керешкә куркытып куйган буласың, имансыз малай.

Сүзне артык сузуның кирәксезлеген аңлап, тандыр* өстенә тезелгән савытларны ишелерлек итәргә тырышып:

— Куркытмыйм берегезне дә, сөенмим, Сөенеч ханымны сөям мин! — дип, турыдан ярдым да салдым.

Әни дә, әти дә тынсыз калдылар. Гомер буе аяк арасында шыңшып йөрергә күнеккән Акборын тиз генә оясына шылды. Әйттем дә, капканы шартлатып ябып, йорттан чыгып киттем. Исәп кайтмаска, барысыннан да ваз кичәргә иде. Әле көннәр җылы, базар сатучыларына булышып, акча юнәтергә кулай. Шул акчага чәйханә тирәсендә көн итәргә була. Чәйханәгә көнлекче булып керсәң дә ярый. Туп-туры шунда киттем. Кахромон ага, кочак җәеп каршыламаса да, гозеремне кире какмады, үз янына алды. Ул кышлактан бөтенләйгә чит якларга чыгып китүемнән куркып шулай эшләде булса кирәк. Бераздан аның, яшереп кенә, атама хәбәр салганын, ризалыгын алганын сиздем.

Көннәр аш бүлмәсендә пылау болгатып, көрпәчәдә** чәйләп утырган картларны сыйлап уза торды. Көз, аның белән бергә укулар якынлашты. Алга таба нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Ул да булмады, ачуын эченә йотыпмы, атам да килеп җитте. Йомшак сүз белән кире йортыбызга кайтарды.

Чәйханәдә торганда, Сөенечне күрүгә зар булдым. Мәктәп мине сөендерде, бу елда, һичбер өметләнмәгәндә, ярәшелгән егет икәнлегемне белсәләр дә, аның янәшәсенә утырттылар. Ул миңа туры карамый, артык сүз башламый, биргән сорауларымны җавапсыз да калдырмый иде.

Хәер, өйдә Мәхәббәт ханым турында телгә алган кеше дә юк. Һәркем үз эше, хуҗалык тормышы белән мәшгуль. Шулай итеп, бәлки, бу ярәшү онытылыр кебек тә иде.

Уйламаганда-нитмәгәндә, Мәхәббәт ханымны, барлык әйберләрен йөк машинасына төяп, йортыбызга китереп куйдылар. Әнисе вафат, атасы башка ханымга өйләнгән, кызның яше дә никах өчен җитәрлек булган, имеш.

Хоҗа булганлыгымны аңлаудан телсез калып, атама карап торам. Ул дәшми. Аның да аптырашталыгы, гаҗизләнгәне йөзенә чыккан. Әни килене тирәсендә бөтерелә, үзара эш, вазифа бүлешәләр, туй-никах турында сөйләшәләр. Ара-тирә миңа да күз ташлаштыралар.

Әти ым белән генә тышка чакырды.

Гомер булмаганны, кесәсеннән чыгарган каптан тәмәке алып, миңа да берне сузды һәм ут кабызып җибәрде. Бу инде ир, тиң гаилә башлыгы санау идеме, атамның уйсыз бер адымы булдымы — аңламадым. Икебез дә, көрпәчәгә менеп утырмыйча, җиргә генә чүмәштек.

— Углым, — диде ул, озын итеп суырган төтененнән буылгандай, авырлык белән. — Анаңның нинди хәлдәлеген күрәсең. Нәзерен таптатсаң, мин, картлык көнемдә ялгыз калсам, кем янына барырмын? Энесеңелләреңне кем карар? Мәхәббәтнең әнисе вафатын да кызының синнән баш тартуыннан күрәләр икән...

...Укуны ташладым. Мәхәббәт белән гаилә булып яшәп киттек. Начар хатын да түгел иде ул. Барысына өлгерергә тырыша. Мине дә бераз булса да ярата шикелле, тик менә күңелемне генә үзенә ала алмады.

Тордым, ашадым, йокладым, бурыч икәнлеген аңлап, аны да куеныма алгаладым... Көн арты көн үтте. Бер-берсенә охшаган бу көннәр дә йөрәктәге Сөенечне үзләре белән алып калмадылар. Торган саен аны ярату, аның белән яшәү хисе көчәя генә барды. Ул күрше кызы буй җитеп ир йортына киткәч тә узмады.

Әнинең вафаты тыныч кына барган көннәребезне үзгәртте дә куйды. Мине Мәхәббәт тирәсендә тотарлык берни калмаган иде. Инде, һичшиксез, әйтермен дип яткан бер төнемдә хатыным беренче тотуымдагы кебек тирләп чыккан кулларына минекеләрне алды да күкрәк турысыннан тәне буйлап аска таба шудырып төшерде һәм:

— Гайрәт, көмәнем бар, сизәсеңме? — дип сорады.

Ничә айлар кочагымда кунып та якыная алмаган Мәхәббәтне дә шундый чакта рәнҗетерлегем юк иде. Китмәдем. Калдым.

Кыз арты кыз алып кайтып, ул мине гаиләгә тагын да ныграк бәйләде. Инде малай да тапкач, минем моннан соң беркайчан да китү турында сүз башламаячагым үземә дә ап-ачык иде. Шуны сизгән Мәхәббәт тә үзгәрде, аның тавышы, йөрешләре ныгыды, үз сүзен катырак әйтә башлады, әмма тәмам җанны биздерерлек бер адым да ясамады. Минем дә, аның да бәхетсезлеге бары тик арада мәхәббәт булмауда иде.

Язмыш каһәрләве болар белән генә чикләнмәгән икән. Мәхәббәт уйсызлык белән кайнар су тулы казанны тандыр буена куйган да, чәй-шикәр алырга дип, кибеткә киткән. Китүен киткән... Хәсәннең әрнүле кычкыруын ишетеп, юлыннан да борылган, тик соң булган инде. Яшь ярымлык сабый казанга килеп төшкән дә кире чыга алмаган...

Бу вакыйга мине исәрләндерде. Болай да битарафлык кына хис иткән хатыныма инде нәфрәт күзе белән үк карый башладым. Һәр начар эшкә аны сәбәпче иттем. Үземнең бәхетсезлегемне дә аннан гына күрдем. Ачу белән кул күтәргән чаклар да булгалады. Хода үзе кичерсен инде. Нәсел атын дәвам итүчесез дә калгач, ата-баба нигезен ташлап, читкә китәргә җыенып йөргән көннәрдә Мәхәббәтләр авылыннан әманәтче татар кардәшләре килеп керде.

— Хәпсе адам, ай-вай, бир үләҗәк икән, ничюн дуньяга келе аҗаба?* — диде ул капыдан** керә-керешкә. — Ах, гарип башим, ич де акылым йитмәй, башим айлана, әннәгез бакыга кечте, шимди бабагыз хастадыр. Гайрәтнең бармасы керек. Сизни орада чоктан күрмәк истейләр.***

Йорттан чыгып китәргә җыенуым каенатамнан фатиха алуга бару булып калды. Чыннан да, хәле авырдан көннәренең санаулы икәнлеге күренә иде. Атам белән дә сөйләшерлеге калмаган. Бөтен теләге, мине күреп, соңгы сүзен әйтеп калу булган икән.

Карт, кансыз калып агарган кулларын әкрен генә селкетеп, түшәге янына чакыргандай итте. Килдем. Тыңларга хәзерләнеп, ятак кырыендагы урындыкка утырдым.

— Синнән вәгъдә алмый торып, бу дөнья белән арам өзелмәс шикелле, ничәнче төн, чакырып та, Әҗәлнең бусагабыздан атлаганы юк. Мин аның инде йорт артында йөргән адымнарын ишетәм, — дип башлады ул сүзен. — Гайрәт, син миңа үз балам кебек якынсың. Безнең сезнең белән ерак кардәшлегебез дә бар. Аллага шөкер, балаларыгыз акылына, сәламәтлегенә аның зыяны тимәде. Кызым Мәхәббәтнең бу дөньяда инде синнән гайре һичбер якын кешесе калмады. Аны яратмавыңны да беләм, әгәр булдыра алсаң, тыныч күңел белән саубуллашуымны теләсәң, аны ташламаска сүз бир.

Чит хатыннарга күз атма дип тә әйтмим, күңелеңне ничә еллардан бирле тыеп килгәнеңне сизәм, җиңел эш түгелдер... Анысын үзең беләсең. Башка бер үтенечем дә юк. Әгәр бергә тыныч-имин яшәсәгез, балаларыгызны ташламасагыз, миннән сезгә — хәер-фатиха.

Миңа торырга да китәргә иде кана. Ни уйлаганымны чамалаган атам, сак кына иңемнән басып, кузгала башлаган урыныма утыртты да, иелеп, колагыма:

— Вәгъдә бир, карт кешенең күңелен рәнҗетмә, дөньядан тынычлыкта кичсен, — диде.

Ярар, дип әйтергә телем әйләнмәде, нишләргә белмәгәнгә, картның арык гәүдәсен кочаклап алдым. Әллә ризалык билгесе дип аңлады, күзеннән йомылганда чыккан яше бергә кушылган йөзебез буйлап тәгәрәде. Шул кочакланган хәлендә аның соңгы сулышы да чыкты.

Әтисен югалткан көннәрдә Мәхәббәткә аерылышу турында сүз кату мөмкин дә түгел иде. Мин аның хәл алганын, картның җидесен, кырыгын, елын... көттем. Ниһаять, көннәрдән бер көнне үз теләгемне белдерү, тормышны ничек дәвам итү өчен киңәшү йөзеннән дә атам катына килдем.

— Улым, мәетләрнең рухыннан курык, киленнең атасына вәгъдә биргәнеңне онытма, сүзеңне таптасаң, тыныч яткан кабереннән дә кубарылыр, кем белән дә, кайда да бәхетле була алмассың. Алай да үзең беләсең. Инде балаларыгыз кул арасына керә. Синнән башка да яшәрләр. Миңа киленнең моннан да яхшысы юк. Бергәләшеп ничек тә торырбыз. Әле мин дә көчемдә, — дип бетерде ул сүзен.

Китсәм, үз кызына әйләнгән Мәхәббәт әтинең бердәнбере булып калачак иде. Ә минем бердәнберем кем? Ташлап китсәм, атам йортына кире кайту юк дигән сүз. Шул бердәнберемне тапмасам... Тормышым барып чыкмаса...

Сорауларыма бер-бер җавап табарга теләгәндәй, сабый чагым узган үзәнлеккә киттем. Мехмет карт утырган тупыл төбенә килеп яттым. Күктә ак болытлар йөзә. Нәкъ Сөенеч кияргә яраткан күлмәк кебек күпергән итәкле ак болытлар кебек иде алар. Бар көчемә:

— Сөенеч! — дип кычкырдым.

Ерак тауларга барып бәрелгән тавышым:

— Сөен-эч! — дигән кебек, колагыма кире ишетелгәндәй булды. Тилергән кешедәй кычкырып көләргә тотындым. Мине ташлап еракка агып киткән болытларга, тавышны тоткан таулар кебек, минем сүзнең мәгънәсен аңламаган картка, дөньяда булган һәр нәрсәгә ачуым күпергәннән-күперә бара иде.

— Сөенеч... — дидем мин, җирне тырнап.

— Сөенеч... — дидем мин, начар туфракта да шытарга җөрьәт иткән, баш калкыткан үләннәрне йодрыгым белән төя-төя.

* * *

Сөенеч... Гаҗәп тә инде бу дөнья! Сөенеч — күз яше, Мәхәббәт — күз яше. Күз яшеннән бер микъдар. Былбыллар яшеннән дә бер микъдар.

Мәхәббәт тикле мәхәббәтне яратма инде! Мондый исемне кушу да нинди фаҗигагә әйләнә ала икән. Таң калдым. Үзең көн дә «Мәхәббәт» дип эндәшкән ханымга күңелеңдә яратмау хисеннән башка һичбер тойгың булмасын. Сүзне өзәсем килмәде, Гайрәтне бүлеп, фикер кыстырмадым. Бушанган чакта кешегә киңәш-фикер кирәкмени? Су буена кызынырга килүчеләргә ясалган агач диванга терәлеп утырган, сөйләгән саен кечерәя барган Гайрәткә карата ниндидер аңлаешсыз хисләр бергә буталдылар.

* * *

Чәйханәгә юл тоттым. Касә арты касә чәй эчәсе урынга, җанны аракы белән басарга тырыштым. Ни эчсәм дә, исертмәде. Күңелдән Сөенеч сурәте, ансыз үткән хәсрәтле еллар китмәде. Мин аның инде гаиләле икәнлеген ишетеп белә идем. Бәхетле булгандырмы, юкмы — анысын белә алмадым. Ата-баба гадәте ирле хатынның хәлен белешү өчен дә күрешүне тыя шул. Начар йолалардырмы бездә — әйтә алмыйм. Ул гадәтләр, ышанулар газиз әнкәмнең гомерен озайткандай булды. Алар каенатамны теге дөньяга тыныч күңел белән кичтерде, атамны — кадерле, балаларымны әтиле итте. Минем җаным, шул киң сулы, мәрхәмәтле йолаларның ташлы ярларына бәрелә-бәрелә, вакыт уңаена акты, шул агымга каршы тора да, агымнан чыга да, ярлардан торып кыйнаган ташлардан исән-имин кала да алмады.

Мине рәнҗеткән шул ташларны ничек чүпләргә, читкә ыргытырга икәнлекне төшенә алмадым. Әгәр арыкның ярларын, төпләрен ныгыткан ташларны алып атсаң, ул кибәр, тиешле җиренә барып җитмәс, күпме адәмнәрне хәсрәтле, икмәксез һәм сусыз итәр. Ниһаять, шул йолаларны саклау, башкалар иминлеге хакына китерелгән корбан икәнлегемне чын-чынлап аңлагач, тынычланып калдым.

Күңелдән үпкә китте дип кенә әйтә алмыйм. Бик борчылган чакларымда шушы карт тупыл янына киләм дә, чалкан ятып, ак болытларны күзәтәм. Алар миңа вакыт-вакыт усал да, вакыт-вакыт бик мөлаем да булып күренәләр. Нәкъ Сөенеч кебек инде менә. Чәчләре генә, йөзләре генә бераз аграк. Кара кашлы Сөенечне сөйсәм дә, карасу болытларны сөймим мин. Үз дөньяма төс булган өченме?.. Әллә су буена Сөенеч ханым гел ак күлмәктән чыккангамы?..

Кече кызыма чиләкләр алып кайттым бүген. Пар былбыллысын түгел, чәчәк рәсеме төшкәнен. Болай да күңел яралы. Анда пар тапмаган былбыл сагышы бар.

Кызга әле генә ундүрт яшь тулды. Гомер үткән дә киткән. Бер көянтәдә тиң булмаган чиләкләр кебек чайкалганбыз. Түгелгәнбез, кемнәрнедер рөхсәтсез чылатканбыздыр да. Бу көянтәгә безне рөхсәт сорамый гына элгәннәр, сорамый гына хәсрәт суларын тутырганнар...

Нигә көн дә киләсез, имеш. Былбыл микъдарында мин юктыр, дисезме? Анда кем бары инде Сезгә билгеле. Әгәр тупылымны үз итмәсәгез, мин Сезне очратмас та идем. Килүемдә бер сер күрмәгез, дип, үземнең тормышымны сөйләдем. Хәер, сер дигәч тә, ул монда үскән һәр куакка, үзәндә туп типкән һәр балага билгеле.

Кызга чиләк алып кайттым бүген, дидемме әле? Былбыллысын түгел. Гөллесен. Былбыл үзе сайлап кунарлык гөл булсын дип...

* * *

Сөенеч — былбыл, Мәхәббәт — былбыл. Бер йөрәктә бер-берсенә охшамаган ике былбыл. Юк, өч былбыл. Өйдә тагын кызлар бар, ди бит. Былбылдан бер микъдар... Әгәр ул былбыллар тагын да артса,

үзе дә кош кебек тын алган йөрәкнең хәсрәтләре тагын да күбәер микәнни? Әгәр ул былбылларның берсе, башкаларның моңлы тавышын күмеп, җырлап җибәрсә?..

И Гайрәт, Гайрәт! Чал чәчле ир-егет йөрәгендә шулкадәр газап дип кем уйлаган?

Без, икебез дә тын калып, күктәге болытларга карап ятабыз. Алар арасында Сөенеч болыты да бар, ди бит Гайрәт. Шифа болыты булсын иде алар. Яңа танышымның йөрәген бәйләргә туган болыт.

Ерактан кайдандыр бер кызның шат чыркылдавы ишетелә. Без борылып караган якта ике яшүсмер, җитәкләшеп, болытлар артыннан йөгерәләр.

— Сөенеч! — дип кычкыра егет, тауларга йөз белән.

— Сөенеч! — дип кабатлый кар башлы болытлар.

Ни дип әйтергә белмичә, Гайрәткә карыйм. Аның йөзендә — бәхетле елмаю. Төшме бу, өнме? Әллә соң яшьлеген терелтеп саташабызмы? Ул, чалбар балакларын кага-кага, җирдән күтәрелә.

— Минем кызым ул, — ди Гайрәт. — Сөенечем. Синеңчә әйтсәк, шагыйрьчә әйтсәк, «вөҗүдем* гөлшанында тагын бер гөл».

*2004*

## Чикерткә

Клавдия Петровна күрше карчыгы белән чәйләп утырган җиреннән, эшләре барлыкны сылтау итеп, көндәгедән иртәрәк кузгалды. Акрын гына ишегеннән чыкты, бер-бер уйда кыяфәттә каталарын киде, кулындагы таягын авырлык белән йөртеп, үз ихатасына юнәлде. Күңелендә бер моңсулык иде. Ахирие Матрена Павловнаның шәһәргә китәр көннәре җиткән дә, хушлашу мәҗлесенә чакырган булып чыкты. Аш янында сүз ялганмады. Бер-бер кызык хәлнеме, яшьлекләренме исләренә төшерергә теләп тырышсалар — күңелләренә моңсуы килде, алдагы елга эшләр планлаштыра башласалар — күз төпләренә яшь бөялде. Ул хакта сүз башладылар, бу хакта — йә очына барып чыга алмадылар, йә әлеге хәлләрнең бер килешсез ягы исләренә төште дә, әлеге сүзне дә ник башлаганнарына үкенеч хисе биләде. Ахырда, Алла кушса, әле күрешербез, бергәләп җәйләр җәйләрбез, дип, язмышка буйсынгандай, тыныч кына саубуллаштылар.

Карчык, тимер күтәртмәне көч-хәл белән бавыннан тартып, чоланга үтте дә бер мәлгә тын калды. Йорттан кыштырдаган тавыш-мазар ишетелмиме дип колакларын шомартып торганнан соң, ярым җимерек икенче ишекне сак кына ачып, йорт эченә атлады. Көннәр буе искергән обойның каерылып торган кәгазьләрен кыштырдатып шаярган, өстәл аягын кимереп теш чарлаган Петя йөгереп каршысына килер дип көткән иде — күренмәде.

Клавдия Петровна карты Афанасийдан калган, инде ботак урыннары да шомарып беткән таяк белән идән тактасына суккалап карады — бер тавыш ишетелмәде. Аннан сул кулы белән ишек яңагына тотынды да, бераз гына читкәрәк китеп, инде үз буенда булып калган җиңел таякны да зур авырлык белән генә күтәреп, ишек өсләрен төрткәләп алды. Петя җавап бирмәде.

Аш өстәле торган аралыктадыр, минем белән качышлы уйнамакчыдыр дип, карчык, каплап торган чаршауның бер кырын ачып мич буена узгач, шатлыгыннан елмаеп җибәрде. Җыерчыклар арасына сеңеп беткән, пешмәгән ике шомырт шикелле күрәнсу күзләреннән сөенеч шәүләсе узды. Клавдия түтекәй утырмага киткәндә, сөт чөмереп калган Петя, көтеп арыганмы, идәнгә сузылып яткан да йокы бүсә иде. Аны уятмаска тырышып, карчык кергән юлыннан берьяклы йортның түренә чыкты. Өстәлдә улы Костядан килгән хат ята. Ул аны инде әллә ничә тапкыр укыган, ахириенә дә укытасы килә, әмма үзе дә, чәйгә чакыргач әйтергә бер сүз булсын дип, әлегә сер итеп саклаган иде.

Зәңгәр-күк тамырлы куллары, дер-дер килеп, хатка үрелделәр. Карчык, олаеп тапкангамы, тормышына чиксез шатлык өстәгән улының ягымлы сүзләрен сеңдергән кәгазь битләрен алып, юллар арасына да качкан җан җылысын тоярга теләгәндәй, башта — бер, аннан икенче битенә күйды.

— Ах, Костя, Костя, кадерлем минем, — диде ул. — Кулыңа мылтык тотып, Әфган тауларын кичкәндә дә онытмагансың мине. Ком-таш арасында бер йотым суга тилмереп ятканда да әниең турында уйлагансың. Рәхмәт, ай рәхмәт, балакаем. Анаң янына тизрәк кайтыйм дип, ничә дошманның башына җиткәнсең ләбаса. Ватанга чын сакчы үстереп биргән икәнмен!

Клавдия Петровнаның шул вакыт кунакка кайтачак улына татлы ризыклар хәзерләп тормавы исенә төште. Хәер, келәт матчасына каклаган каз эленгән, тырыска җимерек лапастагы утын әрдәнәсе астына чуар тавыгы көн дә салып торган йомыркалар җыелган. Быел кура җиләген дә киптереп тормады, алдагы елдагысы да ашалмаган, затлы нәселдән чыккан Манясы кечкенә алюмин бидунны тутырырлык сөт бирә. Иткә җәй көнендә шәһәрнең суыткычлы йортларында да кытлык, диләр. Талун белән, аена дүртәр йөз граммлап кына бирәләр, имеш. Итсез дә сыйларлыгы бар. Анысы солдат паюгында артыграктыр да әле. Беленен пешерер, кәҗә сөтеннән маен язар.

Май дигәннән, искергәнен Петяга ашатып бетерергә кирәк. Абыйсы кайткач, аңа да кунак ризыгыннан өлеш чыкмый калмас.

Ата тычкан Петяны Клавдия Петровнага Матрена Павловнаның оныгы Мишка бүләк итте. Шәһәр йорты подвалыннан иптәш малайлары белән тотып алган мескен җан иясен карчыкның усал килене фатирларында асрарга теләмәгән. Клавдия Петровна йортындагы тычканнарның барысын тәбе куеп тотып бетергән иде инде. Ни дип әйтергә дә белмәде, ахирие кыш шәһәргә киткәндә, иптәш тә булыр дип, үзендә калдырды.

Йортка үз күсе-тычканыңны ияләштерсәң, башкаларныкы килми дигәннәре рас, ахрысы. Шул көннән бирле ник ят бер тычкан идән астыннан өскә күтәрелсен. Хәер, карчыкның читкә ташып ашарлык артык ризыгы юк, булганы исә чәчелеп ятмый.

Клавдия түти Петяны кулга Манядан яңа савып алынган җылы сөт белән бик тиз ияләштерде, икенче елны җәй җәйләргә кайткан Матрена Павловна алырга керсә дә, ул аңа ияреп тормады. Үзен идәннән үрелеп алган карчыкның ишеккә дип борылуын күргәч, кул тиресен кинәттән бик каты тешләде дә, сикереп төшеп, караватастына шылды. Авыртудан күз читләре аска авышса да, ахирие түзде, хәтта чериләгәндәй дә итмәде. Бердәнбер күршесен үпкәләтүдән куркыпмы:

— Дуслашкансыз да икән, ярый инде, бергәләп яшәгез, көзен тагын сиңа кертәсе булыр иде бит, — дип куйды.

Клавдия Петровна, шуларны уйлый-уйлый, мич буена күз ташлады.

— Ах, Петя, Петя, нишләп һаман йоклыйсың син? Абыең кайтам дип хат язган, ул болай тик яткырмас. Сез хәзер өйдә ике ир кеше булачаксыз. Каралтыны рәтләрсез, лапас түбәсендәге имән кайрыларын тактага алмаштырырсыз, болдырны да терәүдә тотарга ярамас.

Кояш баеп килә иде. Клавдия Петровна ут яндырырга булды, әмма челтәр кушып ясаган тәрәзә өлгеләрен дә тартып тормады: бу тирәдән барыбер һичкем үтми шул.

— Кояш баешында черем итү бер дә яхшыга түгел. Чәйләп алырмындыр, ахрысы, сиңа да өлеш чыгар, — дигәләштереп, карчык кабат мич арасына узды. Картларча шаяртмакчы булып, таяк очы белән сак кына Петяның койрыгына төртте, үзе йонсыз колакларына карады.

— Әллә колагын да селкетми инде юньсезкәй, — диде Клавдия түти, инде аркасына ук катырак та төртеп. Чыелдау түгел, Петя селкенмәде дә.

Карчык эшнең нәрсәдә икәнлеген шунда ук аңлады. Петя җан тәслим кылган иде. Нишләргә дә белмичә, беравык дәшми торганнан соң, карчык белештермәстән:

— Урыны җәннәттә булсын, — дип куйды. Аннан кара яулыгының бөгәрләнеп беткән почмагы белән күзеннән тәгәрәгән бер тамчы яшьне сөртеп алды.

Иртән, кояшның беренче нурлары туфракка төшү белән, Клавдия Петровна, алма бакчасына чыгып, таяк очы белән карты Афанасий утырткан әнис төбенә тычкан салырлык кына кабер чокыды. Тезләнеп, капчыклап бәйләгән алъяпкычыннан алып, шул уемга Петяны салганда, әрекмән яфрагында хәл алып торган чикерткә карчыкның иңнәренә сикереп менде.

Тычкан да Алланың җан иясе бит, дип, белгән догаларын укый-укый өенә таба киткән карчык үзенә яңа иптәш алып кайтканлыгын сизмәде дә. Тыштан кергәндә, чолан өстәленнән ашап бетерелмәгән каклаган каз кисәкләрен, әчкелтем миләш суы тутырылган аракы шешәсен эләктерде. Әйберләр тоткан килеш, ишекләрне ничек ябарга белмичә, бер урында таптанып торганнан соң, куйгач, кире чыгарга булды. Карчыкның җилкәләрендә сәяхәт иткән чикерткә шул арада аш өстәленә кунаклап өлгерде.

Мәрхүмне соңгы юлга озату уңаеннан хәзерләнгән каты-токылы табын артында Клавдия түтидән башка һичкем юк иде. Чикерткә әйберләр арасында сикеренгәләп йөрде дә, нәрсә кабарга инде дигән кебек, канат-кулларын угалап алды:

— Пе-тя!

Карчык өстәлнең тавыш килгән почмагына караса — аннан аңа нәп-нәни яшькелт-соргылт җан иясе текәлгән.

— Әллә, Ходаем, Петяның җаны мунча чыршыгы* булып кайткан инде?

Карчыкның бармаклары, үзләреннән-үзләре көч алгандай, җитез генә төртенделәр:

— Иисусе...

Чикерткә шым калып карап торуында булды.

— Кил, Петя, ризыктан авыз ит, — диде карчык һәм, мич буеннан икенче стаканны алып, чикерткә каршысына куйды. Аннан үзенә салынган миләш суының яртысын сак кына буш савытка агызды.

— Синең ризалыгың өчен булсын! — Карчыкның чикерткә белән шул рәвешчә сөйләшеп утыруын берәү күрсә, исәрләнгән мәллә бу кортка, дип уйлар иде, әлбәттә. Ходай кушуы белән, авылның бу почмагындагы икенче өй — иртән шәһәргә китеп барган Матрена Павловнаныкы да бу төндә ут элдермәгән иде.

Ул арада чикерткә, инде үзен хуҗа итеп тойгандай, стакан ырмавына менеп утырды һәм, андагы суны татып карар өчен, егылмаска тырыша-тырыша, башын аска иеп маташты.

— Ой, Петенька, чыннан да, син икәнсең ләбаса! — диде карчык тагын, чикерткәнең үзен дә тануына ышандырырга теләгәндәй. — Китеп тә өлгермәдең, сагынып кайткансың да.

Карчыкның мәңгелеккә кипкән кебек күзләрен яшь каплады. Ул эчке бер сызлану катыш шатлык белән буыла-буыла елады.

— Петя, мин сиңа урынны үзем яныннан — мич өстеннән бирермен. Костя абыең кайтса, сәкедә йоклар. Ул әле яшь — кызлар кочаклап җылынып чагы. Менә безнең гомер ахырына якынлашып бара. Син мине кабат ташлап китмәссең бит? Күзләрем йомылганда, янымда булырсың, ишетсен колагың.

Ишетепме-ишетмиме, мич җылысына кинәнеп алган чикерткә кошларны узарга теләгәндәй сайрарга тотынды.

— Йортта чыршык булгач, радионың да кирәге калмады, — диде карчык, бер мактаныч тоеп, әйтерсең, аның йортында моңа кадәр радио-телевизорлар гөрләп утырган. — Менә Костя абыең гына кайтсын... Минем малай әйбәт тә угыл инде. Унлап дошманны үз кулым белән кырдым, әнкәй, дигән. Илгә бер дигән сакчы үстергәнмен бит, әй. Син көн дә шуның хөрмәтенә җырларсың, яме, Петенька?! Кайтсын гына, әле пичнең дә яңасын, күзгә төтен җибәрми торганын чыгарырбыз, тәрәзәгә ефәк челтәрләр алып эләрбез. Ул, бик күп акча белән кайтырмын, авыл кызларын күзли тор, дип, әманәт әйткән безгә. Синең күз минекеннән үткеррәк инде дә... Улың язмышын кеше кулына тапшырырга ярыймыни? Бер-беребезгә чит-ят булмасак та, минем улым ул гынамыни?!

Клавдия Петровна йортының түрендә ике рәсем бар. Берсеннән бәйрәм көннәрендә шәмнәр яктысыннан Гайсә пәйгамбәр үзе карап тора. Бүген дә ул моңсу күзләрен карчыкның үзенеке кебек сары йөзенә төбәгән. Икенче почмакта — бер үк төсле кутәртмә өстендә — улының фотосы. Рәсемнән солдат киемендәге егет карый, кулларын терсәктән бөгеп, бармакларын маңгаена терәгән. Фотоның астына зур хәрефләр белән «Ватан өчен гомеремне дә кызганмам!» дип язып куелган.

— Унлап дошманны кырган бит! — диде ана, баласы белән горурланып, кат-кат үзалдына. Аннан, кырылган җаннарның кяфер икәнлекләрен дә исенә төшереп: — Игелексез җаннарга, минем улымның гомерен ут астына куйганнарга тәмуг яныйдырмы инде... — дип өстәде. — Аллам сакласын, дөньялыкта хаталансалар да, алар да — кеше баласы лабаса. Аллага шөкер, менә минем Костя сугышка тәре тагып китте, тәре тагып кайтыр. Әле киткәндә, әйткәнне-ниткәнне көтеп тормады, чиркәүгә барып, изге суын да алды. Изге сулар сакласын инде угылкаемны.

Карчыкка Костяның рәсем читләрен бизәкләгән челтәр бүген никтер ошамады. Тегеләй тартты, болай, барыбер дә күңеленә хуш күренмәде. Аннан, шул турыда онытырга тырышыпмы, кяфер булган мөселманнарны кызганыпмы:

— Ходай ярлыкасын үзегезне, теге дөньяда туры юлны аңлатсын, — дип куйды. — Менә минем Костя — Аллага шөкер, христиан. Ун дошманның башына җиттем, дигән бит!

Клавдия Петровнаның кайгы белән башланган көне тагын улын көтү шатлыгы белән тәмамланды.

Костя кайтасы көн, төрле сәбәпләр белән, ерагайганнан- ерагая барды. Көз дә үтте, кышлар да ахырына җитте. Озын төннәрдә әле мич каршысында, әле мич башында Петенька белән алар һаман батыр солдат хакында гына гәп кордылар. Җилнең чолан ишегенең бавыннан тартуын да, морҗа башында улавын да, киртә кырында үскән карт тупылның төндә сыкрануларын да Костяның ишектән керүенә, урамнан аваз салуына фаразладылар. Егет исә кайтмады да кайтмады.

Петя шул арада үсте, күзләре тагын да зураеп китте, тавышлары тагын да яшелләнде. Ул, кай ягы беләндер, җәй буе симертелеп, яшь бикәчләр артыннан йөгерә башлаган калай әтәчкә охшаган иде. Карчык аны кулларына алып үчтекиләргә, учларыннан өреп бер стенадан икенчесенә кадәр сикертергә гадәтләнде, йортның тагын бер хуҗасына тәмам ияләште.

Карчыкның өмете инде өзелде дигәндә, авыр чемоданнарын күтәреп, Костя кайтып төште. Күрешкәч, тиз арада өстәл хәзерләрмен дип еллар буе хыялланган Клавдия түтекәй олыгайган, ирәйгән, чибәрләнгән бу егеткә үзе дә, онытылып, гашыйк кызлар күзе белән карап торды.

Кичен аларның сөйләшеп сүзе бетмәде, Костя алып кайткан күчтәнәчләрне ашап һич туймадылар. Мондый кадерле кунакны карчыкның тагын да ныграк хөрмәтлисе килә иде. Берни дә уйлап тапмагач, ул үзенең җылы мич башын бер төнгә Костяга биреп торырга булды.

Ниһаять, утлар да сүнде, йокларга да яттылар, тик Костяның гына керфекләренә йокы эленмәде. Ул каты солдат караватына күнеккән, аңа әнисенең биек ястыкларында башы әйләнә сыман тоела иде. Җитмәсә, төн уртасында әллә каян гына мунча чыршыгының сайраганы ишетелә башлады. Бер сәгать түзде егет, ике сәгать, торып ут яндырырга батырчылык итмәде, бар нәрсәне пыр туздырып, чикерткә эзли башлады.

Карчыкның учларында биеп кенә яшәгән Петя, кунак абыйсының ни кылырга җыенганын белмәгәнгә, кул аркасына сикереп менде дә тагын да шәбрәк сайрарга тотынды.

— Аһ, мур кыргыры! Әле син ун дошманның башына җиткән батырдан да батыррак булмакчымы?! — Костя, инде бернинди ачусыз-нисез генә, шаярткан бер кыяфәттә, икенче кулы белән чикерткәне шап итеп кысты да, җан тәслим кылганын белгәч кенә, төшеп, мич учагына атты.

— Әнием дә тынычлап йоклар, миңа да ял ярыйдыр, — дисә дә, инде йортка таң яктысы үтә башлаган, йокы да каядыр китеп барган иде.

Шулай да Костя Клавдия түтинең Маняны сауганын, мичкә ут элдергәнен, өстәл хәзерләгәнен, йомшак тавыш белән табынга дәшкәнен көтте. Карчык исә, нидер югалткан шикелле, мич тирәсендә әйләнгәләп йөрүендә булды.

— Петя, Петя! — диде ул бераздан, эче пошканрак тавыш белән. — Петя, дим, чык инде, төне буе яныма килмәдең, кайда йөрисең соң? Кунак абыең торганчы, су эчерим үзеңә.

Бу сүзләрдән аптырашта калган Костя мич башыннан сикереп төшкән һәм әнисенә карап тора иде.

— Нинди Петя? Син ишегалдында чагында һичкем дә кермәде. Бу өйдә качарлык урыны бармыни аның? — диде ул бераздан.

— Нинди Петя дип... Минем өйдәшем инде. Дустым, якыным дисәң дә була. Чикерткә...

— Әллә мин берәр бала-чагамы дип торам. Чикерткә эзләр дип кемнең башына килер? Үтердем мин аны, әнкәй, мичкә аттым! — диде Костя, көлә-көлә.

— Үтердем? Мичкә... — Клавдия карчыкның күз алдыннан караңгы шәүләләр йөгергәндәй булды, ул да түгел, алар барысы да чикерткә, тычкан балаларына әверелделәр дә ике аякка басып биешә башладылар. Мичкә аркасы белән терәлгән карчык, инде берни аңламый, араламый башлагач, әкрен генә мич буйлап шуып төште. Аның сулышы ешайган, күзләре аларган иде. Костя тиз генә су, дару каптырды, көчле беләкләренә алып, карчыкны сәке өстенә илтеп яткырды, коргаксыл кулларыннан, итсезләнгән битендә тырпайган аксыл алмаларыннан үпте.

— Мин киткәнче, терелә күр, әнкәй... — диде ул, еларга җитешеп. — Исән-имин саубуллаш, хәер-догаңда кал инде, әнкәй.

— Киткәч? Син кабат китәсең дәмени?.. Кем белән яшәргә миңа, Костя? Әйт, кем белән? — дип сорады аңышып киткәндәй, әмма берни күрмәгән, күзләре томаланган карчык.

Солдат егет дәшмәде. Ул әнисенә хезмәт срогын тагын да озынайтканын әйтергә дә оныткалыгын исенә төшерде. Үзенең дә күзенә яшь килде.

— Юк, юк, китмәм, — диде ул бераздан, әнисе тынычлансын өчен генә.

Клавдия Петровнаның итсез беләкләре суынганнан-суына кебек тоелды, күзләренең мәгънәсе югалганнан-югала барды. Бераздан ул:

— Петя янына ал мине, Ходам! Иисусе... — диде дә соңгы тынын алды.

Чукынырга дип җыелган бармаклары, өлгерә алмыйча, таралып, борын турысында тырпайдылар.

*2004*

## Чегән кызы

Яңа гына яңгыр җебетеп үткән кара җирдә вак-вак тояк эзләре калдырып, урамны иңләп сарык көтүе кайта; әле бабамнарның чираты җитәргә иртәрәк икән: көтүчесе бүген дә түбән оч малае.

Таныш булмаган кешегә дә өстендәге киемнәре аның авыр тормышлы гаиләдән икәнлеген аңлата. Бөдрә чәчләре — кепка ертыкларыннан, аяк бармаклары кеда тишекләреннән яңгырдан соң саф һава суларга чыкканнар. Тез өсләреннән генә калган чалбар балаклары чачакланып беткән. Йөзе, каралып, бакыр төсенә кергән. Җәй буе башкалар өчен дә аның көтү көткәнлеген әйтеп тора.

Карасу, ярылып беткән иреннәре арасыннан миңа ап-ак тешләрен ыржайтып, турыбызны узып барганда, ул көн саен:

— Сәлам, Чегән кызы! — дип кычкыра.

Кичке уеннарга төшмәвенә үч итеп күчергән ташлары өстендә утыруымны күреп, эченнән сөенәдер әле...

Мин торганчы ук, кояш чыгар-чыкмаста, әбием белән бабам бик тәмләп чәй эчәләр. Инде уянган булсам да, җылы юрган астында аларның сөйләшкәннәрен тыңлап ятам.

Бабам һәркем белән үзенчә җор. Әбигә ул шаян сүзләрне үлчәп кенә, тәмен белеп кенә әйтә. Ялгышын да ычкындырып, үпкәләтеп куярмын дип курыкканга, күбрәк башкалар турында сөйли:

— Карчык, бүген өй артында кайсыдыр бик тырышты, ташларны тиешле урынга күчереп маташты, ахрысы, хезмәт көне язарсың, онытма, яме. Кызыңа әйт (анысы мин булам инде): безгә эш калдырмасын , кичәге шикелле, кеше күрмәгәндә, иптәшләре белән бакча җиләген ашап чыксыннар. Каршы як тупылга, балта остасына әйтеп, утыргыч ясатып куйдыр. Тәрәзәдән фонарь яктысы уйнатып, сине кичке уенга чакырып утырган берәү төнлә шуның башыннан егылып төшмәде микән? Бик нык шартлау тавышы ишетелде. Әмирикәннәр, безнең калхузда атом бомбасын сыныйлар икән дип, сугыш ачмасалар ярый инде. Фельдшергә әйтерсең: кем булса да, калхуз хисабына бүлнични алмасын...

Әби дәшми. Ишетмиме, ишетергә теләмиме шунда. Ни көлми, мутлыгым өчен — ни мине, юк-бар сүз сөйләп утырганга — ни бабамны әрләми. Әби утырган өстәл почмагыннан чынаякларга торып-торып су акканы гына ишетелә.

Менә бераздан ул да сүзгә кысылырга итте, ахрысы:

— Теге ни, Фәхерниса малаеның үз әтисе килеп чыккан бит. Бу якларга бөтен нәсел-нәсәбе белән. Башта Фәргатьне көтүдән урлап китмәкче булганнар.Урман авызына качып өлгергән. Башка беркем урынына көтүгә чыгасым, алар белән очрашасым юк, дип әйтә, ди.

— И-и-и, юк сүздер ул. Дөрес булса да, үзең күрмәгәнгә ышанма. — Гомер буе әкият сөйләп, бала-чаганы көлдереп, артыгы белән җитди әбиемне дә ялыктырып яшәгән бабам өйгә гайбәт сүзе кертми. Хәер,, колакка катырак булгач, сөйләгән чакларында да, пыш-пыш кына чыга торган имеш-мимешләрне ул ишетми дә, шуңа күрә бу авыл яңалыкларын мин дә әллә ни белмим.

Таныш малай турында сүз чыккач, калын юрганымның почмагын бераз күтәребрәк тә куйган идем, тик сөйләшү шул урында өзелде дә кабат ялганмады. Мин исә тәмам аптыраушта калдым.

Хәерниса малае шул Фәргать була ич инде. Әтиләре — бөрешеп кенә йөри торган, кешегә күтәрелеп карарга да базмаучы бер авыл агае. Өстендә — кышын да, җәен дә, көзен дә бер үк сырма. Фәргать минем белән бер яшьтә булса да, әтисе шактый олы күренә. Ул инде калхуз эшенә дә йөрми. Көннәр буе кибет каршындагы эскәмиядә тәмәке пыскытып утыра. Бу авылга килеп, йортка кереп, мөселман диненә күчкән бер керәшен карты.

— Сыеныр урыны булмагач, нишләсен инде, бичара, — ди әбием аның турында. Яшь чагында кай якларда йөргән ул, кемнәр белән яшәгән — беркем белми. Күрше Крещенкадан гына булса да аның хакында кызыксынган, белешкән кеше дә юк. Авыл мәчесе абзарда тавыклар арасында ничек яши бирә, Җәгъфәр абый — Җәгүр карт та шулай. Иртән аның кибеткә килгәнен, кич кайтып барганын күрәсең. Килми калса да, аның утыргычына башка берәү утырмый.

Керәшеннәр чолганышында яшәгәнгәме, Аксуда бөтен мәзәк, мәкаль — шулар турында гына.

— Керәшеннең акылы керделе дә чыктылы, — диде бервакыт Фәргать тә үзалдына. Әтисе керәшен була торып, ул нигә шулай ди торгандыр — кайтарып сорамадым. Тегермән буасы янында яткан киемнәреннән хач ясап куйдым да, юеш купальникларымны да алмаштырмыйча, ярым шәрә килеш су буеннан кайтып киттем. Үзеңне бел — син кем, янәсе.

Фәргать ул көнне кичке уеннарга чыкмады: миңа үпкәләвен аңлатты булса кирәк, әмма аның бу ачуы озакка бармады. Ул тагын клуб янындагы уенлыкка килә һәм мине турыбызга кадәр озатып куя торган булды. Дөрес, бераз кырысрак әбием мине дә көн саен чирәмлеккә төшерми, Фәргать андый кичтә дә барыбер капка төбебезгә кайта. Тәрәзә астында сызгырып торып, бабамның теңкәсен корыта йә, үзенчә берbegin ширлек эшләп, өенә китеп бара.

Монда, бу кыз миңа гашыйк булсын дип, чәчәк, бүләк ташымыйлар. Капка төбендә әләктереп алып, ник минем белән йөрмисең, дип, үзегеңә үтәләр. Мин инде бу гадәтләргә ияләнеп киләм — авыл кызына әйләнеп барам.

Авыл кызына әйләнәм, дисәм дә, тере сыердан да шүрлим үзем. Көтү чираты җиткәндә, шәһәр ягын каера башлыйм. Узган елгы көтү дә бүгенгә кадәр халык теленнән төшми.

Безгә иң эссе көннәрнең берендә туры килде ул көтү дигәннәре. Баш очында — җем иткән кояш, җилнең әсәре юк. Ятабыз арыш басуы буенда, укый торган китабыбыз белән шул кояштан битләребезне каплап. Тын кысылган, тәннәр хәлсез.

Башта, ничек кенә чыдарга көн буе дигән уйдан гайре һични булмаган бер мизгелдә әллә каян килеп чыккан салкын җил исәргә тотынды. Ул да түгел, еракта, бик еракта, тәннәрне чымырдатып, яшен яшьнәде, күк күкрәде, офыкта куркыныч кара болытларның, өерелеп, безгә таба килгәннәре күренде. Авылның икенче башында шул ук кояш, шул ук эсселек иде әле.

Бу хәл вакытлы гына дип уйлап, адашкан болытлар узганчы, күтәртелгән күпер астындагы кеше биеклеге торбаларга кереп качарга булдык. Ул ара көзнеке кебек өшеткеч яңгыр тамчылары да төшкәли башлады.

Күпер астында озак юанырга язмаган икән. Ерак урманнан ук тау елгасы тизлеге белән агып төшкән кап-кара ташкын торба эченнән безне ияртеп алып та китте. Абыем:

— Торба тоташкан ярыкларга тотын! — дип кычкырырга гына өлгерде.

Мин үзем дә, эшнең нәрсәдә икәнлеген чамалап, бар көчем белән тырышып, шуларга эләгеп калган идем инде. Җәй эссесендә кипкән елга тигезлегендәге торбаның икенче башы үзеннән бер-ике метр гына арырак тирән чоңгылга алып чыга, ә чоңгыл төбендә эре-эре ташлардан тыш берни юк. Алар, язгы сулар белән ераклардан ук агып килеп, гомергә шул чокырда утырып калганнар.

Ләмле, үләнле, урман-басу туфраклы су бугазны чиркандыра, югары күтәрелгән борын тишекләренә керергә әзерләнә. Торба ярыкларына ныграк берегү өчен, инде кедаларымны да ташкынга агыздым. Сәдәфләре чишелеп, агымга ияргән кофтам үзе белән мине дә торба авызына сөйри башлагач, кулларымны ычкындырып алып, алардан да арындым.

Ташкын торган саен көчәя бара. Абыем, аякларым арасыннан агып, якты дөньяга чыгып китте. Түзсәм, мин инде күп булса ике-өч минут түзә алырмын. Куркудан дога ук укый башлаганда, абыемның бик каты кычкырганы ишетелде:

— Мин исән! Әйдә, син дә ак! Торба өстенә тартып алырмын!

Ычкынып китеп, ташкын кочагында барганда, исән калуга өмет бетте. Секундлар — сәгать озынлыгында, хәрәкәтләр әкренәйтелгән тасмадагыдай тоелды. Менә торбаны да чыктым. Вак-вак ташлар өстеннән сикерә-сикерә, чоңгылга килеп төштем генә дигәндә, көчле куллар мине каядыр читкә алып ыргытты. Упкын кырыена баскан абыем әнә шулай мине үлем тырнагыннан алып калды. Тәннең, кул-аякның киселмәгән, бәрелмәгән җире юк. Килеп төшкән урынымда кымшанмый да ятам.

Күктә чалт иткән кояш. Җил тынган. Болытлар качып беткән. Яңгыр сибәли башлаган килеш туктаган, тузанны да басмаган. Басуга таралып, яшь арышка рәхәтләнгән сарыкларның мәэлдәгәне ишетелә. Күтәрткән юл өстеннән чегән таборы узып бара... Тагын да арырак шул ук юлдан кулына озын таяк тоткан бабам килә.

— Сез нәрсә?! Әҗәтканалар! Ашлыкны әрәм итеп! — Бик ачуы чыкканда гына әйтә торган сүзләренең мәгънәсен аңламасам да, куркып киттем. Көч-хәл белән генә күтәрелдем дә, кан саркыган аякларымны сөйрәп кенә, сарыкларны җыярга дип, арыш басуына юнәлдем. Шул чакта гына тузан туздырып йөгергән Фәргатьне абайладым. Әмма ул, гадәттәгечә, кара-чутырларыма төрттереп:

— Сәлам, Чегән кызы! — дип кычкырмый. Мине күргәч, барган юлыннан кире туктап борыла да инде авылга таба сыпырта. Миңа булышмавына, яныма килмәвенә үпкәләп, үзүземә тагын кич чыкмаска вәгъдә бирәм.

Капка төбендәге утыргычта әнә шуларны уйлап утырам. Кисәк кенә әти-әнием янына, шәһәрдәге дусларым арасына китәсем килә башлый. Иртән, киләсе җәйгә кайтасыма өметләндереп, әбиләрем белән саубуллашам.

...Җәйме, әбиемнәрме, авылның кечке уеннарымы, әллә башка берәүме — кайсы ныграк сагындыргандыр — институтка кабул итү имтиханнарын тапшырып бетерү белән үк, авылга җыена башлыйм.

Көтелмәгәндә килеп төшүем белән шаккатырырга теләп, бакча артыннан, басу капкасыннан гына ромашкалы сукмактан төшеп киләм. Койма буенда киптерергә дип таратылган урман печәне дә, буразна араларында чүп тә күренми. Пөхтә, җыйнак бакчада ап-ак ромашкаларга гына тимәгәннәр.

Калын кашлы, салынкы иренле, зур корсаклы күрше абыйсы, җиләк-җимеш бакчаларының киртәсенә терәлеп, мине көтә. Сәламемне алмыйча кереп китмәсен белгәнгә, адымнарымны әкренәйтәм, тәкатен сыныйм. Ул сабырсыз булып чыга, еректан ук , яратып, Фәргать кебек:

— О, Чегән кызыбыз кайтып та җиткән икән! — ди.

Аның бу сәламе узган еллардан калган истәлекләрне яңарта. Күңелемә бүген үк кич чыгарга дип беркетеп куям.

Бабамнар — һәрвакыттагыча, самавырлы өстәл тирәсендә. Әбием — җемелдәп кенә көлеп, аның шаяруларын тыңлауда. Мин аларны ишегалды тәрәзәсеннән әллә кайчан күрдем инде.

Менә, ялан аякларыма йомшак кына басып, ишектән узам, мич кырыена гына сыенып, аларга якынаям да, берни булмаган шикелле, өстәл янына килеп утырам:

— Әби, чәй ясале-е-е.

Бер минут тынлык.

Аннан:

— Шулчаклы бабаң булырсың икән, — дип, әбием чәе өстендә каймак йөзеп йөргән чынаякны минем алдыма этеп куя. — Сизгәнмен диярсең — өч кешегә ясаганмын бит, әй.

Кич җиткәнне әллә нинди бер түземсезлек белән көтеп алдым. Сөйләгән сүземнең, эшләгән эшемнең рәте булмады. Инде төзәнеп-бизәнеп урамга чыгам дип торганда, кайтканымны ишетеп алган Әлфия килеп керде.

— Нихәл, кызый, — диде ул миңа, әле кичә генә аерылышкан кешедәй.

Аның да клубка төшүе икән. Капка төбендә, авыл яңалыклары, күргән-белгәннәр турында сөйләшеп, эңгер-меңгерне уздырдык. Сүз артыннан сүз ялганып, Фәргатькә килеп терәлде:

— Әлфия, ул әле минем кайтканны да белми торгандыр, җаен табып хәбәр итмәссеңме? Берәр дус егетең аркылымы шунда...

— Син әллә берни дә ишетмәдеңме?

— Нәрсәне?

— ...

— Аптыратмале, әйт инде!

— Фәргать өйләнде бит, ике балалы чегән хатыны алып кайтты. Аның әтисе дә чегән булган икән. Юктан гына барысы да кара-чутыр түгел бит инде алар! Җан тартмаса да, кан тарта шул...

Каян җан тартмасын ди?! Мин шунда гына аның ни өчен һәр килгән чегән таборы артыннан йөгерүен аңладым. Менә ни өчен миндә чегән кызы чалымнарын күргән ул!

— Ә Җәгъфәр абзый? Ул, ул нәрсә диде?

— Ул нәрсә дисен? Үзе дә йортка кергән кеше генә бит. Биштәрен аркасына асып, авылдан чыгып китте. Анысы да хәзер Җәгүр карт булып йөри торгандыр.

— Соң, Фәргать үзен баласы кебек күргән картны җибәрми кала алмаганмы?

— Һе... Фәргать... Аны телгә аласы да килми... Су буенда атна буе бәйрәм иттеләр дә, арбаларына төяләп, алары да китеп бардылар.

— Фәхернисаттәй?..

— Чеп-чи татар авылында чегәннәр арасында гомер кичерә алмый бит инде. Фәргате чегән баласы була торып, керәшен картын йортка кертер идемени? Анысы әле — хет үзебезнең милләттән. Алай да аңа да җиңел түгел...

— ...

— Фәхернисаттәй бик биреште. Елап, күзләре күрмәс булды. Хәзер көн дә — кибет каршындагы утыргычта. Әллә ирен, әллә Фәргатьне, әллә Җәгъфәр абзыйны көтә. Беркем белән берни сөйләшми.

Миндә дә чегән кызы гына күргән Фәргатькә карата җылы хисләр сүнгән, ниндидер ачумы, үпкәме, тәгаен генә аңлашылып бетмәгән кичерешләр бөреләнеп килә иде. Аларны үстерергә теләмәдем, сүзне башка кешеләргә, икенче дусларга бордым.

Иртән, шәһәр күчтәнәчләремне тотып, кибет турына киттем.

Эссе җәй кояшы астында Җәгъфәр карттан калган сырма эчендә шул сәләмәнең үзе кадәр генә булып утырган Фәхернисаттәйне ерактан ук шәйләдем. Мине күрмәгәнен белгәнгә, янына ук килеп тезләндем дә башымны кытыршы кулларына салдым. Аның кура ботагы кебек бармаклары, булдыра алган кадәр сак кына шуып, маңгаем астыннан чыктылар һәм чәч бөдрәләрем арасына кереп югалдылар. Танырга теләгән кебегрәк, карчык:

— Чегәнкәйме? — дип куйды.

Инде монысы да... шул сүз белән... тәмам...

— Чегәнкәем, алып кайт аны авылга, адашып, алдашып йөрмәсен. Синең кай төшең чегән кызыныкыннан ким?!

Фәргать минем өчен бик ерак иде шул инде. Аның хакында ишеткәннәр электә ике арада сузыла башлаган бик нечкә җепләрне дә кисте. Карасу-саргылт йөзе, йомык күз кабаклары, тузгыган чәчләре белән сырмадан аерылып та тормаган шушы бер мәхлук җан иясенә нәрсә дип җавап кайтарасың?.. Тезләрен кысып-кысып кочаклаудан башка чара тапмадым.

Бу җәй минем өчен узган иде инде... Юк-бар эшләремне сылтау итеп, озак та тормый, әбиләрдән китеп бардым.

...Поездыбыз үтеп барган Сазтамак тукталышы тирәсендә, чуар күлмәкләрен җилфердәтеп, чегәннәр мәш килә. Безнең якларда аларга инде күптән ияләшеп беткәннәр, әллә ни игътибарга алган кеше дә юк. Мин исә нигәдер, шулар арасында Фәргатьне күрермен дә имәнеп китәрмен шикелле, тәрәзәнең каплавычларын төшереп куйдым.

— Яратмыйм шул чегәннәрне, — диде купедаш рус ханымы. — Илсез, җирсез халык, әле менә мин баштарак, Сезне дә чегән кызы түгел микән дип, куркыбрак калган идем.

Белдекле йөзле бу апа үзалдына сөйләнә дә сөйләнә. Аның сүзләре дә, поезд текелдәве дә, йөрәктән башта шом булып ургылып чыккан, аннан бөтен тәнемне урап алган дала көе астында йотылганнан-йоты-

ла барып, тәмам ишетелмәс булдылар. Ул шундый көчле, моңлы иде ки, аңарда аяз көндә таулар күкрәгеннән агып төшкән ташу дәртләре дә, кыяларга бәрелгән кайтавазлар яңгыравыгы да, мәхәббәттә аңлашу җиткергән таң җилләре сулышы да, кире кагылган хисләр ыңгырашуы да — барысы да бар. Шушы дулкынга ияреп, үз-үземне белештермәстән, атылып, тамбурга чыкканмын да, иң якын кешеләремнән аерылып китүемне яңа гына аңлагандай, стоп-кранга китереп басканмын...

*1995*

## Җил бизәге

Үзе җитәкләгән кафедра хезмәткәрләре аның картаясына өметләрен тәмам өзгән бервакытта — көтмәгәндә-уйламаганда — профессор биреште. Әле кайчан гына, кара кайгыга төшереп, чәчләренә йөгергән көмеш нурлар бер тотам сүс арасында югалып ук калдылар. Күзләренең агы саргайды, түсе уңган бит алмалары, әнисен югалткан куян баласыныкыдай дер-дер килеп, йөзенә куркак бер кыяфәт бирде.

Кечерәйгәнлектән шифоньер түренә елышкан костюмнары яңадан өстенә менде. Әмма иреннәре һаман да уйнак, елкылдык, гәүдәсе элеккечә төз, мәһабәт иде.

Ул үзенең бик озын гомер яшәгәнлегенә хатынын, сукыр эчәгесе белән ашказанының яртысын, тыңлаусыз маңгай чәчләрен һәм бөтен тешләрен югалтып бетергәч тә ышанмады. Аңа яшерен мәхәббәт тоткан студентка кызлар да, кайсы кемгә чыгып, бер-бер артлы балалар үстерделәр, секретарь-машинистка да, җае туры килгәндә, яшьрәк мөдирләргә күчү ягын карады, еллар буе күңел сердәшчесе булган шагыйрә ханым да күренми башлады. Әллә шигырьләр дөньясына, әллә шул дөнья тудырган ыгы-зыгыларга батты...

Инде соңгы тапкыр чәйләп утырганнан бирле никадәр вакыт узганы да онытылган иде. Алар, көндәгечә, шушы бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәл тирәсенә җыелдылар. Бу елда гына укуын тәмамлап, аспирантурага калган яшь кыз да шунда. Кып-кызыл костюмыннан. Тыз-быз килеп, чәй ясап, шаян сүзләр аткалап йөри. Затлы муенсалары, тән хәрәкәтенә ияреп, әллә нинди коткылар салып, елык-елык килә. Тамчы кебек эшләнгән колаксалары шәрә җилкәләренә үк тиеп тора. Ялгыш кына сүтелеп киткән кебек итәге тулы ботларын сөеп уйный.

Кемгә генә охшаган соң, дип уйлады ул аның турында һәм нигәдер бөтенләй охшамаган да. Чынлыкта исә кыз нәрсәсе беләндер әле үз укучысы чагында ук күзе төшеп өйләнгән хатынын хәтерләтә иде. Шул ук сап-сары чәч, сызып кына куйган кебек каш, бераз зуррак булса да, вакытында чытлыклы гына җыела белгән иреннәре янында мәхәббәт чокыры...

Кечкенә борын яфраклары да, колак яфраклары да хатыны Гөлүсәнеке кебек иде бугай. Әйе, әйе! Һәм... нәрсәседер чит, үзгә. Әллә кирәгеннән артык иркен тотуымы, урынында тора белмәгән күзләренең бертуктаусыз кемнедер эзләвеме, шул ук ирен читләренә яшеренгән, тоемлы ирләр генә сизәрлек тән дәртеме...

Заманы да башка булгандыр инде. Хатыны Гөлүсә боларның барысыннан да мәхрүм иде шул. Өйдә мәче кебек мыштым гына йөри, чит-ят кеше килгәндә, өстәл хәзерли дә үз бүлмәсенә кереп югала. Сирәкмирәк иркәләүләренә дә коры гына:

— Атасы-ы, балалар... — дип җавап бирә. Үзенең үпкәне, кочканы юк та юк инде ул. Әллә шуңа, әллә эчендә азгыннар шайтаны котырганга, никадәрле хөрмәт итсә дә, ир хыянәтсез яши алмады. Хатыны да моны белә, дәшми, шулай тиеш кебек, тыныч кына гомер кичерә. Соң кайтканда да — ашы әзер, кайда йөрдең, дип сораган кеше юк. Башка берәүгә өйләнсә, ул ничек яшәгән булыр иде, хәзер тәгаен генә фаразлау да бик кыен.

Ике арада кабынырга тиешле көчле яратуга өмет егет чакларында ук калды бугай. Хәер, алар өйләнешкән төннәрен дә икесе ике тулай торакта уздырдылар. Бүлмәгә яшереп алып кайтып, аның да дәрәҗәсен төшерәсе, иптәшләренең читкә китеп куныуын да үтенәсе килмәде. Каникуллар башланырга да озак калмаганга, зөфаф төне өчен шуны көтәргә булды. Көздә, икесенә бер бүлмә алып, карт белән карчык кебек кыштыр-мыштыр яшәп киттеләр.

Шул озын гомерендә ул чын-чынлап шагыйрә ханымга гашыйк булган иде бит, җырлар җырлап кына аңлата алмады, сүз белән әйтергә кирәклесен тапмады. Ут кебек кабынган мәхәббәте тышка чыкмаган килеш басылды. Дөрес, алар бергә кичәләргә йөриләр, очрашып чәй эчәләр, шигырь укыйлар... Күңелендә туган теләкләр шул кысалар эчендә генә сыешмаслык булганга, тәнен гел йөгәндә тотты.

Шагыйрә ханым аны яраткандырмы, юктырмы — аңлап булырлык зат түгел иде. Мактау сүзләрен дә уенга алып, яңгыратып бер көлә, ачылган кочактан да шома гына шуып чыга.

Сагындым, дип елмаеп, атылып-бәрелеп керә дә үзе дә нәрсәдәндер тыелган шикелле туктап кала, аннан тыныч кына ике куллап күрешә.

— Җил бизәге, — диде ул, серле итеп, Эльвира туташ белән таныштырганда. Аннан сәерсенеп карап торган шәһәр кызына: — Сезне бик матур, дип әйтүем, — дип өстәде.

Бу сүз карт профессорның да җанына җылы йөгертте: әнә ул да матурлыгын таныды, хатын-кыз була торып таныды.

Икенче килгәндәге сүзләре генә бераз сагайтты:

— Җилнең бизәге коелмадымы әле?

Керә-керешкә әйтелгән бу сүзләр үпкәләтерлек тә иде.

— Бизәк бизәк инде ул, коелган җирендә дә ялтырап ята.

— Әйе, әйе, кайда да ялтырый... Мин шул турыда әйтәм дә инде. — Чишмә тавышыдай көлү ,мәкерләрәк тоелса да, бүлмәгә язгы сафлык, рәхәтлек алып килде. Профессор кышка дип ныклап ябылган тәрәзәләрне каерып ачты. Көлү сафлыгына язгы җилләр яңадан-яңа хуш исләр өстәде.

— Карале, җил бизәге... бер дә начар чагыштыру түгел, — дип сөенде ул үзалдына. — Әнә җилдә, чыннан да, никадәрле бизәк.

Ул да булмады, бүлмәгә тулып-ташып кергән җил, тәрәзәләрне шапылдатып ябып, кире чыгып та китте.

Мәҗлес тынды. Моңарчы чәйдән бервакытта да баш тартмаган шагыйрә дә өстәл артына утырып тормагач, ниндидер авыр тынлык урнашты.

— Мин хушлашырга кердем, — диде ханым. — Китәм. Башка шәһәргә. Башка йортка. Башка дөньяга.

— Бездән качыпмы? — Артына ук килеп баскан профессорның җылы сулышы муен чокырына кунып калган шикелле, ханым өстендәге плащының якаларын күтәреп куйды.

— Юк, шигырьдән качып. Гадирәк торасы, гаиләле буласы килеп. Туганнарыма да якынаермын.

— Ә мин синсез, хиссез нишләрмен, хыялыем, — диде профессор, шаярмакчы булып, әмма ятышсыз рифмалар артыннан ук тамагына төер килеп тыгылды. Әйтерсең лә, бергә эчеләсе яшьләр шунда килеп бөялделәр.

— Җилдә бизәк күп бит, — диде ханым нигәдер. Профессор көтелмәгән хәбәрдән аңгырайган баш мие белән аның ни әйтергә теләгәнен аңлый алмады, әллә ишетеп үк бетермәгәндер дә. Шапылдап кәнәфиенә килеп утырды да өнсез калды.

Ханым китте. Яшел плащының итәкләрен җилфердәтеп, инде Ленин урамы буйлап йөгерә торгандыр. Кая китә ул? Нигә китә? Әле яшиләр иде бит. Шигырь язу шулай ук начар микәнни соң? Авыр микәнни? Тыңлаучысы барда...

Аңа таба якынайган томан эченнән кешеләр күренмәс булды, бераздан кызыл күлмәкле кыз калкып чыкты. Менә ул аның янына ук килде. Җансыз кулларын, үзенең нечкә бармаклары белән тотып, күкрәгенә китерде. Ташкурчак йодрыгын бар итеп тоя башлаган профессор кинәт айнып китте. Бүлмәдә беркем калмаган.

— Мин Сезне бик тә, бик тә яратам, — диде кыз, иреннәрен чак кына, оялып кына тидереп. Аннан сүзне башкага күчерде:

— Сез миңа ярдәм итәрсез бит?

Кызның ни хакында әйткәнлеген аңлау хәлендә үк булмаса да, профессор да елмаеп:

— Әлбәттә, — дип җавап кайтарды.

Әлбәттә! Әлбәттә! Шундый яшь, чибәр, матурлыкның үзе кебек кызга ярдәм итмиме соң?! Аның бөтен гомере алда әле...

Әйе, менә аныкы узган икән. Шундый кызлар арасында еллары да саналмый узган иде. Ул җансыз кулын сак кына кире тартып алды да икенчесе — терсе белән, йомшак кына итеп, кызның нәүмизләнеп көткән күкрәкләренә кагылмыйча, бармакларына тидерде:

— Эльвира, чәйне яңарт әле.

Чәйләр эчкәч, авыр булып узган көн дә артта калды кебек. Профессорның күңелендә менә шушы сары чәчләрдән, зәңгәр күзләрдән, җанына якын мишәр сүзләреннән башка берни юк, һәм әллә инде берни кирәкми дә иде. Бераздан бүлмәгә яшь бер укытучы — декан ярдәмчесе килеп керде, бергә эшләсе эшләре барлыгын исенә төшерде. Профессор, ул эшне егетнең үзенә генә тапшырып, бүлмә ачкычын калдырып кайтырга чыкты.

Баскычтан төшкәндә генә, хыял дәрьясында йөзеп, күзлеген, каләмнәрен онытып калдырганлыгын аңлады. Кире керәсе итте. Иртәгә килмәячәк, дәресләре юк иде.

Әкрен-әкрен генә күтәрелгәндә, шагыйрә ханымны кабат исенә төшерде. Җил бизәге дип, нәрсә аңлатырга теләде соң ул? Матурлыкка гына ишарәләдеме икән? Ә кыз, чыннан да, матур бит. Сүнеп барган теләкләрне уятырлык, дәртләрне кузгатырлык матур.

Профессор үзенең Себер имәненнән ясалган ишеген болай да эчке бер шомлану белән ачкан иде. Аннан имәнеп үк китте. Аның креслосында, аның күзлеген борын очларына элеп, башына аның эшләпәсен киеп, әлеге яшь укытучы утыра. Куллары... кочагына ук сеңеп беткән аспирантканың күлмәк изүен чишеп азаплана...

Профессор түзмәде, эчке иләмсез бер тавыш белән:

— Җилбәзәк! — дип кычкырып ук җибәрде дә тупсага килеп төште. Егет белән кыз көтмәгәндә җитәкчеләренең җан тәслим кылганлыгын башларына да китермәделәр, чөнки, соңгы сулышын алганда, шагыйрә сүзләренең мәгънәсенә төшенгәнгә туган серле бер елмаю профессорның ирен читләренә кунган иде.

— «Җилбәзәк»не этимология сүзлегенә өстәргә кирәк, — дип уйлады ул, үзе дә үлеп барганлыгына ышанмаганга.

*1996*

## Баш очында болытлар

Минем өчен болытлардан да якынрак һәм алардан да яратмаганрак тагын ни дә булса бар микән — белмим. Дөньяга ишек тә, тәрәзә дә булып хезмәт иткән җир асты юлы капкачын читкә этәреп, менә әле дә җәйге җиңел кауры́й болытларга карап ятам. Мәңгелеккә су астына яшәргә күчкән диңгезчемени! Ул да үзенең түгәрәк иллюминаторы каршысыннан тегеләйгә-болайга йөзеп йөргән балыкларны минем кебек күзәтә булыр.

Түп-түгәрәк дөнья, түгәрәк күк йөзе, шул түгәрәккә этешеп-төртешеп кергән болытлар. Җелеккә су, салкын үткән көннәрдә кайта-кайта явадыр шикелле алар миңа.

Менә кычыткан күбәләге. Нәрсә калган аңа, бу тынчыган торба юллары өстеннән очмаса! Өф-ф-ф...

Китте. Зәгыйфь канатлары минем сулышымны да күтәрерлек түгел икән. Ә, юк. Тагын килгән. Өф-ф-ф... Менә юләр! Әйдә, аскарак төш! Минем битемә кунарсың. Йә инде, алайса кит. Өф-ф-ф...

Кара син бу болытны! Нәкъ минем баш түбәмә кунаклады да китми тора. Әллә җил үзгәрде микән? Яңгыр яумаса гына ярар иде. Алай дисәң, инде ничә атна тәнгә су заты тигәне юк. Якында гына Казансу да бит...

Кеше күрмәгәндә, төнлә чыгып, юынып, чистарынып кайтырга кирәк булыр. Торба чокырына тулган сулар, җәйгә чыккач, тынчый башлады. Эчәргә дә авыр, укшыта. Миндәй сукбайлар укшымый ничек чыдый диген син?!

Кешеләр дигәннән, аларның да төрлесе бар. Минем янда — үзем кебек җыен әтрәк-әләм. Кемгә эчәргә иптәш кирәк, кемгә — кунар урын, кемгә... ә, юк, ир кирәк булса, шулай дип әйткәне табылыр иде. Аларның ризыгын капканда, сәләмәләрен сорап алганда, күңелдә тагын ниндидер бер кыл өзелә шикелле.

И болытлар!.. Аңлыймыни соң алар менә бу иске-москыга төренгән карт йолкышның тәнендә кем җаны яшәгәнлекне! Һм... Элек дус булып йөргән берәү, үз исемен куеп, Гөлҗиһанга атап язган шигырьне бастырган. Үлгәндер дип уйлагандыр инде. Ә Гөлҗиһан?

Ул көн дә, мин өскә чыгып, иртәнге чәйне җылытканда, урамнан җыеп кайткан гәҗит кисәкләрен караштырганда, үзенең алсу-саргылт чәчәкле җиңел күлмәгендә эшкә бара. Яхшырак урынга да күчәргә була иде югыйсә. Аның юлы яткан торба өстеннән китәсе килми шул. Ул якын килми генә ташлап калдырган киемнәр тактала́р өстендә кагылмаган килеш тора. Инде ул кәчтүм-пинжәкләр өстемдә таякта кебек утырадыр.

Гөлҗиһан да картайган. Кечерәеп калган битен җыерчыклар баскан. Гәүдәсе соңгы айларда күзгә күренеп калынайды. Алпан-тилпән өенә кайткан йорт казы шикелле генә атлый.

Кем булып эшли икән? Һаман да шул нәшриятка таба бара үзе. Транспорт-фәләнгә дә утырмый.

Ә бит юктан гына үзгәрде барсы да, юктан гына... Башка вакытта җай тапмас кебек, Гөлҗиһанны Кучмә театр төбендә калдырып китмәсәм соң? Әллә моңсу, әллә серле елмаеп, нәрсәдер әйтте шикелле.

Галия ачык калдырган ишектән менә шушы болытлар сурәте төшкән зәңгәр күлмәгендә килеп кергән иде Гөлҗиһан. Кайсысының нинди хәлдә фәхеш исе сеңгән ярым черек йорттан чыгып киткәнен аңларлык та булмады. Гөлҗиһанның алсу йөзе күксел болытлар каплагандай төссезләнеп калганы, кулындагы ридикюленең шапылдап идәнгә төшкәне генә хәтердә.

Инде хәзер хатын дип әйтергә дә тел бармый үзен. Кем белән дә булса тора микән? Юктыр, торса, бу киемнәрне сакламаган булыр иде. Әллә... ир тапкач, алардан арынуымы? Җанны борчып тормасыннар әле күз каршында, ераккарак илтеп ыргытырга кирәк.

Кит әле, тычкан! Эчемне пошырып, син дә гел аяк астында чуаласың. Авызга кабарга валчык ризык юк чагында. Фуйт! Фуйт! Фуйт!

Әле менә болытларны әйтәм. Синнән дә катырак яратмыйм бит мин аларны. Кышын болай да караңгы дөньямны тагын да томалыйлар. Җәен... үткәнне искә төшереп, җанга тияләр. Гөлҗиһанның күлмәге дә бүгенге күк йөзе шикелле иде шул. Ә хәзер әнә күбрәк саргылттан киенә.

Бер булмаганны язалар да инде гәҗитләргә. Гөлҗиһан, шуңа төреп, бераз кабымлык та калдырган. Үзем турында укып шаккаттым. Утыз ел торба астында, дигәннәр. Ә бит миңа әле дә нибары утыз алты! Гөлҗиһанга да утыз ике тулгандыр инде. Соңгы тапкыр туган көнендә нинди шигырь укыган идем соң үзенә?

Син уйларсың...

Юк ла... Әйе, әйе, шулай.

Син уйларсың: шагыйрь шундый яраткан!
Үзенә тиң гөлчәчәкне ул тапкан.
Үпсә, таҗларын коярмы санаган —
Нигә дип керфекләрен чәчкә япкан?

Шаккатырлык та булмаган шул юлларга балалар кебек сөенешеп ятканнары! Гөлҗиһаны җавап та язып маташкан булды әле:

Китәм, дисәм, син тотып кал кулларымнан...

Ә бит китте. Кулыннан түгел, итәгеннән тотып калып булмаслык итеп китте.

Аптыратты кычыткан күбәләге дә. Хәерсез, килә дә җитә, килә дә җитә. Өф-ф-ф... Фуйт! Фуйт!

Күбәләкләр ишетә микән? Булмас. Ишетсә, сөйләшер идек рәхәтләнеп. Шушы каурый болытларны сүгәр идек.

Канатларыңны авырайтып, җебетеп, горур башны да иеп, яңгыр коя бит алар сиңа, күбәләккәем! Минем дә шулардан да яратмаганрак һичнәрсәм юк! Кайчандыр, исемнәрен кушып, никадәр шигырь язылган югыйсә.

Тәрәзәдән кергән болыт
Каударланып
Нидер эзләп йөри
Йокы бүлмәсендә...

Шәп әйтелгәнме? Шәп! Ирен эзләп, сөяркәсе ишеген каккан хатын шикелле бит ул болыт! Күпне күргән-белгән Мәчтүрәтти белән бер...

Кочагымда — кадерле яр.
Күкрәгенә
Юрган яптым,
Начар күзләр күрмәсенгә.

Китсәң кит, төшсәң төш, болыт! Әллә җил бөтенләй туктады инде?! Торасың шунда эч пошырып һаман баш очымда. Гөлҗиһанның кибәргә элгән күлмәге шикелле...

Әле шул гәҗитләре дә... Ну язып та күрсәтәләр инде, мин сиңайтим! Утыз ел шакшы су эчендә, имеш. Яшәрсең монда утыз ел! Төш, бер сәгать торып кара. Җылы торба өстендә утыз түгел, ун ел уздырып та илле яшьлек карт кыяфәтенә керде. Әле ярый торбасы нәкъ Казан уртасында. Кеше күзеннән дә читтәрәк, үтеп-сүтеп йөрүчеләр, ризык ыргытучылар да юк түгел. Төзелмәгән йортка сузылган су юллары булгач, бик үк сасы ис тә аңкымый.

Гөлҗиһаннан... яңгырдан соң гына була торган саф исләр килә иде. Болыт исе... Ярата иде бит ул чакта болытны үзе дә, ярата иде! Үзгәнә үткәч кенә күралмас булды.

Тәрәзәдән чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма? —

дигәнме әле Хәсән Туфан? Ничек әйтүендәмени хикмәт? Җандагыңны аңларлык, шуны әйтерлек болыты булмагач!

Менә мин дә Гөлҗиһанымны бик сагынам. Ә бит бар иде, тырышлыгыңнан, чисталыгыңнан туйдым, дип әйткән чаклар да бар иде. Ачудандырмы? Тәртип белән яшәсәң, илһам килми, шигырь язылмый, имеш. Яз син хәзер әнә күзеңне умырып яшәгән болыт турында! Анда булса кайгың!

Һм... горур башны да ия тормыш. Күккә ашып, болыт кебек яшәр җан идем. Инде шул болытларны да яратмыйм.

Синең көлмәгеңә, синең күзләреңә охшаган өчен дә яратмыйм мин аларны, Гөлҗиһан! Саф, чиста булганнары өчен яратмыйм. Сине исемә төшергәннәре өчен яратмыйм.

Язалар да инде бу гәҗитләр. Хатын-кызлар клубында бәхәс киткән икән. Кем дә кем әлеге сукбайны, ягъни мине, үзенә алып кайтып, чистартып, ире ясый, шуңа клубның спонсорлары яңа фатир, машина бүләк итәчәк. Араларыннан икәү табылган да инде. Хәзер психологлар янына йөриләр, имеш. Сукбайны яңа тормышка кайтарту ысулларын өйрәнәләр. Йөрәген, хәтерен саклап, эш табып… башкарасылар, ди.

Болытларны яратырга, үпкәмне онытырга гына ярдәм итегез миңа! Башка һични дә кирәкми. Яратмыйм мин аларны. Төн дә, көн дә баш очымнан, торба тишегеннән караганнары өчен яратмыйм! Дөньяда яшәүнең күңелле икәнлеген исемә төшергәннәре өчен яратмыйм.

Салкын сулар сибеп, хыянәт хисен уятканнары өчен яратмыйм. Җилфер-җилфер кояшта кипкән Гөлҗиһан күлмәге ич алар! Кояшта кипкән Гөлҗиһан күзләре...

Күзләреңә карап кичерү сорыйм, Гөлҗиһа-а-ан... Күзләреңнең зәңгәрен качырма, алмаларын соргылт болыттай усал төсләргә каплама, Гөлҗиһан!

...Ну язып та күрсәтәләр инде бу гәҗитләр! «Утыз ел буе торба тишегендә яшәгән бер ир-атны йортына алып кайткан ханым юындырып, кырындырып куйган икән дә, үз ире булып чыккан, имеш». Ә кайсы төше ялган соң аның?! Елларын исәпләмәгәндә, һе...

«Хәбәрсез югалган шагыйрь табылган» дигәнме? Гаҗәп! Әллә бу торба тишегендә гел шагыйрьләр генә яши микән?!

Болытларны күралмас хәлгә килгәнме? Нишләп алай булсын? Ну алдыйлар да инде бу гәҗитләр! Яратам бит мин сезне, болытлар! Я-ра-там! Гөлҗиһаныма, аның мең серле күзләренә охшаган өчен. Миңа ничәмә-ничә еллар кеше икәнлегемне оныттырмаган өчен дә! Якты дөньяга ачык калдырылган тәрәзәм бит сез, болытлар!

Минем җаныма болытлардан да якынрак ни булса да бар микән — белмим...

*1999*

## Сорый белсәң, Айдан сора

— Сорый белсәң генә — теләк, сорый белмәсәң — имгәк икән шул, — дип дәвам итте сүзен Сабира. — Исеңдәдер, кичке уеннардан кайтып, капка төбендә ял итеп утырганда, минем сиңа, их, кызый, авылдан гына чыгып китәргә иде... ничектер кәгазь юнәтеп... аннан соң, гомерем поезд тәгәрмәчендә үтсә дә, үкенмәс идем, дип әйткәләгән булды.

Казанга килеп төпләнгәнче, ничә ел поезд тәгәрмәчләре өстендә йокладым. Өч тәүлек эшлим, өч тәүлек ял итәм. Кергән фатирымның да поезд купесыннан артык җире юк. Калхуз базарыннан ерак түгел бер йортта — Нариман урамында. Янәшә бүлмәдә әле бер, әле икенче үзбәк туктала. Алардан хуҗабикәгә акча мул тама. Сатулары начар булганда да уфтанмыйлар. Мондый якын җирдән икенче бер фатир табасыңмы әле, юкмы... Чәй өстәлен җимештән өзмиләр, кагыннан, яшелчәсеннән...

Юлда йөреп талчыкканнан соң, үз бүлмәңдә тынычлап ял итәргә планнар корасың — кая ул! Әллә кайлардан җыелган үзбәкләр йортыбызда төне буе пылау пешерәләр, тел асларына тәмәке салып, шуннан күзләре тонып, вакыты белән тамак та чылатып, гәпләшеп, кәеф-сафа корып утыралар.

Юка такталар белән генә әмәлләп ясалган янәшә бүлмәдә кеше барлыгына исләре дә китми. Хәер, мине дә үзләре янына кыстыйлар. Марҗалар кебек алларыннан төшми утырмавыма, базарчы хатыннардай әрсезләнеп, сүзләренә катнашмавыма гаҗәпләнәләр. Беләбез без синең кебек тәртипле проводницаларны, дип, борын астыннан гына елмаялар.

Кайберләре, утызда да кыз түгелсеңдер инде, дип турыдан- туры әйтергә дә кыенсынмыйлар. Җитмәсә, үземне артык тыйнак тотуым, яше булса да, ир-аттан тәмам баш тартмаган хуҗабикәмә дә ошамый. Җае чыккан саен, бүлмәмне башкалар да соравы, артыграк бәя бирүләре турында сүз башлый.

Төн урталарында ишегалдына чыгып басам. Анда да шул ук пылаучы үзбәкләрдән килә торган суган, май исе. Җил безгә карап искәндә, базарның тынчу һавасы тар, җимерек ишегалдына төеп тутырылгандай була. Айдан сүз читкә чыкмаганга, аның белән киңәш-табыш иткәндәй, сөйләшергә гадәтләнеп киттем.

— И-и-и, — дим. — Безнең авылдан Казанга килгәч, син дә ябыгып киткәндәй булдың. Төсең дә тонык, үзең дә боек... Менә син мине юлларда озатып йөрисең. Күңелең утырмыймы? Минем кебек торыр җирең юкмы? Күктәгеләргә җиткер, әгәр кереп йөрергә ишеге булса, тәрәзәсез бер почмакта да көн итәр идем. Тик үз куышымны гына насыйп ит. Сине сагынсам, ишегалдына чыгып та карармын...

Шулай үзалдыма сөйләшүемне читтән генә бер абзый карап торган икән. Яныма килде дә:

— Бик бетеренмә әле, сеңлем, менә мин — шушы йортларның хуҗасы, участокка кил, урам себерүче итеп булса да алырмын, ничек тә торыр урын әмәлләрбез. Кайда эшлисең соң үзең? — дип сорау бирде.

— Кеше артын җыештыручы инде...

Ямьсез генә җавап бирсәм дә, абзый, хәлемне аңлагангамы, бер дә ачуланмады:

— Башыңа төшсә, сеңлем, башмакчы булырсың, аның монысы да шул ук артны җыештырудан артык түгел инде, — диде.

Яңа эшне авырга санамасам да, рәхәтлеген дә тапмадым. Әле беләктә көч бетмәгән. Тик менә син яңа гына ялт иттереп куйган юлларга кемнеңдер төкеренүен, шакшы ыргытуын күрү җанны тырный. Мин җыйдым аны, синең иртәңне матурлау өчен җыйдым, дип кычкырасыңмыни — түзәсең. Синең эшне — эшкә, үзеңне кешегә санамаулары кимсетә. Җитмәсә, авылдашларым минем бу мескенлекне күрмәсә ярар иде, дип, кояш чыкканчы ук, көрәк-себеркеңне күтәреп, Чернышевский урамына чабасың. Кытыршы урамнарны себереп хәл бетә, көч кими. Хәер, алар хәзер үзгәрделәр, исемнәре дә башка. Сабира себергән урам иң элек — Ленинныкына, аннан Кремльнекенә алмаштырылды.

Сабира, тыңлыйсыңмы-юкмы дигәндәй, туктап карап торганнан соң, тагын сүзен дәвам итәргә булды:

— Ул урамнар элек тә якты иде, сукбайлар да күренми диярлек. Икедән-өчтән торып чык. Әле минем иптәшкә Аем да бар бит. Үзем эшлим, үзем һаман шуның белән сөйләшәм:

— И-и-и, Ай, тәки куышлы иттең бит син мине, — дим. — Алай булдыра алгач, бүлмәнең юньлерәген бирсәң соң! Ни тәрәзәсе, ни өстәл куярлык урыны... Йоклый торган почмак шунда. Караватка да яным белән узам. Күршеләрнекенә терәп салынган ишек төбендәге мичкә утын ыргытыйм дип бөгелсәм, арт ягым белән иске су чиләген аударам. Кеше гырлавыннан, кычкырышуыннан төнлә йокы күргән юк. Киров урамында гына да никадәр подвал бар, шуларның тәрәзәсе яныннан узганда да, кызыгудан йөрәгем сикерә. Гөлфинур, ул җир асты йортларын син дә беләсеңдер, Сез хәзер яшәгән Нариман урамындагыларның да барысы шундый иде...

Мин, э-э-э-е дигәнне аңлатып, баш селким.

— Алла бер бирсә, бирә икән. Озак та үтмәде, күптән кызыгып карап йөргән йортыма күчерделәр. Чиркәү каршында гына. Хәзерге Бауман урамының бу башындарак. Бер саргылтым бина. Капка турыннан кыеклабрак югары күтәреләсең, сукмагы Кремльгә алып чыга. — Сабираның әлеге сүзләрен тыңлаганда, капылт итеп, аңарга кунакка килгәч, дөбер-шатыр узган троллейбусларда авылдашлар да бардыр шикелле, тәрәзәдән карап торганым искә төште.

Шул чакта бер кызык хәл булган иде. Күрше кызы, төн уртасында уянып, барыбыз өчен дә уртак аш-су бүлмәсенә чыккан. Тәрәзәгә яңгыр сибәләгәнне ишетеп, шуның саф исе керсен диптер инде, җилләткечен ачып куйган да яңагына килеп терәлгән. Күкрәкләре арасына шаулап тулган яңгырның ни өчен җылы икәнлеге кызга бераздан гына барып җиткән: берәү ут яктысы төшмәгән өй янына пес итәргә тукталган да тәрәзәгә яңгыр яудыра икән.

— Подвал бөтен сәламәтлегемне суырды да инде, — дип дәвам итте сүзен Сабира. — Үпкәм кабарды, аякларым шешенде. Урам себерерлек хәл калмаган иде. Үзем һаман чыгам да Айга карыйм, Ай белән сөйләшәм:

— И-и-и, Ай, — дим. — Биргәч биргәч, шушы тәрәзне туфрак өсләрендә дә итә ала идең бит син. Тере килеш гомерем буе кабердә яшәрмен микәнни?

Ай дәшми. Караган да каткан. Ул, мин кереп киткәнче, урыныннан да кузгала алмас кебек. Балыкчы хатыныннан ким булмады бу, һич ярамассың, ди торгандыр инде.

Кабердә яшәү дә гомер буена язмаган икән. Бераздан Кремль урамының 36 нчы йортына күчерделәр. Эшне дә җиңелрәккә алмаштырдылар. Хуҗа да яратып, якын итеп өлгерде. Ялгыз булсам да, яңа фатир чиратына бастырды. Тегесе аның вакытлы иде бит. Эшләгәндә генә тора аласың.

Әле шул вакыт яшәгән җирләремне карап уздым. Йортны сүткәннәр. Кечкенә генә, матур гына бакча ясаганнар. Бауман урамының башы ул хәзер, дим бит. Эх, минәйтәм, шушындагы тормыш сагындыра. Бөтенебез бер гаилә булып яшәгәнбез. Үзе — үзәк урам, кибете-базары якында гына. Нәрсә җитми бу кешегә? Җимерелер, салкын суының да юньләп булганы юк дигәнмендер. Шулай уфтанып, сөйләнгәләп торганда, күрше карты әйтә куйган иде:

— Кызым, соравын гел сорыйсың, хәерлесен генә теләмисең. Сорый белсәң — теләк, белмәсәң — имгәк ул.

— Мин тәрәзәсез фатирым, подвалдагы өем һәм башка бик күп нәрсәләр турында уйландым. Барысын да сорап алганым исемә төшеп көлгәндәй иттем, әмма бабайның хәерлесе дип әйткәненә колак салмаганмын, шунысы хакында уйланмаганмын...

Шушы сөйләшүдән соң берничә көн узгач, Сабираның яңа микрорайоннарның берсеннән алган фатирына өйдәш булып кергән ир кулыннан вафаты хакында хәбәр килеп ишетелде. Шул җанны тузгытып җибәрде. Әле яңа гына сөенеп өй туена чакырган ахирием, аның әйткән соңгы сүзләре исемә төште.

Кыенсынып, кечкенәгә дә канәгать булыр сыман, Алладан зурын өмет итмәгән һәм гомер сикәлтәләрен арттырганнан-арттыра гына барган Сабирага, инде юньлеләнгән тормышына сөенеп, Ходайга дога кылырга кирәк булгандыр. Ай аңа әнә өй янына өйдәш тә бүләк иткән...

Сабираның соңгы «хәерсез» теләге мине хушсыз калдырды. Ул, сорагач-сорагач, үзенә ирнең шәфкатьлерәген сорамавына үкенүен әйтеп өлгергән иде шул...

*2000*

## Сары шарф

— Озын булса, кисәрсең, — диде Әнис, кулындагы төргәген миңа сузып. Әле буяу исләре дә таралып бетмәгән газета эчендә ни яткандыр — беләсем килсә дә сорамадым, төргәкне дә алырга ашыкмадым.

— Җылы түгел дисәң, муеныңа урарсың, башлык белән киярсең, — диде ул, кабат сүз башлап.

Әкрен-әкрен генә сүтелгән төргәктән күз явын алырдай җете сары шарф килеп чыкты да идәнгә шуып төште.

Бәйрәмнәргә ерак булса да, шарфның бүләк икәнлеге аңлашылган иде.

— Минем төсем итеп ябарсыңмы, сакларсыңмы — үзең кара...

Әнис, шарфны алып, миңа сузды.

Һе... сары шарф ничек инде аның төсе була алсын?! Ул аның яшел күзләрен дә, соргылт чәчләрен дә хәтерләтми. Алай дисәң, өстендә — һәрвакыт сары күлмәк...

— Төсен ошатмасаң,ташласаң да була...

Ошатмасаң, дип... Ә нишләп әле ошатмаска?!

Шарфны капыл гына эләктердем дә җилкәмә салдым.

— Идәнгә кадәр икән шул... — дип куйды Әнис.

Булса ни! Муенымны өч кат ураганнан соң, шарфның очлары, тәнемне иркәләп, күкрәк өстенә килеп ятты. Каршыма баскан көзгә аның миңа бик тә килешкәнен әйтеп тора иде.

— Килешә... Килешмәскә! Күбәләк кебек кенә әйләнеп-бөтерелеп, Әниснең кочагына килеп кердем.

— Апама дип алган идем, инде синнән дә кадерлерәк кешем юк, — диде ул,еш-еш сулап. — Кис, ташла, оныт, әмма мин, шушы шарф шикелле, синеке генә!

Шарфны кисәргә була ул... Шарфны ташларга була...

Әнис китте. Мин аңа рәхмәт әйттемме, хәтерләмим.

Икенче көнне инде шарф, чыннан да, минеке иде. Дус кызым да аны бик матур дип тапты:

— О-о-о!.. Яратуы да шушы шарф кебек озын булса... Ничек түзәрсең?..

Сәер сүзләр иде. Ярату озын буламыни, озын гомерле була, дип уйладым. Ничек түзәрсең...

— Өстеңдә тузсын, — дип өстәде Рафика.

Еллар узды. Шарф кына тузмады да тузмады. Юган саен ачыла баруында иде. Һаман да яз кебек йомшак, җәй кебек җылы, көз кебек җете...

Шарфны тагын да ача төшсен дип, кап-кара пәлтә сатып алдым. Аңа төс бүрек кияргә гадәтләндем. Бөтен киемнәрем шарфка ярашты. Пәлтәләр, бүрекләр, перчаткалар, төсләрен үзгәртми генә, гел дә алмашынуда иде. Инде иремә әйләнгән Әнис тә аның тузмавы-сыпылмавына сәерсенә башлады. Биргән башка бүләкләренең дә һич кенә дә искермәвен шәйли иде микән — белмәдем. Әмма үзем башка әйберләргә үзгәртеп тә түздыра алмаган ул кием-салымнарны сандык төбенә салып куярга гадәтләндем. Алтын йөгертелгән сәгать белән сары шарф кына туйдырмады мине.

— Сал инде, ул сиңа моңсу төс бирә, — диләр иде яңа танышларым.

— Син кичерер кайгыларның сәбәбе шушы шарфта булыр, — диде көтмәгәндә ирем белән бергә эшләүче ханым.

— Ул синең яратуың кебек ап-ачык, — дип кабатларга күнекте дус кызым.

Ә Әнис, киенгәндә, шарфымны муеныма урый-урый:

— Бу шарф миңа яшьлегемне исемә төшерә, — дип әйткәли торган булды.

Шарф тузмады да тузмады. Шарф эчендә, Әнис кочагында яшәү җылы, рәхәт иде...

Баш очыбызда күптәннән козгын кебек бөтерелгән гайбәтләр яңгырдай җанга яуган бер көндә, көтмәгәндә-уйламаганда, тәнемне калтыравык алды. Хәлсезләнеп, исәрләнеп, атылып-бәрелеп, өйгә кайтып кердем. Шыксызланып калган бүлмәбез уртасында, җәй киткәнне көтми килгән көзгә охшаш сарылы-яшелле күлмәгемне кигән килеш, нәрсәгә барып тотынырга белмичә әйләнгәләп тордым да гөрселдәп идәнгә килеп төштем. Үпкә сүзләремне җиткерергә, аңлашырга янымда Әнис тә, борынымны борынына төртеп мышкылдарга бер-бер песи баласы да юк, кулымдагы Әнис биргән сәгать кенә ансыз узачак көннәремне саный башлаган иде...

Сары шарф, сары сәгать, сагышлы истәлекләрдән торган ялгыз дөньямда мин беркемне кирәксенмәдем.

— Оныт инде, сал шул сары шарфыңны, — дип әйтә иде танышларым, теләкләрсез яшәвемне аңларга теләмичә.

— Ул — Әнис кебек, көз кебек сары, вакытлы алдавыч, аның җылысы да үзеңнеке бит! — дип куйды бервакыт дус кызым.

— Кем сөйгәненә сары бүләк ала инде... — дип тәкрарлады Әниснең эшендәге ханым.

Янда, сөйләшәм дисәң, кызым бар, ә җанда эчпошыргыч тынычлык иде. Шушы тынлыкны хезмәттәшемнең Яңа ел бүләге бозды.

Мин теләгән, мин көткән затлы сәгать беләгемә бик килешле килеп кунды да гомеремне башкача — тек-тек кенә санап та китте. Миңа аның адымнары артык кызу, теле артык ашыгып атлый кебек тоелды. Һәм шунда заяга, ялгызым узып барган елларымның бөтен фаҗигасен аңладым. Иске сәгатькә аның янәшәсендә урын калмаган иде...

Ишектән кергәндә үк, кызымның:

— Әнием, курчакларымның киеме тузган, тегим әле, чүпрәк бирче, — дигәне ишетелде.

Мин, аны бик тә сәерсендереп, муенымнан идәнгә кадәр үрелгән шарфны кызу-кызу гына җыеп, кулына китереп тоттырдым.

— Ул бит әле өр-яңа, — диде кызым, төсе җете шарфны курчакларына кисәргә базмыйча.

— Аның караве — мәңге тузмаячак! Курчакларың имгәнеп, ватылып бетсә дә, тузмаячак! Югач керешә дә белми торган нәрсә ул! Үсми торган, картаймый торган курчакларыңа мәңгелек кием!

Сүзләрдә минем өчен ят усаллык, зәһәр, мыскыл җитәрлек иде. Үзем дә имәнеп киттем.

Оп-озын шарфтан кызым атна буе киемнәр текте. Эшен бетергәч, бөтенесе сап-сарыга әйләнгән курчакларын киштәдәге китаплар алдына утыртып чыкты. Өй дә сап-сары булып калды.

— Әнием, безнең өйгә дә көз килде, име... — Кызымның күзләренә нигәдер яшь бәреп чыкты.

— Юләрем, кыштан соң көз киләмени?! — дидем мин, аны тынычландыру өчен.

Мышык-мышык торган кызым:

— Сары яфрак кебек кунгансыз! — диде дә бөтен курчакларны киштәдән сыпырып ук төшерде. Аннан: — Иске киемнәрендә дә матур минем курчаклар. Синең кебек матур! — дип, муеныма килеп сарылды.

Без аның белән Казан урамнары буйлап йөрергә чыгып киттек. Муен — ачык, җан — ачык. Анда шундый тынычлык, әйтерсең, бөтен узган гомерем сыпырып ташланган. Күктән төшешли үк кунарга урын эзли-эзли яуган карлар шул тынычлыкны тагын да арттыра. Кызым аларга үзенең учларын ачты. Бер кар бөртеге бик озак эремичә ятты. Соңыннан, тамчыга әйләнгәч, кызым аңа иренен тидерде:

— Әнием, кар яшендә тоз тәме юк! — диде ул, сәерсенеп.

Әйе шул. Кар яшендә тоз тәме юк шул.

— Әнием, әнием, карлар саргаймыйлар да!

Әйе, карале, карлар саргаймый да икән...

— Алар каралмый да бит, аларга тузан гына куна!

Һе...

— Кар, тузан кунса, эри дә кача ул, эри дә кача...

Әйе шул. Эри дә кача.

— Менә мин, дәү үскәч, бу карлар төсендә бик күп шарфлар алырмын әле, әнием!

Кар төсендә, ди бит. Кар саргаймый, ди... Гомерем ике шарф белән узар микәнни? Сары шарф... Ак шарф...

Сары шарф... Ак шарф...

Сары шарф... Ак шарф...

*1997*

## Чәчәктә кайткан яз

Без, иптәш кызым белән, язгы суларны чупыр-чупыр китереп, авылларына кайтып киләбез. Инде карлар эреп беткән диярлек. Анда-санда тишелеп чыккан үги ана яфраклары баеп барган кояшка сары чәчәкләрен сузганнар. Язның беренче шытымнарын өзәргә кул бармый. Җанда эчке бер рәхәтлек. Шушы сары чәчәкләр, сап-сары кояш, иптәш кызымның сап-сары кофтасы шул рәхәтлеккә туры килә торган саф төсләр сирпи.

Бу минутларда кем нәрсә уйлый — безнең анда эшебез юк. Шулай да, әзрәк баргач, Рамилә кичен күрше егетен очрата алыр микән, дип, дустым өчен дә борчыла башлыйм. Хәмитләрнең тау башыннан күренеп торган тәрәзәләрендә ут юк. Әгәр әйтсәм, Рамилә көләчәк кенә. Аның казах кызыныкына охшаган кысынкы күзләре авылга алып керүче күперне дә шәйләми булса кирәк. Кызык, юл буеннан баш төрткән әле бик нәни чәчәкләрне күрә микән, минем кебек сөенә микән, дип уйлап куям мин аның турында.

Егетләрне үзеннән өркетмәс өчен, Рамилә бервакытта да күзлек киеп йөрми. Дәрестә дә, язарга кирәк булганда гына, анда да бөтен кеше инде эшкә тотынгач кына, үзенең затлы кысалы күзлеген йомшак кулъяулыгы белән сөрткәләп, борын очына элеп куя. Ул күзлекнең почмагында менә шушы чәчкәләргә охшаган кеп-кечкенә сары тамга бар. Әлеге тамга, күзлекнең чит илнеке булуын күрсәтеп, мәсьәлә чишелгәнче, Рамиләнең борын яфрагы читендә елык-елык итеп утыра.

Юлга җыелган суларның чупыр-чупыр килгәненә Рамиләнең узган елдан калган биек үкчәле туфлиләре чулт-чулт җавап биреп, минем кәефемне тагын да күтәребрәк җибәрәләр. Түбәнгәрәк төшкән саен, клубка чыгасы вакытыбыз бик азга булса да якыная.

Чупыр-чупыр... Чулт-чулт, чупыр-чупыр... Чулт-чулт...

Хәмитләр турыннан үткәндә, Рамиләнең болай да кысынкы күзләре тагын да кечерәебрәк кала, кара күз алмалары үзәккә җыела. Тавышыбызны ишеткән егет тәрәзәдән карамас микән дигән өметләр белән, Рамилә үзе сүз башлый. Минем җавабым юк. Иптәш кызымның өметен җимермәс өчен генә, җирдән берике вак таш алып, чекрәеп торган карасу пыялалы тәрәзәгә ыргытам.

Хәмитнең әнисе, бик тә чибәр китапханәче ханымның шәүләсе, җанга якын бер яктылык сыман, түр аркылы сызылып уза. Без исә күрше йорт капкасына юнәләбез.

Монда Рамиләләр яши. Туган якка кайтмаган елларда мин, аларга барып, бәрәңге чыгарышкан, өй җыештырышкан, авылның бетмәс-төкәнмәс эшләрендә катнашкан булып йөрим.

Көмеш самавыр артында, хәл-әхвәл сораша-сораша, чәй эчәбез. Аннан сүз без көткән якка юнәлеш ала:

— Ни, Данил абый, Рамиләнең чыгасы да килми, мин, тик утырганчы, йөреп кайтыйм булмаса. Клубыгызда күрәсе кешеләр дә барые...

Рамиләнең әтисе, ут сүндереп йөреп кырысланып беткән кеше, тикшеренүчән карашларын миңа төби. Нинди дә булса җөпләү-фәлән ишетмәгәч, мин:

— Эшегез-мазар булса, чыгып тормаска да була инде, — дип дәвам итәм. — Әллә иртә таңнан ябышырбызмы?

Минем хәйләне аңлап бетермәгән Рамилә өстәл астыннан гына бик каты иттереп аягыма китереп баса. Бу, Хәмитне син чакырмасаң, кем чакыра, дигәнне аңлата.

Эш турында сүз башладыңмы, Данил абый җеби дә төшә инде.

Өендә буй җиткереп килгән малае бар. Ә монда минем эшкә җитезлекне әйбәт беләләр...

Данил абыйның:

— Кунак кызы ич син, эш эшләп ятарсың инде, булмаганны, бар, чыгып кер, озак йөри күрмә, — дигәне сүзләремнең аның күңеленә мач килгәнне аңлата.

Миңа шул гына кирәк тә. Эңгердә чупырдатып кайткан суларга да басмыйча гына, йөгерә-сикерә, клубка төшеп җитәм. Белеп торам: Хәмит инде күптән анда һәм мин күренгәнне көтеп утыра. Безнең әле Рамиләнең әти-әнисе яткачы биисе, Казан-Арча яңалыклары белән уртаклашасы бар.

Тик Хәмит, гадәттәгечә, бию кичәсенең ахырына чаклы тормый, нигәдер берни әйтмичә-нитмичә, клубтан чыгып китә. Мине чит бер авылда япа-ялгыз калдырып китә. Әллә үземнең генә кайтмаячагымны белгәнгә, алданрак китәме ул? Алдан сөйләшенгән эш икәнлеген күңелем белән генә сизенәм.

Бу авылның урамнары нәкъ җырдагыча, кәкре дә бөкре. Айлы төннәрдә дә килбәтсез, нурсыз күренә ул миңа. Кырлы-сырлы сукмаклар аша үтеп, үзем кунакка төшкән урамга килеп җитәм. Аның чатында минем аякларым үзеннән-үзе кызулана башлый. Бер шомарагының кунак кызының юлына аркылы төшүен көт тә тор. Мин Нәгыйм абзыйларның ат арбасы куелган өй каршына килеп җиткәндә, ике егет кулымнан эләктереп ала. Икесе дә — иптәш кызымның элек йөргән егетләре. Нишләргә белми, як-ягыма каранам. Су да чупырдаудан туктый.

Сүзне Рифат башлый. Май җиле шикелле йомшак тавышы үзгәргән, өзек-өзек:

— Син... миңа... ошыйсың, Гөлнур. Урам әйләнеп кайтасың килмиме? Мин... сиңа... үзебез яшәгән... өйне дә... күрсәтермен.

— Ник, мишәрләр өйдә яшимени? Ызбада түгелмени? — дим мин аңа, тешләремне ыржайтып.

Багана лампочкасының сүрән яктысында ул моны күрәме-юкмы, аңлашылмый кала, Фәнүс турыдан-туры:

— Кайсыбыз белән йөрисең? — дип яра.

— Менә, икегез белән дә ич, — дим мин, башымны юләрлеккә салып. — Иптәш кызымның егетләрен бер-берсеннән аерып куя алмыйм бит инде.

— Син безнең янда чамалабрак сөйләш. Үткән-беткән, без аны оныттык. Сүз менә синең турыңда бара. Кайсыбыз белән йөрисең? — ди ул тагын да үҗәтләнебрәк.

Мин аяк киеменең очларында бөтерелеп, көлемсерәп торган итенәм дә, кулларыннан ычкынып, Рамиләләр капкасына йөгерәм. Кызганыч, ниндидер шаяны аны бикләп тә куйган икән. Инде кирегә, Арча юлына элдерәм. Сыйрагы минем ике буй кадәрле Фәнүскә мине куып тотар өчен бер-ике адым атлау да җитә, шунлыктан Нигъмәт абзыйның ат арбасына сикереп менәм. Яныма менә-нитә калсалар, тибеп төшермәкче булып, япун самурайлары кыяфәтендә катып калам.

Арбага җигелгән егетләр белән авыл урамнары буйлап очабыз гына. Минем инде башлар әйләнә, күңел болгана. Күз алларым караңгылана. Бераз вакыт үткәннән соң, шаярып арыган егетләр, мыш-мыш килеп:

— Кайсыбызны сайладың? — дип сорыйлар. Минем җавап юк, әмма әйтмәсәң, уеннан уймак чыкмагае, сәяхәт тәмам йончытты. Озын буйлы, чибәр Фәнүс дияр идең — әле мәктәп баласы гына. Рифатны сайлар идең, әнисен усал мишәр хатыны дип сөйләгәннәре күңелгә шом салып тора...

Уңайрак вакытны туры китереп, арбадан сикереп төшәм дә:

— Берегезне дә түгел! — дип, кабат, алны-артны белми, Арчага карап йөгерергә тотынам.

— Тукта! — Фәнүснең боерулы тавышын ишетүгә, сөрлеккән аякларым миңа хыянәт итә. Инде кеп-кечкенә бармакларым да аның тирле куллары эчендә.

— Минем егетем бар шул, — дим мин, абынган җиремнән тора-тора.

— Не пройдет! — ди Фәнүс, теш арасыннан гына сыгып.

Соңгы өметем — Рифатта. Ул, башын кыңгыр салып, уйга батып тора да:

— Гөлнур, рәнҗемә миңа, бәлки... мин... китеп... ялгыш та эшли торганмындыр... Әмма үзем яраткан бу кулларыңны авырттырасым килми, — ди.

Ул китә. Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Рифатның ботинкасы да иске микәнни соң? Без тавыш-тынсыз Рамиләләргә таба борылабыз.

— Фәнүс, — дим мин бикле капка янында, — Фәнүс, кертеп җибәр мине.

— Шуның өчен бикләп куйдыммыни мин ул капканы?!

— Фәнү-ү-үс...

— Таң аткач!

— Минем... эчләрем дә... кысылып бетте инде.

— Читкәрәк китеп торам...

— Тамак та ачты, йокы да килә, Данил абыйдан да куркам, дәрес тә хәзерлисе бар, сине яратмыйм да... — дип тезәм мин бер-бер артлы.

Ул, теш араларына кыстырган үги ана чәчәген әйләндереп, берни дәшми басып тора.

— Фәнү-ү-с...

— Таң аткач!

Сүз беткән. Таң атмый да атмый... Керергә ымсынуым гына була, Фәнүс узган ел кызлар өчен сугышып сындырган тешләрен шыгырдатып ала, йөрәгем жу итеп аяк астына төшеп китә...

Инде:

— Фәнүс, үбә күрмә, — дим мин аңа.

— ...

— Теш казналарың сынып ук чыгар да... авыз эчемә коелыр шикелле.

Үземә дә бик җитди күренгән сүземне Фәнүс кызыкка ала булса кирәк:

— Ачуымны китерсәң, тешлим дә әле мин.

Без, җиңелчә генә төшкәли башлаган яңгырдан качып, капка түбәсе астына керәбез.

Фәнүс туңа. Инде минем дә тешләрем шыкылдый башлый. Фәнүс мине сак кына тезләренә утырта:

— Атта йөреп арып беткәнсең син, кызый.

— Ие, Фәнүс, теләсәм, өйгә дә кереп китә ала идем лә мин. — Каян килә миңа бу мактанчыклык?!

Фәнүснең иягендәге бала мыек йоннары шундук кабарынып китә:

— Минем капкыннан ычкынган тычкан юк әле. И булмас та!

— Әйдә, алайса бәхәсләшик. Җиңелсәң, син башка бервакытта да минем яныма килмисең.

— Ә нигә? Була ул! Җиңә калсам, кызый... Мин сине өебезгә алып кайтып утыртам! — ди Фәнүс, мин көтмәгәнчә сөенеп.

Мин Фәнүснең маңгай чәчләре белән уйнап утырам... Үзе кебек тискәре туры тотамнар кашлары өстенә ишелә дә төшә, ишелә дә төшә.

— Фәнүс, чишмә буенда сары чәчәкләр бар инде...

— ...

— Кичә без елга суы эчмәдек, әнә шул ерак чишмәгә бардык.

— Кичә син безнең авылга төшмәдең дә түгелме соң?

— Фәнүс...

— Әү инде, Гөлнур, әү. Ни әйтмәкче тагын? Мин бит нәкъ менә шул чишмә тавышын тыңлап утырам.

— Без аңа, такталар салып, юл ясап кайттык.

— Чынлапмы? Әйдә, алайса!

Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Чупыр-чупыр... чулт-чулт.

— Фәнүс, синең дә ботинкаң тишекмени соң?

— Әйе, безнең авылда бөтен кешенең наские тишек, — дип көлә Фәнүс, минем ни әйткәнне аңламыйча.

Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Чупыр-чупыр, ди язгы сулар. Чулт-чулт, ди Фәнүснең кара ботинкасы. Челтер-челтер, ди чишмә.

— Куа-куа, — дип кушыла бака балалары.

Кинәт кенә, куа-куа, дип, кеп-кечкенә бака баласы минем аяк арасына сикерә. Көчле ай яктысында ул миңа бик тә, бик тә куркыныч булып күренгәнгәме, мин, үзем дә белештермәстән, кирегә — суның аръягына, Рамиләләр турына йөгерәм. Меңләгән вак-вак бакачыклар, ямь-яшел авызларын сузып, минем артымнан куа килә кебек.

— Чупыр-чупыр, чулт-чулт, куа-куа...

Колагымда яңгыраган шушы тавышлар астында мин, Фәнүс белән бергәләп, койманың икенче ягына сикерәм. Ярый әле койма җимерелмәде, дим эчемнән.

— Ну, кызый, чапсаң чабасың икән, билләһи, кача яздың бит.

Фәнүс минем җитезлекнең сәбәпләрен аңламаган булып чыкты. Тирләгән маңгаемны аның күкрәгенә терим. Шул хәлдә Фәнүсне баскыч кыегы астына этәм.

...Кичтән алынмый калган галушларга түбәдән су тама. Чупыр-чупыр, чулт-чулт... Фәнүс үрелеп кенә аларны иреннәренә җыя да минем плащның ачылыбрак торган изүенә тамыза. Салкын су миңа рәхәтлек бирми.Күлмәкләремне юешләндереп, чиркандырып, тәнемә үтә. Мин, кирәкле вакытны көткән кәҗә бәтие шикелле, өйалды диварына сөяләм. Соңгы тамчы суның тамуы була, кулларым, аякларым дерелдәп башлый да гөрселдәп җиргә авам.

— Гөлнур, — ди Фәнүснең калтыравыклы тавышы, — ни булды?

Минем зур булып ачылган күзләрем яңа туган айга карап хәрәкәтсез кала бирә. Фәнүс, көчле куллары белән күтәреп алып, мине диварга сөягәндә дә бер генә керфегем дә селкенми. Мин тагын, гөрселдәп, баскычның каты такталарына егылам.

Күтәрә-егыла, күтәрә-егыла торгач, икебез дә суга чыланып, аяк киеменең сазына буялып бетәбез. Фәнүс тезләнгән хәлдә миңа ялвара:

— Гөлнур, үлмә... Гөлнур, үлмә генә...

Шашынып кыңгырауга басуына — өйдән Хәмит белән Рамилә атылып чыга:

— Тс-с-с... Әтине уятасыз инде!

— Үлә бит, алып кереп китегез, — ди Фәнүс.

Рамилә белән Хәмит, ике култыгымнан тотып, мине өй ишегенә таба сөйриләр. Инде ишек ябылып маташканда, түзмим, кычкырып көлеп җибәрәм.

Арттан Фәнүснең:

— Гөлнур, кире чык! — дип җикергәне генә мине айнытып җибәрә. — Миннән... көлеп... мине... тезләндертеп!

Туктаусыз яңгыраган кыңгырау тавышына Данил абый уянмагае дип куркып, мин кире чыгарга мәҗбүр булам. Йөземне тагын да ныграк агартам да, аякларымны чак кына сөйрәгәндәй итеп, Фәнүскә таба атлыйм, хәлсезләнеп өстәл кырыена авышам.

— Син мине алдадыңмы? — ди миңа Фәнүс ерактан гына, үпкә белән. — Син мине алдадыңмы?

— Юк ла, Рамилә көлүе иде ич ул.

Өйалды ишеге ябыла. Фәнүснең аяк тавышлары югала. Чупыр-чупыр... чулт-чулт. Чупыр-чупыр... чулт-чулт.

* * *

1989 елның маенда поезд мине Арча вокзалының перронына төшереп калдыра. Үзебезнең якка илтүче икенче берсен көткәндә мин, гадәттәгечә, җентекләп тирә-якны күзәтәм. Быел яз соңга калды, ахры, дип уйлыйм эчемнән. Кай елларны кып-кыска буйлы сары чәчәкләр инде апрель азагында ук кояш җылыткан урыннарда баш суза торганнар ие... Тимер юл кырлачларында да алар никтер күренми. Вокзалга якын-тирәдәге шпаллар майланып, пычранып беткән. Кояшка яны белән утырган берьяклы гына урам каршысында каз бәбкәләре чемченә. Ерактан миңа алар үзләре кебек үк йомшак сары чәчкәләрне эзләп йөри шикелле...

Шундый уйлар белән хыялланып басып торганда, күзләрем озын гына буйлы чип-чибәр бер ир-егеткә төште. Туктале, кем соң бу, минәйтәм, кайда күргәнем бар?

Ул да мине искәргән булса кирәк. Уйламаганда-нитмәгәндә яныма ук килде дә әллә нинди тирәннән килгән үзәк өзгеч тавыш белән:

— Ничә еллар газаплаган бер сорауга җавап бир әле, Гөлнур, — диде. — Рамиләләрдә син аңыңны югалтып егылган идеңме, әллә миннән көлдең генәме?

Фәнүс... Фәнүс! Фәнүс! Ничек итеп үзебезнең бәхәсне исенә төшерергә аның? Инде ничә еллар үткәч, ни мәгънә?! Шул вакыйга аркасында без кабат очрашмадык түгелме соң?

Аннан... Авылның үзен артыгы белән яраткан һәм, бәлки, чыннан да, бер дигән егетен шул җиңүем белән нигә кимсетергә?

Инде тимер юл читендә ялгызы гына моңаеп утырган бер сары чәчәккә дә тап булгач, күңелем тәмам йомшады... Тавышымдагы калтыравыкны басарга тырышып:

— Юк, мин авырган идем, борчылма, — дидем.

— Эһ, әгәр белгән булсам...

Нәрсәне әйтеп бетермәде — аңламадым. Бәхәстә җиңелүен танып, ул мине «онытырга» уйлаганмы, «тәкәббер» дигән нәтиҗәгә килгәнме, әллә чирле булуымнан курыкканмы, — сорарга батырчылык итмәдем.

— Ә Рифат? — диде ул миңа аннан. — Нигә син Рифат белән калмадың?

* * *

Мине башкалар белән калдырып китәргә мәҗбүр булган Рифатны шул елны май ахырында, инде җирләр кипкәч, болынлыктагы чишмә буенда очраттым. Укулар беткән, алда имтиханнар тора, безнең бераз шаярышып, ял итеп аласы килгән чак. Түгәрәкләнеп туплы уйныйбыз.

Рифат та безнең янга төшәр дип һич уйламаган идем. Аның, каршы ягыма басып, күзләремә гел сөеп карап торуына үпкәсе ташыган Рамилә, барыбызны аптыраашта калдырып, куллардан ычкынып, еракка тәгәрәгән тупны эләктерде дә өенә кайтып китте.

Кич иде. Соң иде. Шушы хәлне генә көткән кебек, барысы да таралыштылар. Аларга кунакка дип төшкән булсам да, хәтере калган Рамилә артыннан барасы килмәгәнлектән, юлда кара төн куып җитәренә карамыйча, Арчага менеп киттем.

Тау башына күтәрелгәндә, караңгылык куерып, күкне йолдызлар басты. Дөньяның сихрилеге артты. Янәшәмдә барган Рифат та шулай уйлый иде булса кирәк. Ул тынлыкны бозарга базмый, әкрен генә минем белән бер адымга атлый. Кайвакыт кына ни өчендер авыр итеп сулаганы ишетелә.

Мин яшәгән фатирның хуҗабикәсе кайтмаган булып чыкты. Ялгыз кунудан бик нык курыкканга, Рифаттан үзебездә калуын үтендем. Мин — диванда, ул — каршы як стена буендагы урындыкта килеш, сәгатьләр буе сүзсез генә утырдык без.

— Минеке бул, — диде Рифат, миңа китәр алдыннан.

— Рамилә нәрсә дияр? Күрдең бит...

— Мин аңа үзем аңлатырмын. Минеке бул.

— Миңа әле нибарысы...

— Көтәрмен.

— Фәнүс ни дияр?

— Фәнүскә аңлаткансың бит инде...

— Әниең?

— Әнием сине яратачак, менә күрерсең. Мишәр дигәч тә, үз баласына усал түгел ич инде ул.

— Минем әнием дә бар бит...

— Минеке бул!

— Булдыралмыйм, Рифат.

Вәгъдәләр, сүзләр күбрәк тә әйтелде булса кирәк, ризалык алалмаган, шул ризалыкка өмете калмаган Рифат ишек тоткасына барып ябышты.

— Мин көтәрмен, — диде ул соңгы кабат.

Ишек араларны өзеп ябылды. Мин, урам як тәрәзә буена килеп, куе зәңгәр костюм кигән, үтә пөхтә бу егеткә нидер дәшәсе иттем. Әмма:

— Тукта! — дип кычкырасы урынга, сул кулым белән генә үрелеп, форточканы ябып ук куйдым.

Кибет чатына җиткәч, Рифат та икеләнеп калды булса кирәк. Ул, борылып, соңгы тапкыр безнең тәрәзәбезгә карады...

Мин бу хакта Фәнүскә сөйли дә ала идем. Тик... шул- чак вокзал буфетыннан ике кулына ике бала җитәкләгән бер ир-ат килеп чыкты. Рифат... Рифат! Рифат иде ул!

— Әнә, үзеннән сора! — дидем дә килеп туктаган поездга кереп киттем.

Рифат, әлбәттә, мине күрмәде. Аңа кулларымны изәп китеп барганда, ул, кара болонья курткасы кесәсеннән олы кулъяулык чыгарып, баласының борыныннан аккан юешен сөртеп маташа иде.

*1996*

## Судан тапкан йөземнәр

Арыкның ашкын суы, кояшның тире салдырырлык эссесе, Тянь-Шаньның болытларга өстән караган чал башлары күңел төпкелендәге бөтен хисләрен тергезде Сылуның. Көн-тәүлек эчендә әлеге түбәләргә менеп җитү кая инде ул! Таш-тауларның итәгенә генә дә якынлашмассың! Кыз эре плитәләр белән түшәлгән арык кочагында су уңаена агу белән канәгатьләнде. Ә дуслары, тәмам иркенәеп, табын корып утырганнар һәм кызны тәмам онытканнар иде.

Бөтен гәүдәсе белән агымга каршы торып күтәрелә, аннан чайкала-чайкала кирегә төшә торгач, Сылу суның салкынлыгына күнекте: башта аяк бармакларын гына тыккан булса да, аркан ятып, күзләрен йомгач, таралып, бар нәрсәне күңеленнән чыгарып ага, ага, ага... Арык текә: алкын сулар, Сылуны вак таш кына санагандай, уңга-сулга бәргәләп, тукталган авыллары янына китереп тә җиткерә. Кыз узылган араны чамалый, үтеп тә китми, күзләрен дә иртәрәк ачмый.

Арык буйлап югары күтәрелгәндә, кояш — каршыдан, шуңа күбесенчә аска карап атлый. Инде бусы соңгысы дип менүе иде. Агымда сөрлеккәндәй, кояш кочагында тукталып калды...

Көтмәгәндә икенче берәүнекенә береккән тәненә эссе йөгерде, иреннәре башка иреннәргә кушылып, үбешү исереклегенә чумдылар...

Шундый халәт, кояшның алтын кыршавы эченнән караган егет, кочаклаган кулларын җибәреп, Сылуның учларын үз учларына алмаса, артка каерылып:

— Гүзәл кыз, сиңа гыйшкым бар, ханымым бул минем! — димәсә, мәңге шулай дәвам итәр кебек иде.

Әлеге сүзләрдән соң Сылу, егетне ишетмәгән кебек, бик озак уйсыз калып торды. Әйткәненә төшенгәч, ни дип җавап кайтарырга да белмәде.

Эсседән сакланып, кара каймалы кыргыз эшләпәсе кигән егетне җентекле бер күзәтү белән күзәтә бирде. Атлетныкыдай гәүдә, калку күкрәкләр, матур тән, ирен өсләрендә юка гына мыек, бик үк кысык булмаган күзләр. Каты, биртләч куллары эш кешесе икәнлеген күрсәтеп тора.

— Ханымым бул минем, — дип башлаган яңа җөмләсен кыз: — Сылухан, — дип тәмамлап куйды да фикерен җәяргә ирек бирмәде.

— Сылухан, сылухан... — Егет инде сүзне ничек дәвам итәргә дә белми иде. — Сез әллә Чемионга килдегезме? Ялга?

— Әйе.

— Татармы?

— Каян белдегез?

— Күзләрегез өлгергән йөзем кебек. Кояш каралткан шәмәхә йөзем. Агачтан җыелып беткәч, арыктан таптым менә. Агар суда да йөзем бар икән!

— Ә Сез кыргызлар инде...

— Күрәзәлек кылышабызмы?

— Юк. Сез дә, алар кебек, үзегезгә йөземнәрнең кечкенәләрен генә сайлагансыз, — диде Сылу, көлеп. — Аннан... русчагыз да кайтышрак, эшләпәгез дә карлы тау түбәсе кебек. Ә үзбәкнеке... карбыз бөркәнчәсе сыман түбәтәй.

— Ханымым буласызмы инде минем? — диде егет кабаттан, иң кирәк нәрсәне исенә төшергәндәй.

— Сезгә ничә яшь соң, дустым?

— Иркен, — дип аныклады егет тә. — Тиздән егерме бер. Тормышым нык минем. Авылда эшем дә кирәкле. Торбалар эретеп ябыштырам. Бай яшәрсең. Сөйгәнем булырсың.

— Мин бит кырыкка таба атлыйм. Утыз биштә инде. Эҗең* санамасаң, аркадашың булырмын, — диде Сылу татарча гына, белер-белмәс кыргыз сүзләрен кыстырып калырга тырышып.

— Аркадашлар дүкәндә кирәк — яхшы мал алу өчен, достлар — үзбәк арасында, татар кызы кочакта булса хуп.

— Мин сиңа үзең кебек яшь гүзәлхан сайлашырмын!

Иркеннең йөзен кинәт кара болытлар каплады. Кыр тузаны кунган күз төпләренә яшь бәреп чыкты да, тут йөзенә юл салып, җиргә төште. Үзе арыкка тезләнде һәм Сылуның кинәт калтыравык алган аякларына капланды.

Әллә су, әллә аның эчендә калган егет сулык-сулык елый иде. Сабый шул әле, сабый, дип уйлады кыз, камыш кебек сыгылып төшкән егетне күтәрешеп. Бераз үзе дә күкрәгенә кысып торганнан соң, кул хәрәкәте белән генә арык читенә әйдәде.

Бик озак вакытлар сүзсез генә биек тау очларына карап утырдылар. Ак түбә башларына эсседән кара сырлар ясалган. «Тәнне чеметеп аккан сулар шуннан ук юл ярадыр инде», — диде Сылу үзалдына. Ә бу кыргыз егетендә таулар ныклыгы, катылыгы, горурлыгы юк микәнни соң?

Иркен инде тынычланып калган иде. Кыз соравын ишеткәндәй, бу эшләрнең сәбәбе хакында сөйләп китте.

— Өч көннән минем туй бит, — диде ул боек тавыш белән. — Хәзер менә кияү атнасы, яшьлек белән хушлашып йөрүебез. Сине күрдем дә кияү егетләреннән аерылып калдым...

— Ханымым бул минем, дисең тагын... Үзең...

— Минем булачак хатынымның бармак очларына да кагылган юк! Гәүдәсе күлмәк эченә яшерелгән, йөзен, ерактан караганда да, үзе бора. Ә Сез — гомеремдә беренче мәртәбә үпкән кыз. Беренче мәртәбә кулын тоткан да.

— Ә нәрсә комачаулый? Ярәшелгәнсез ич инде!

— Аны аңлату да кыен шул. Тугач та, үземә аталган күрше кызы — минем кәләш. Мәктәптә дә, шуны белгәнгә, баштарак гел бергә утырттылар. Бергә уйнадык, бергә укыдык, күбрәк бергә булган саен, бизә генә бардым, җитмәсә, малай-шалай да үзенчә үртәгән була. Югарырак сыйныфларда дус кызлары белән утыра башлагач та, күңелемдә урын ала алмады. Язын, армиядән кайткач, агалары килеп, килен төшәр вакыт җиткәнне искәрттеләр...

Әни ялгыз. Миннән кече дүрт ир бала. Ике кыз. Әтигә караган кебек карыйлар үземә. Ничек итеп биргән сүздән баш тартасың, аларны ана сүзен тыңламаска өйрәтәсең.

Ә менә Сезне күргәч, уйларым үзгәрде дә куйды.

Сездән башка һичкемне үпкәнем дә юк иде бит минем! Гомерлек хыялым тормышка ашты бүген!

— Бигрәк яшь шул әле син, сабый...

— Сезнең үзегезгә дә минекеннән артыкны биреп буламы соң?!Без кыргызлар иртәрәк картаябыз шикелле. Кояшта, җилдә йөзләр каралып сула, ком-ташта яланаяк йөргән аяклар балачактан ук яргаланып бетә. Әнә суда аккан сурәткә кара: менә дигән пар түгелме?!

Егетнең озын, сагышлы хикәяте тора-бара Сылу колагына җил шавы кебек кенә ишетелә башлады. Ул да түгел, кояш та түбән тәгәрәде. Арык сулары да бераз әкренәйде. Егет торды. Сылуны да урыныннан кузгатты.

— Киттек!

— Кая?

— Авылга!

— Нигә?

— Анамны күрерсең! Бәхет йөземеннән авыз итәрсең.

— Йөземдә бәхет буламыни?

Егет дәшмәде.

— Базар саен ич ул... Бәхет булса, базарга куймаслар!

— Була! — диде Иркен ирләрчә ныклык белән. Аннан Сылуны, җилтерәтеп, кукуруз кырына алып кереп китте.

...Алар шактый озак бардылар. Кыздан биек үскән кукурузлар арасына качкан сукмакта каршыларына ник бер адәм килеп чыксын!

Таныш булмаган егет белән япан кырда калудан курку хисе бөтенләй юк иде. Тора-бара каршыда йортлары яхшылап агартылган бер авыл калыкты. Иркен — алдан, Сылу арттан атлады. Һәр йорт каршысыннан узганда, бер оя балачага урамга атыла, күп тә үтми, ата-анасы да, чыгып, капка баганаларына сөялә. Иркеннең сәламнәренә алар гаҗәпсенгән кыяфәттә генә җавап кайтаралар.

Менә капкасы юлга каршы торган ишегалдына килеп керделәр. Болдыр идәненә бик якын уелган тәрәзәләргә бер уч күз сибелгән иде.

— Эҗе, эҗе! — диештеләр бала-чагалар.

Ул да булмады, бакча юлыннан аркасына коры-сары бәйләме аскан кортканың күтәрелгәне күренде. Эссе көнне дә көрти киеп кайткан бу карчыкның, бик карт тоелганга, Иркеннең әнисе булуына ышанасы килмәде дә:

— Апа, михмоныбыз бар гуй, — дип әйткәнен ишеткәч, шулай икәнлеге аңлашылды.

Карчык ихата уртасына узды, коры-сарыны ишеп кенә өстеннән җиргә ташлады, үзе дә, лыпылдап, шуның өстенә килеп төште. Аның җир кебек йөзе агарып киткәндәй булды. Ана белән бала үз телләрендә кызу-кызу сөйләшә башладылар. Сылу сүзләрен игътибарга алмады, карчыкның кипкән йөзем кебек күзләре кызның кунак кына икәнлегенә ышанмаганлыгын сөйли иде.

— Тандырга ут төртеп җибәр әле, нан пешерим, — диде ул бераздан кабалана-кабалана. Кызның, чакырып та, өйгә атламавын күргәч, кулы белән көрпәчәдән урын күрсәтте.

— Эҗе, мин — Казаннан, татар кызы, михмон, Чемионда тукталдым, рәхмәт, һични кирәкми, хәзер китәбез, — дип тезде Сылу, калырга да, тиз генә чыгып таярга да белмичә.

Хатын-кызлар үзара аңлашсын дип читкәрәк китеп торган Иркен, баскыч алып, өй түбәсенә терәде һәм тәлгәшләрдән инде бөтенләй бушап калган йөзем ботакларына үрелде. Иң-иң өстә әби-бабайларның сандык төбендә яткан тәмәке янчыгына охшаган бер нәрсә асылынып тора иде. Иркеннең бармаклары җелт кенә бөрмә бавыннан тартып җибәрүе булды, әлеге кечкенә капчык аска очып төште, һәм ямь-яшел яфраклар арасында кояшта күкләнеп торган йөзем тәлгәше күренде.

— Бәхетле бул! — диде Иркен, тәлгәшне чем тирәсендә бөтереп.

Болдыр идәнендә, яңакларына таянып, аптыраштa утырган карчык та, аның белән килешкәндәй, ияген селки иде. Ыру гадәтләрен бозып, туйга нибарысы өч көн калганда, улының икенче берәү белән җитәкләшеп кайтып керүеннән ул әле дә айнымаган һәм Сылуга инде яшь киләш итеп карый иде булса кирәк.

Өй эчендәгеләрнең берсе, иң кечкенәсе, ике-өч яшьләр тирәсендәгесе, абыйсына үртәп тел чыгарды да олырак апасы артына яшеренде.

Инде китәргә вакыт: әйтеләсе сүз әйтелгән, өзеләсе йөзем өзелгән иде. Сылу, хушыгыз дигәндәй, балачагага күз кыскандай итте, аннан ике куллап, мөселманчалап, ананың сөякчел кулларына үрелде:

— Исән-сау торыгыз!

Карчыкның мимылдаган иреннәрендәге сүзләрне Иркен дә аңламагандыр. Кызның китеп баруы килеп керүеннән битәр аптыраткан иде аны.

— Йийең! — диде иң соңында ана, елмайгандай итенеп.

— Авыз итәргә куша, — дип шәрехләде Иркен урыс телендә.

Сылу капкага атлады. Көндезләрен гадәттә бушап кала торган урам умарта күчедәй кайный иде.

Иркен, урам кырыннан аккан арыкчыкта тәлгәшне юганнан соң, йөземнең иң эре бер бөртеген чеменнән аерды. Аннан бераз гына тешләгәндәй итте дә Сылуның иреннәренә китерде. Күзәтеп торган халык өчен бу гаҗәп серле, күтелмәгән бер вакыйга булгандыр, алар, яшьләргә юл биреп, әкрен-әкрен койма буйларына елышты. Сылуның күңелендә мутлык, шаянлык калыкты. Иркеннең көчле кулларына ныграк ябышып, очар кош кебек кенә урамны узды ул. Егет кулларыннан йөзем ашады, матур сүзләрен тыңлады, туктаусыз көлгән булды.

Авылны чыгып, чәкәнбашлар арасында кеше күзеннән югалгач, егет тагын:

— Ханымым бул инде минем! — дип сүз башлады.

— Китми явар болыт булдың тәмам!

— Чык инде миңа! Мин сиңа йөзем генә ашатып яшәтермен! Күзләрең кебек эре, сусыл йөзем. Бәхетле итәрмен, бәхетем булырсың!

— Мин болай да бәхетле ләбаса!

— Бәхетле хатын арыктан кояш эзлимени, дим әле мин менә...

— Илем әллә кайда кала бит, Иркен!

— Илең иркәң туфрагында булыр, Сылухан!

— Син малаем шикелле генә әле...

— Яшьтәмени хикмәт! Эшләмәгән эшләрнең үкенечендә! Мине әнә шулар картайта. Бөтен хыял сөйгән кешегә өйләнү иде лә! Үпмәгән, кочмаган, бер кыз белән дә дуслашмаган егет бит әле мин, Сылухан. Синең иреннәреңнән затлы йөзем тәме килә! Мин әнә шуны аңладым!

— Кояштан исергән иреннәр ул, Иркен. Кыргыз тауларында акылларын югалтканнар.

— Юк! — Иркен шул сүз җитезлегендә киң ачылган куллары белән кочагына эләктереп алмакчы булган иде, Сылу, кыр кәҗәсе шикелле, сукмак буйлап алгарак йөгерде. Егет куып җиткәндә, алар басуны чыкканнар иде инде.

— Син, һич югы, туема килерсеңме? — диде Иркен, иптәшләре янына җитәрәк.

Нәрсә дисең?.. Каршы әйтеп, күңелен төшерәсеңме, ризалык биреп, ялганчы буласыңмы?..

— Мин сине көтәрмен. Әгәр килмәсәң, әгәр килмәсәң... мин аңа өйләнмәячәкмен! Сиңа, дөньяга, мине ирексезләгән кануннарга үч итеп!

— Исемең дә шуңа Иркендер инде синең. Санлашканга канун бездә дә бар. Бик үк иркенәйтми әтиәни, — дигән булды Сылу, егет бераз басылсын өчен.

— Мин сине алырга барырмын! Ап-ак «Волга»да! Туй көнен кунакханә төбенә чыгып көт! — дип үрсәләнде Иркен аның саен. — Йөземем минем, татар кызым, Сылухан...

Сылу берни дәшмәде.

Алар авылга барып йөргән арада, кияү егетләре Сылуның иптәшләре янына килеп чыкканнар һәм шактый гына кызып та өлгергәннәр иде. Иркеннең үсмер кебек бер күрүдән гашыйклыгын, татар кызының кунакка килергә теләмәвен сиземләгәч, алары тәмам ярсыды. Сәбәбен шофердан табыпмы, аңа бәйләнә үк башладылар. Сылулар шуңа күрә тизрәк китеп бару ягын карады.

Куркып калган үзбәк агае хәрәкәт туктатылган юлга кергән икән, аны кисеп, киң итеп казылган чокырны сикереп чыкканнарын машина шул чокырның каршы ягында асылынып калгач кына аңладылар. Иптәшләре тартып алганда, Сылуның авыз-борыны, кием-салымы кара кан иде. Ул сүрелеп барган кояшта талгынланып, саегып калган суга кереп ятты. Кызны инде күтәреп йөртә алмас хәлгә килгән агарсу, дулкынчыкларын кызылга буяп, кояшка таба йөгерде.

Туган якның кырыс салкыннарын исенә төшергән тау елгасы, яраларны төзәтмәсә дә, кан агуын киметте. Иярдәге Иркен әлеге хәлләрне күргән икән. Килде. Кулларына сак кына күтәреп, кызны судан алып чыкты. Соңгы тапкыр дигән сымаграк иреннәренә үрелгән иде дә өркеп киткәндәй тукталып калды. Ә бәлки, хисләрен кабат кузгатасы килмәгәндер.

Таш өемнәрендә үзе дә ат кебек басып, югарыдагыларга карап торган машинаны чабышкылар белән күтәрттеләр.

— Күрәсеңме, синең китүеңне юллар да теләми! — Әллә чынлап, әллә сүз юкта сүз булсын дип кенә әйтә идеме Иркен...

— Ә бу юллар авылыгызга илтәсе булган бит, — диде Сылу, шаяруга борырга маташып.

— Алай булгач, бигрәк тә! Машинага кадәр синең безгә кайтуыңны тели.

Сылу бизгәк тоткан кебек калтыранган машинага кереп утырды. Әкрен генә урыннарыннан кузгалып киттеләр. Иркеннең:

— Иреннәреңдә бәхет йөземенең тәме! — дип кычкырып калганы ишетелде.

Иртәгесен, әле китәр көннәр җитмәгән булса да, Сылу, чемоданнарын күтәреп, олы юлга чыгып басты. Арыкта аккан суларга карарга батырчылык итмәде. Хушлашып, хатлар агызса да, Иркеннәр авылына бармаячак иде.

Таулар арасыннан кыз утырган автобусның тәрәзәсенә башын сузган кояшка кул яссылыгы гына болыт кунган, һәм аның аша узганда нурлар болытны кыргыз егете кулларыннан Сылу ашаган тәлгәш төсенә буяганнар.

Күктәге бәхет йөземнәре кыз утырган автобуска ияреп барды-барды да, үзе янына чакырып кул изәмәгәненә, китеп барганына үпкәләгән шикелле, борылышка җиткәч, икенче якка юл алды.

*1998*

## Аккош җыры

Әллә нинди сихри август киче булды бу. Җилеккә төшкән яңгырлардан соң, җәй эсселәрен бүләккә китереп, табигать безнең белән шаярта иде, ахрысы. Мин менә шушындый чакта да туңам, эчтәге бер өркүдән туңам. Киң ябалдашлы карт өянке астына ике кешелек кенә итеп ясалган утыргыч мине Рәдифкә сыендырып ук куйгач, куркуым тагын да арта төште.

Каршы юл буйларына тезелгән баганалардагы зур лампалардан төшкән якты төнне эңгер-меңгер вакыты сыман итә: мин Рәдифнең агарган сакал бөртекләрен дә, сирәгәйгән тешләрен дә, хәтта ике күзенә төшеп килә торган акларын да шәйлим. Ничә яшьтә икән ул?

— Сез кемнәр белән укыдым, дидегез әле?

— Җитәкче абзаңнан нәп-нәкъ бер ел түбән курста.

Гаяз абыйның да башында чәч диярлек нәрсә калмаган. Гәүдәсе Рәдифнекеннән дә түбәнгәрәк иелгән, бөгелеп-сыгылып йөреше тәмам картларга охшата да куя.

Ә аңа ничә соң? Иллеме? Кырык бишме? Димәк, Рәдиф абыйсына да шул чама. Яше белән кызыксынганны аңларлык та булмагач... Картайган инде ул да, картайган.

Абый, туганым, әфәндем, дус — кайсы сүз ныграк барыр иде үзенә?

— Сезгә алайса илле... картлач... — Ачуын чыгарасы килгәнгә әйтелгән сүз үзенекен эшли. Ниһаять, аның да түземлеге бетә: иреннәре бер-берсен ашарга, чепи күзләре әрле-бирле йөрергә керешә. Әйдә, әйт, әйт, ачуыңны басарлык ни дә булса әйт инде!

— Син миңа картлач түгел, хәтта абый диясе дә, Сез дип дәшәсе дә булма, кызый! Рәдиф! Бары шулай гына!

— Ә мин менә апаң булырга да, әнкәң булырга да риза.

Рәдиф һич кенә дә минем үҗәт, шаян холкымны кабул итәргә теләми, сүзне гел җитдигә ала.

— Шулай... син риза... Яратырга гына теләмисең... Тиң итәсең генә килми... — Аннан үзе дә шаяруга күчә: — Әнкәм булсаң, иркәләр идең әле, күкрәкләреңә кагылырга да рөхсәт итәр идең.

— Карт кына түгел, кызык та, әдәпсез дә икән әле Сез. Соң, кайсы илле яшьлек «бала»ның әнкә күкрәгенә тотынып утырганы бар?

— Әгәр мин сине белмәсәм, бу телеңә үпкәләп, мондагы бөтен лампочкаларны кырып бетергән булыр идем. Әйдә, яшәсеннәр, яна бирсеннәр. Синең кара күзләреңне күрсәтеп, күңелемне сөендереп утырсыннар. Утсыз җирдән сине табуы да кыенрак булыр. Кочаклавы да!

— Тимә инде, Рәдиф абый... — Мин терсәкләрем белән аннан ерагаймакчы булам, әмма торган саен кочагынарак керә баруымны аңлыйм.

— Тимә дә тимә. Беләсең килсә, сиңа тимичә һәм синең турыда уйламаска тырышып, ничә ел яшәдем.

— Тагын бер-ике ел гына яши алсагыз да, мин Сезгә элеккеге хөрмәтемне саклый алыр идем. Ә болай. Фу, картлач...

Нәрсә сөйлим мин?! Олы яшьтәге кешене ни дип мыскыллыйм?! Шушы сүзләрне ишетер өчен килгәнме ул монда?

— Их, мин синең телеңне белмәсәм икән! Әйттем бит инде, мондагы бер генә лампочка да исән калмас иде, дип.

Сүзенең дөреслеген исбатларга теләгән шикелле, Рәдиф абый иң якындагысын җирдә яткан бер ташны атып коя да төшерә.

— Фу, әле Сез тәртипсез дә икәнсез!

— Китермә инде ачуны, зинһар. Кайчандыр сине күргәч, шигырьләреңә, аннан да битәр күзләреңә гашыйк булгач та әйтергә теләгән бер сүз бар иде. Шуны менә хәзер әйтә алсам... Куркыта. Аңламассың шикелле. Көләрсең. Йә бөтенләй үк китеп тә барырсың. Теге вакытта, очрашу кичәсендә, Илмира апаң чәй мәҗлесенә килеп кермәгән булса, онытылып китеп ычкындырган да булыр идем мин ул сүзне, Ходай саклаганмы? Язмышларны үзгәртергә теләмәгәнме? Әллә бу эшне үзебезгә калдырганмы?

Күз алдыма аның буйдакларча җыештырылган бүлмәсе, каты-коты ризыклы өстәле, йонлач эте килеп баса.

Эте биеклегендә калып, алдыма тезләнгән Рәдиф абый... Ничек ошаган иде ул миңа! Әле яшь. Сакалында да мондый ап-ак буйлар юк. Күзләренең моңы да кимрәк. Киемнәре дә чистарак, пөхтәрәк.

Һич югы, бер сүз әйтсен дип көттем бит ул чакта. Нибары бер сүз көттем! Сак кына чәчләремә кагылсын, керфек очларыннан үпсен дип теләдем.

Ә үзе нинди сер саклаган икән? Һичкемгә әйтә алганым юк, ди...

— Ә бит, Зифа... Юк, кирәкмидер дә инде… Ул сүзне әйтмәс өчен, хәзер сәбәпләре дә күбрәк. Ул чагында... Бертуктаусыз миннән көлүләрең, исең китмәгән булып кылануларың, әллә чынлыкта да ошатмавың, Илмира апаң белән төрттерүләрең...

Әйе шул, Илмира апа… Йортларын, балаларын иренә калдырып, аның артыннан, кием-салымын да алмыйча, туган ягына кайткан Илмира апа…

— Беләм, Рәдиф абыең сиңа гашыйк булачак. Мине бәхетсез итмә, аңа битараф күренергә тырыш. Нинди генә җилбәзәк булса да, миңа аннан башка һичкем кирәкми. Тирә-ягында болай да күпме кызлар аның. Ә менә югалтуым тик синең аркада гына булыр шикелле... — дигән иде ул, шаккатырып һәм бер

җирдә үзенә тынгы, эш таба алмас, бераз ялкаурак, бераз аламарак, җилкуаррак, әмма үтә дә нечкә күңелле Рәдиф абый хакына үзем дә үләргә дә риза берчакта.

— Белмәсәгез — белегез, мин бит Илмира апага Сезнең белән аралашмаска, очрашмаска, сезне һәрвакыт читкә тибәрергә сүз бирдем. Рәдиф абыйга һич кенә дә исем китми, дип алдадым.

— Алдадың? Синме?

Мин булса нәрсә?.. Әйтерсең, үзе гел дөресен генә сөйли.

— Башкалар турында әз генә булса да уйламадыңмыни? Ул Илмира апаны яратмый, ахрысы, дигән уй күңелеңә бер генә дә килмәдеме?

Ул чактагысын кем белгән? Инде хәзер килде ни дә, килмәде ни. Көзгә кергәч, бу өянкенең яфрак коймыйча яшәргә әзерләнүе кебек бит ул. Салкында яшел яфракларны, телим дип кенә, өшетмичә саклап кара!

— Аның белән очраклы гына танышканны, очраклы гына кушылганны беләсең лә син. Тимер юл вокзалындагы ике йортсыз-җирсез бер җан булганыбызны мең кат сөйләп тә... Янәшә утырып, туган якларга кайттык та, шулай язгандыр шикелле генә, бергә яши дә башладык ич без.

Тормышта очраклы нәрсәләр аз түгел. Өянке ботагын, үскәч, безне ышыгына сыендырыр дип, кайчандыр кем дә булса ишегалдыбызга төртеп куймаган. Каяндыр җилдә очып килгән бер орлыктан тишелгән ул. Бүгенге төн дә — шул очраклыкларның берседер...

— Алай җиңел генә тормыш юлларыңны үзгәртә алгач, минем белән уйнама инде син, Рәдиф абый, уйнама! Әнә тагын берәрсе белән вокзалдан каядыр бер якка утыр да кит. Туйгач, икенчесе белән китәрсең...

Рәдиф абый дәшми. Өянкегә тагын да ныграк елыша. Карашын минем күзләрдән читкә борырга тырыша. Аның мине ишетергә теләмәгәне көн кебек булса да, ачуын чыгарасы килү теләгем һаман да басылмый:

— Мин менә бер генә кеше өчен дә, Илмира апа кебек, гаиләмнән, бигрәк тә баламнан баш тарта алмыйм! Бердәнберемне, кадерлемне югалтырга тиеш түгеллегемне мәхәббәт исереклегендә онытаммы соң?!

Рәдиф абыйга кинәт җан кергәндәй, күзләренә нур кунгандай була. Ул тагын миңа таба борыла.

— Нәкъ менә шушы әйбер миңа икегезне ике төрле бәяләтте дә. Миңа бит баласы өчен яшәүче хатын кирәк, ана кирәк.

— Соңга калган тәүбәкәр сүзе генә инде бу...

— Әгәр гомерем буена беркемгә дә әйтмәгән ул сүзне менә хәзер әйтсәм дә… Юк, аңламассың син мине. Әйткәнемнең кадере булырмы?..

Рәдиф абыйның миңа сүз катарга да гөнаһ санатырлык бер гөл итеп караган чакларын искә төшерәм. Янымнан да күтәрелеп карарга базмыйча узган чакларын. Нәрсәләр бар безнең арада? Нинди киртәләр аны минем ягыма чыгармый?

Рәдиф абый үзеннән нәрсәдер көткәнне сизде бугай. Көрсенде. Офтанды. Тамакларын кырды. Өянкегә бер терәлде, бер купты... Алай да сөйләрлек көч тапты:

— Иң изге сүзне ахыр мизгелгә саклыйсым, сиңа күңелеңне тузгытырлык, елатырлык бер җыр калдырып дөньядан китәсем килә иде минем.

— Дөньядан киткәндә, хатлар язсаң гына инде, Рәдиф абый. Монда кадәр килеп, хушлашып йөри алмассың. Ул хатлар мине табарлык, мин дә аларны укый алырлык хәлдә булсам гына инде.

— Ну, телең! Мин бит ул сүзнең миңа мөнәсәбәтеңне үзгәртерен күңелем белән тоям, әйтә генә алмыйм. Әле әллә никадәр әйтелмәгән матур сүзләр барда! Һәрберсенә бер көнеңне бирсәң дә...

— Аккош җыры кебегрәк икән лә ул сүз. Мин көткәндә җырланмаган бер җыр...

Бераз читкәрәк этенүем аркасында, эскәмия кырында чактан гына эленеп калдым. Үзем төн уртасы җитеп тә, өемә кайтмаган Илшат турында уйлыйм. Ул югында чит-ят бер ир белән үзара мөнәсәбәтләрне ачыклап утыру килешәме икән? Ерак юлдан килгән кунакны урамда тоту килешәме?

Туңуым, Илшат хакындагы билгесезлектән эч пошуым тагын да көчәя, дерелди үк башлыйм. Рәдиф абый төн салкыныннан дип уйлый булса кирәк, курткасын иңемә сала.

— Юк, кирәкми, миңа кыен, керим. Кайтмаса кайтмас... Иртәгә — бәйрәм. Пешерәсе-төшерәсе, иртәрәк торасы да бар.

Әйтерсең, көн дә бергәләп утыргычта гәп саткан күршем белән генә хушлашам. Рәдиф абый, үз-үзен белештермәгәндәй, ут иреннәре белән минем иреннәрне эләктереп алмакчы булуын күрдем дә, торып, ишек төбенә йөгердем. Аның артымнан:

— Зифа!.. — дип нәрсә хакындадыр кычкырганы ишетелә.

Мин сине көтәрмен, дип әйтергә теләдеме ул? Үпкәләттем, дип әйтәсе килдеме аның? Мәңге онытa алмасын аңлатырга теләдеме?

Ул сүзнең инде аңлашылмавы хәерлерәк. Борылып карамадым. Кердем. Тәрәзә төбенә килеп утырдым. Күзләрен уа-уа, улым да аш бүлмәсенә чыкты.

— Ник утны яндырмадың? Әти кайтмадымыни, әни?

Ни әйтергә белмим. Каршы як юлда бер ир-ат шәүләсе тора. Йортны әйләнеп, шул якка чыгып баскан Рәдиф абый икәнлеген аңласам да, ул мине шәйләмәсен өчен, ут кабызмыйм.

Тыштан искән җилгә дә ачу килми. Ачык форточкадан кергән һава йөрәккә хәл бирә. Инде туңуым да басыла төшкән.

Рәдиф абыйга тәрәз аша булса да әйтер сүз юк икән... Нәрсәнедер — ут кабызуымнымы, чыгып алуымнымы көтеп тора-тора да, йоклаганнардыр инде диптер, чакырасыма тәмам өмете өзелеп, үзе керергә батырчылык итмичә, юл буйлап китеп бара.

Казаннан ук китүеме аның? Мине генә күрергә килгәнме? Иптәшләренә барырга булдымы? Инде таксилар да азайган бер вакытта... Хәер, ул ир-ат лабаса! Миңа еллар дәвамында әйтергә әзерләгән сүзен дә әйтә алмый киткән ир-ат...

Йокы вакытын тәрәз төбендә уздырып, иртән, саф һава суларга дип, ишегалдына чыкканда, күз лифт кырындагы почта ящигына төште. Ачкыч та алып чыгып тормыйча, капкачын каерып ачтым. Уч кадәрле кәгазь кисәгендә нибары бер җөмлә: «Зифа, мин сине яратам!»

Кәгазьнең икенче ягын әйләндерәм. Ул минеке булса кирәк: анда моннан берничә ел элек шушы сүзләрне көтеп тә ишетмәгәнгә кәеф кырылып язган бер куплет шигырь:

Мин көткән сүз юкмыни соң күңелеңдә?
Нәрсә уйлап торасың син су буенда?
Мине сөйгән тал-тирәкләр ирештерер —
Син аларга әйтер идең, һич югында.

Ничек аңа килеп кергән ул? Кылт итеп Илмира апа кәсәсендә онытылып калган шигырьләр — куен дәфтәрем исемә төште.

Кичебезне уздырган өянке астындагы утыргычка килдем. Рәдиф абыйның җылысы калгандыр шикелле, искергән такталарын капшадым. Ул җылыны тоймадым. Аккошларның соңгы җыры шулай кыска була микәнни? Шул җырга алып килгән юллар нигә шундый озын? Җырлап югалудан ни мәгънә?!

*2001*

##Ерактагы офыклар

Җәймә, тышлыклар, үз кулы белән кидерелгән, җәелгән булса да, Алсуның тәненә сафлык тойгысы бирмәде. Әле уңга, әле сулга борылып ята торгач, түшәмдәге сурәтләр белән уйнарга кереште. Кул сузарлык, карашны чикләгән ара иде бу. Төнге утның түбәннән күтәрелгән яктысында аркылы-торкылы сызыклар балалар китапларындагы лабиринтларга охшап калганга, имән бармагы эзләр арасыннан сул якка таба китте... Аннан хәрәкәтсез калган ягын оетып торган каюта диварына килеп терәлде.

Диварның аръягында — Шамил. Күршедәге Ләйсән бүлмәсенә аяк очларында гына узса да, ул икәнлеге тәгаен. Алай итеп, борын яфракларында чебен дә утырып тормаслык итеп, Шамил генә сулый ала. Алсуның нәкъ колак турысына карап йокыга киткән борынның дивар тишәрдәй мышкылдавы болай да килергә теләмәгән йокыны күзләреннән тагын да еракkарак куган иде.

— Мыш-ш-ш, мыш-ш-ш...

— Салмыш-ш-ш, — дип җавап бирде кыз эченнән генә, күңелен күтәрер өчен бер сәбәп булсын дигәндәй.

Бер урындарак төртелеп торгандай итенде дә имән бармак әнә шул мышкылдаган борын тирәсенә юнәлде.

Ул Шамилнең борын эченнән баш сузган төкләрен, кылдай кара мыегын кытыклап узганга салынганнан соң, кап-калын ирен өстендә тукталды.

Әле көндезен генә, качып, мине үпкән иреннәр. Мут, әрсез иреннәр, — дип уйлады. Ачуны да китерми, теләкне дә уятмый торган иреннәр иде бу. Юантык гәүдәле авыл агаеның ит калҗасын эләктергән кебек үбүен яңадан тойган кебек булды. Бу юлы тәненнән нигәдер чиркану йөгереп узды. Ә бит диварга сы-

ланып, Алсуга карап яткан ул иреннәрне үзенә сиздерми генә үбеп алырга бик җай вакыт. Бер мыскыл рәвешендә генә...

Юк, керфек очларыннан үбүең яхшырак. Шамилнең күзләре күзгә көн кебек соргылтлар. Атнықына охшатып, аху дияр идең, аттагы моң юк үзләрендә. Дивар белән гәүдә арасына кысылган икенче учын, көчхәл белән тартып алып, Шамилнең ташкурчакныкы кебек ялтыр-йолтыр килә торган күзләре тирәсенә куйды.

Көзге күкне болытлардан ачылган итеп күз алдына китерде. Шамилнең күзләре дә җетеләнеп киттеләр. Аннан әлеге яшькелт алмаларны учына коеп төшергәндәй итте дә шуларга карап ята башлады. Озакламый хыял тудырган сурәтләр эреп юкка чыкты. Тора-бара изри башлаган акылында Шамил дә онытылды, әмма йокы үзе бик еракта иде әле. Алсу, оеп, бары тик төн агышына кушыла баруын гына аңлады.

Бу төн башка төннәргә һич охшамаган иде. Су өстеннән йөзеп барган пароход тәрәзәсеннән айның карап тормавы да, бүлмә тарлыгы да, түшәм тәбәнәклеге дә төннең серлелеген, шомлылыгын тагын да арттырганга, Алсу йокыга китәргә дә курыкты бугай.

Астагы киштәдә, нәкъ шундый ук тарлыкта, төнге утның күзенә карап, Васыйл ята булыр.

Ә нигә яндырып калдырган ул аны?

Мин курыкмасын өченме?

Кемнән куркыйм? Васыйлданмы? Булмаганны!

Үзе өчен кирәк санаганмы?

Әй лә, янсын.

Васыйлның борылганы, хәтта тын алганы да сизелми. Ниләр уйлый икән? Ниләр тели?..

Аның эчке дөньясын яшерә алмый торган күзләренә карыйсы килеп китте. Сирәкләнгән чәчләреннән сыпырасы. Авыр эш күрмәгән, тупасланмаган учларына яңагын куеп торасы.

Һәрбер үртәүләргә, кире сүз әйтүләргә:

— Алсу, син алай димә, — дип сүз башлауларыннан арганга, тагын шуны ук әйтер дип шикләнеп, күңеле белән Васыйлның да йокламавын сизсә дә, дәшмәде, аңа табан әйләнеп, йөзтүбән яту белән канәгатьләнде.

Озакламый таң атты. Тәрәз ярыкларыннан елга өстендәге салкын узгандай булды. Әле тын, тыныч иде. Шамилнең генә мыш-мыш сулаганы ишетелә. Шул авазны чыгарган борынга Алсу әкрен генә чиртеп алды да, юрган кебек шуып, каюта идәненә төште.

* * *

Васыйл, Алсуның кулларыннан тотып, күзләренә карады. Берни аңлатмыйлар шикелле. Дулкыннар өстендә, дулкын-дулкын көй астында кыз җанына узарга теләгән иде.

Нигә һаман теләсә нәрсә сөйләнә Алсу? Дулкыннар шавында да мәгънә юк микән әллә? Бар, нишләп булмасын!

— Мин синең көйне тоюыңны телим, — дип, Васыйл кыз күзләренә тагын да назлырак караш ташлады.

— Ә мин тоям! Җил генә бер якка исә. Көчәйми дә, тынмый да. Дулкыннар да гел бер көйне көйли... — диде Алсу. — Син дә әнә шуңа гел бер якка әйләнәсең.

— Башкалардан әйләнә-әйләнә качам бит мин. Күзләре гел бездәдер шикелле. Китик әле. — Васыйл көйнең урта бер җирендә биюеннән туктап калды.

Алсуның бармаклары да, керфекләре дә, иреннәре дә нигәдер йомшак кына дерелди иде. Күңеленә дулкын көе үткәнме?..

Тәмәке кабызган булып, егет арткарак калды. Янында тартып, Алсуны үпкәләтәсе, үзен дә кыен хәлгә куясы килмәде?

Кыз ятакның икенче каттагысын сайлаган булып чыкты. Бәлки, инде йокыга да киткәндер.

Ниләр уйлап йокыга китте икән ул? Ни теләп?..

Аңа кадәр кул сузарлык ара. Караш чикләнгән биеклек. Сул як диварның артында әлегә беркем юк. Төнгә лампочканың сүрәнен яндырып куйган иде. Күзгә карап тора.

Әллә сүндерергә инде? Алсу ни әйтер?.. Куркып калмасмы? Әй лә, янсын...

Ләйсән дә кайтты шикелле. Әллә Шамилнең урыны шул каютага туры килде микән? Әйтмәгән дә булды тагын...

— Мыш-ш-ш, мыш-ш-ш...

Кара, туктады. Кытыр-кытыр. Кыштыр-кыштыр. Ләйсән янына төштеме ул? Башка бер-бер тавышмы? И-и-и, кешеләр, ичмасам, рәхәтләнеп сөешә, сөелә торганнардыр. Тиккә алай мышнамыйлар бит инде!

Инде сәгать ничә икән? Күрше бүлмәдә, үзләрендә һава беткән дә безнекен суырып кертер шикелле, кемдер — Шамилме — һаман да бик тирән итеп сулый.

— Мыш-ш-ш... Мыш-ш-ш...

Алсу ишетсә, бер хикмәтле сүз әйтеп куяр иде. Салмыш, дипме шунда. Шалмыш, дипме...

Җаннарны суыра бу сулау... Тәндәге теләкләрне дә суырып алсачы...

Алсу ишетә микән?

Йоклыймы ул? Аның диварында нәрсәдер кыштырдаган шикелле. Әгәр йокыда булса, кемнеңдер каршы бүлмәдән килгән борын җыры уятмаса ярый инде.

Тәмәке тарту теләген көчәйтеп, тәрәз ярыкларыннан, буылып-буылып, иртәнге саф һава керә.

Кул биеклегендәге түшәм. Чакрым ераклыгы ханым...

Менә ул, юрган кебек кенә шуып, аның башмаклары өстенә төште...

* * *

Шамил дуслары яныннан кайтып кергәндә, Ләйсән йокыда иде инде. Уяу булса, эндәшер, дип уйлады ул, күтәртмәгә басып, икенче катка күтәрелгәндә.

Диварның теге ягындагы янәшә киштәдә тәгаен Алсу ята. Түбәндә йокларга яратмыйм, дигән иде... Битләрен биткә терәп ятсыннар әле менә. Иреннәренең тәме шампан ачысы белән дә басылмады.

Их, дустының кызы булмаса соң!

Рәхәтләнеп сөешә торганнардыр инде. Мин үпкән иреннәрне Васыйл үбә торгандыр...

Ичмасам, Ләйсән дә дәшми. Кич бию мәйданчыгында булмаганга үпкәләгәнме ул? Берәр нәрсә сизгәнме? Алсу әйтмәсә генә ярый инде.

Нәрсә дип кызыкты соң кызыйга?! Үзен яраткан Ләйсән булмагандай...

Дулкыннарның пароход калайларына килеп бәрелгәне ишетелә. Тын. Тыныч. Шул уйлар белән Шамил әкрен генә йокыга киткәнен дә сизми калды.

* * *

Таң атмаса да атмады. Шамил, уянса, һич югы, мышнавыннан туктар иде.

Кем яныннан кайтты ул кара төн уртасында? Ниләр эшләп йөрде?

Өске каттан, борыннарны әчеттереп, сарымсак, кыяр, шампан исләре төшә.

Юк-бар уйлар да аны теләүне сүрелдерми, дип борчылды тәкате корыган Ләйсән.

Ә башкалар... Юк ла, алар — бәхетлеләрдер... Кочышып-сөешеп, елга буйлап дулкыннарда агалардыр.

Дөньясына төкереп бер ял итәм, дигән булды.

Чү! Күрше бүлмәдә тып итеп нәрсәдер идәнгә сикерде. Алсудыр әле! Ләйсән колагын каюта диварына терәде.

— Кил инде, яныма утыр, — диде Васыйл, ике арадагы киртәнең теге ягыннан. Әллә нинди ягымлы бу тавыштан Ләйсән, үзенә әйтелгәндәй, сискәнеп китте. Колагын салкын диварга тагын да ныграк кысты.

— Утыр инде...

— Нигә?

— Тавышыңны ишетәсем килә — ни булса да сөйлә әле миңа.

— Телисеңме — шигырь... — диде Алсу. — Мин бит палубада, сездән качып, җайлы ятакларда көн буе язып яттым. Менә берсе:

> Тезләр — тездә, күзләр — күздә, иреннәр пар,
> Тәннәремдә әллә нинди ут теләк бар...

Алсу сөйли дә сөйли. Нәрсә карый бу Васыйл?! Ни теләгәнен үзе белмиме? Алсуны аңламыймы? Бөтен язганы әйтеп тора лабаса...

— Алсу, үзең шундый шигырьләр язасың, үзең үптермисең дә!

— Көчләп сөймәвең өчен якын итәм дә инде мин сине! — диде Алсу, Ләйсәнне гаҗәпләндереп. — Син башкаларга охшамаган. Әдәпле...

* * *

Ә Идел ага да ага. Гайбәтче хатыннар беркатлылыгы белән, минем дулкыннарымда никадәр пар кушылгандыр, дип ага иде ул. Аның гына текә дулкын булып күтәрелгән күкрәк очларындагы теләген аңларлык беркеме юк. Ә диңгезгә әле ерак... Таң атканда серлелеген югалткан офыкларга үзе дә әллә ни алгысынмый иде.

## Әлифба

1943 елның пычрак көзе иде. Авылның озакка сузылган сугыштан хәлсезләнгән, тиз генә тәмамланасына өмете дә өзелә барган чагы. Без, мәктәп балалары, парта артына утырып белем туплыйсы урынга, көн дә кырда — башак җыюда. Әниләр — уракта. Әби-бабайлар малсыз калган каралты-кура тирәсендә кайнаша, бакчада бәрәңге казый, юк-бардан ризык җиткереп газаплана.

Көчендәге ир-атлары бер-бер артлы сугыш кырларында сибелеп калып, инде үсмер егетләре дә алар артыннан ук сөйгән кызларын калдырып, билгесез, ерак тарафларга китеп бара. Әткәйне менә сугышка алмадылар. Без кечкенә булсак та, аның яше чыккан икән инде. Ул колхоз умарталарын карый, кичләрен авыл советында каравылда тора.

Олы абыйны сугышка озатуны да бик авыр кичергән әни, аның исәнлегенә дога кылганда да, яткан-торган саен, сез дә кечкенә, инде атагыз исән-сау булсын, дип әйтми калмый.

Мине Харрас абыйның сугышка кадәр яратып йөргән кызы Суфия апа укытасы булып чыкты. Кыр эшләре кимеп, мәктәпкә баргач, безгә беренче көнне үк районнан өр-яңа әлифба алып кайтып тараттылар. Беренче битендә — Ленин, икенчесендә — Сталин рәсеме. Башка битләрен мин әле карарга да өлгермәдем. Шушы ике сурәткә текәлеп, апаның мәктәптә сөйләгән сүзләрен искә төшереп утырам. Бөек юлбашчыларның исемнәрен укый алыр өчен генә дә сез хәреф өйрәнергә тиеш, дигән иде ул. Әтигә әйткәч, көлде, иң элек икмәкле-тозлы булу өчен кирәк ул уку, диде. Аның, дүрт класс белемле хатын-кыз кулына калдыгыз бит, дип, гаҗәпләнгән бер кыяфәттә торуы миңа ошамады. Булачак җиңги турында шулай дип әйтергә ярыймыни?! Ул сиңа җиңгәчәй генә түгел — апа да, беренче укытучым бар кешедән кадерлерәк ул, дип әйтә, ичмаса, әнием.

Апа биргән әлифбаны, гәҗит кәгазенә төреп, яхшы савыт-сабалар гына тезелгән шкафка куйдым да күрше кызы Фәйрүзә янына кереп киттем. Сөйлисе сүз, яңалыклар күп иде. Нинди матур башланган көн бу! Эх, ул да минем кебек мәктәпкә йөри башласа!

Син теләгәнчә буламыни?! Күршеләрдән чыгуыма, энем Зиннур сумкадан карандашларны алган да китаптагы Ленин белән Сталин рәсемнәрен кара кайма белән әйләндергән, күзләреннән чәчәк ясаган, иякләрен сакалга батырган. Укытучы апамнан куркудан, Сталинны, Ленинны кызганудан елап ук җибәрдем. Төсле буяуларны бетерсәң, йә китап бите тишеләчәк, йә эзе калачак иде. Алай иттем, болай иттем, басып-басып ясалган юллардан берничек котыла алмадым. Нишләргә дә белмәгәч, кич җиткәнне көтәргә сабырлыгым җитмичә, эти янына умарталыкка йөгердем.

Әтием иртәләгән: инде кайтып килеше. Ул, гадәттәгечә елмаеп, кулларын җәйгән генә иде, кочагына атыласы, җилкәсенә менеп утырасы урынга, өйдәгедән дә көчлерәк итеп, тагын елап җибәрдем.

Әти эшнең нәрсәдә икәнлеген сораганына үкенерлек кыяфәткә килде. Мин җиткергән яңалыкны ул һичничек көтмәгән иде. Утыртасыз икән сез мине, балалар, дип үзәк өзәрлек итеп әйтте дә, ачу белән мине читкә этеп, янәшә барасы да килмәгән кебек, кызу-кызу атлап тыкрыктан безнең урамга кереп китте.

Мин дә, Зиннурны кыйнап ташламасын дип, елый-елый, әти артыннан чаптым. Инде Сталин белән Ленин, әлифба кайгысы да, иртәгә апабызның моннан да катырак орышасы да онытылды. Энемне яклыйсы килепме, әтинең үзе өчен куркуданмы:

— Әти, Зиннурга тимә яме, тимә! Мин апага, үзем буядым, дип әйтәм! — дип үрсәләнә-үрсәләнә тәкрарларга тотындым.

Әти нигәдер мин көткәнчә эшләмәде. Идәндә бер кайгысыз мәче баласы белән уйнап утырган Зиннурга бармак белән дә чиртмәде. Әлифбаны тотып, агарып, тәрәзә янында утырган әнигә усал караш ташлады да:

— Балаларыңа күз-колак булмыйсың! — дип җикерде.

Инде әлифбаны нишләтер дип көткән идем, тыштан өр-яңа булып, төсле буяулары белән кызыктырып торган китапны хәтта ачып та карамады. Кулындагы йомарланып беткән түбәтәен, безгә селтәнгәндәй, карават башына ыргытты. Ул аның көмеш шарына туп-туры килеп төште дә бераз атынып торганнан соң тынычланып калды.

Өй буенча арлы-бирле йөри торгач, әти дә басылды, йомшады.

— Кызым, бу әлифбаны без хәзергә качырып торыйк, аннан, кирәге чыкмаса, утка ук ягарбыз. Ленин бабаңның да, үзенең дә рәсемен болай бозганнарын белсә, Сталин абыең яратмас, бик нык ачуланыр, мине төрмәгә үк алып китәрләр, — дип кенә әйтте дә китапны нишләргә белми торган әнигә тоттырды.

Дөньяның бу якка үзгәрүен күргәч, әтигә чын-чынлап үпкәләдем. Энемне, әтине бер белмәгән Сталин китап буялган өчен генә төрмәгә утырта димени! Әнә Суфия апага шулай дип әйтеп карасын! Китап, укый-укый, барыбер туза да, буяла да ич!

— Дөньяда Сталиннан да яхшы кеше юк әле ул! Менә мин аңа хат язармын да яңа әлифба сорармын, ә монысы Зиннурга калыр! Син дә аның әйбәт икәнлегенә ышанырсың! — дидем мин әтигә. Ул:

— Юк, кызым, Сталинның бездән башка да эше күптер. Аңа хат язу килешмәс, бу хакта директор апаң белсә, аңа да ошамас, иң элек үзеңә начар булыр, рәхмәт әйтмәсләр. Әйдә, без аны болай гына эшлик. Син, миңа әлифба эләкмәде, дип, директорга барырсың, ә ул икенчесен бирер, — дип, гомер булмаганча, мине ялганга котырта башлады.

Сталинга хат язу бик кызык тоелса да, әти белән карулашмадым, уйладым-уйладым да ризалаштым.

Савыт-сабалар торган шкафның пыяласында газетадан кисеп алынган Сталин рәсеме бар. Әни, пыяланы сөрткәндә, аны ертмаска, әшәкеләтмәскә тырыша, һәрвакыт читкә алып куя. Ак киемдәге Сталин миңа бик ошый. Ул миңа иң кыю, иң батыр солдаттыр сыман тоела.

Ие шул, шушындый сугыш вакытында Сталин өйдә утырамы соң, немечны дөмбәсләп йөри бит инде ул! Минем юаш кына, йомшак кына, ябык кына абыем да сугышка киткәнне! Ә Сталинның гәүдәсе әнә нинди! Мыеклары минем җилкәмә төшеп торган толымчыклар кадәр бар! Күзләре безнең усал әтәчебезнеке кебек үткен! Кирәген бирә инде ул немеч-мимычларның!

Директор апаның авылның икенче башында яшәгәнен белә идем. Әти белән безнең аларда булган бар. Анда барганда бу эшкә ник ризалык биргәнемә үкенсәм дә, Сталин кадәр Сталинның вакытын алмавыма сөенеп, үземне тынычландырдым. Эңгер-меңгер төшеп килгәнгә, үзем белән Акбайны алган идем. Ул ябык. Хәлсез. Алай да миңа ияреп йөрергә ярата. Икәү бергә директорларга килеп җиткәнне сизми дә калганбыз.

Аларның өйләре — авылда иң зур, иң матур өй. Хәдичә апаның ире сугышка кадәр колхозда персидәтел булып эшләгән иде. Киткәнче, яңа капка эшләтеп калдырды, өй каршына карлыган бакчасы утыртты. Капкадан өй ишегенә тактадан салынган юл килә. Бик батыраеп керсәм дә, капкадан узгач, кыюлыкның эзе калмады, ишеккә кадәр кыяр-кыймас кына атладым.

Хәдичә апа өйдә булып чыкты. Ул минем әйткәнемне бераз шикләнебрәк тыңлаган кебек күренгән иде, барыбер ышанган. 28 әлифба кебек иде бит югыйсә, ялгыштым микәнни, дип уйланып торса да, үз кызының өр-яңа, таушалмасын өчен сугышка кадәр кибеттә кәнфит салып бирелә торган кәгазьгә төрелгән әлифбасын чыгарып бирде. Китапның җитмәгәнлеге турында беркемгә ычкындырмаска кушты. Иртәгә районга да барасым бар, Миңсылуга ничек тә табармын әле, диде.

Төн хыялланып узды. Әллә иртәгә тагын уку көне булганга күңел утырмады, әллә әлифба бозылу вакыйгасы тынычлыгымны алган иде. Сугыш беткәч, әлеге хәлләр хакында ничек итеп Сталинга язачагым, аңа матур әлифбалар чыгарганы өчен рәхмәт әйтәчәгем, ничә фашистны кырганлыгы турында сораячагым турында уйландым. Иртәгә нинди дәресләр булыр, ни сөйләрләр, дип баш ваттым.

Икенче көнне безне директор апа укытты. Суфия апагыз үз теләге белән сугышка китте, дип белдерде ул. Сәерсенсәк тә ышандык. Сугыш адәм баласының кемлеген ача дип уйлый идем, ялгышмаганмын, диде әти.

Кечкенә генә, матур гына апабызның авыр автомат күтәреп кырлар буйлап йөгерүен, ут астына керүен күз алдына китерү миңа бик авыр иде, шуңамы ул минем төшкә барыбер гел әлифба тотып кына керде.

Шул вакыттан соң әти эчендә ниндидер сер йоткан шикелле булып калды. Абыемның яраткан кызы сугышка киткәнне өнәмәдеме ул, аның исәнлеге өчен кайгырдымы — әйтмәде. Еллар үткәч кенә, мин аның әлифба югалуда гаепләнүен, җавап биргәнче дип, директор белән киңәшеп, сугышка китеп котылуын аңладым.

Суфия апа биргән әлифбаны без утка якмадык. Бала кылган гамәлдә аның гөнаһы юк бит инде, диде дә әни, аны бик тирәнгә — кышкы киемнәр салынган сандыкның иң төбенә яшереп куйды.

*2004*

## Соңлап аткан мылтык

«Эленеп торса да, мылтык бер шартлый», дигәннәре хак икән. Габделвәлинең мылтыгы көтмәгәндә шартлады. Аны кышкы буранлы төннәрнең берсендә, хатыны, балалары белән хушлашырга да рөхсәт бирмичә, кара машинага утыртып алып киттеләр. Киттеләр, әмма таңда ук кыйналган, күзләре кызарган ирне кире алып та кайттылар. Ул туп-туры пөхтәләп чүпрәккә төрелгән мылтык саклаган түргә кереп кит-

те. Хатыны Халисә артыннан барыйм дип ишеккә ташланган иде, алгы катның як-ягына баскан солдатларның берсе үз мылтыгының сабы белән генә аны бик саксыз читкә этәрде.

Габделвәли түр бүлмәдән ашыкмыйча гына, мылтыкны чүпрәгеннән сөтә-сөтә, йокысыннан уянган баласын кочаклаган хатынына карый-карый гына чыкты. Тешләрен кысып, соңгы сүзен әйтми калдырырга теләгәндәй, ишеккә таба атлады, аннан тукталгандай итте һәм әкрен генә баш какты. Халисә, сүзләр әйтелмәсә дә, бу баш селкүнең мәңгегә хушлашу икәнлеген Габделвәлинең кара көйгән күзләреннән аңлады. Аңлады, тик үкереп еларга тотынмады. Баласы башыннан тартып төшергән яулык почмагын тешләп тораташ каткан кебек карап калды.

Ир-атлар ишекне ябып чыгып киткәннән соң минут та үтмәгәндер, ишегалдында ату тавышы яңгырады.

— Ходаем, әллә атылып үлдеме?! — дип, Халисә тәрәзәгә капланды, тик алай булып чыкмады. Габделвәлине өркетер өченме, шул куркуны башкаларга да салырга теләпме, солдатларның берсе һавага аткан икән. Габделвәлинең мылтыгы инде аларда, үзе, бөкрәеп, машинаның арт ишегеннән кереп бара иде.

Икенче бер чакта эт өрсә дә йөгереп керә торган күршеләр дә, шушы ук урам башында яшәүче туган-тумача да күренмәде. Авылда төннәрен болай алып китүләр инде беткән кебек бер заманда таныш-белешләрнең сагаюы Халисәне аптыраушта калдырды. Ә бит ул Габделвәлигә әйткән иде, бу мылтык башыңа бер җитә әле, дип кисәткән иде.

...Сабының буяулары да бүген сыланган кебек ялтырап торган мылтыкны Габделвәли сугыштан алып кайтты. Кемлеген күрсеннәр, мәктәптә дәрес биргәндә кирәге дә чыгар, янәсе. Ул Өркеттә физкультура дәресләре укыта һәм әле фронтка киткәнче малайларны сугыш һөнәренә өйрәтеп тә азапланган иде. Үзләре ясаган агач мылтыкларны, автоматларны күтәреп, тау араларында да йөрделәр, урман эчләренә дә качтылар, окоплар да казыдылар, тик менә, күрсәтмә әсбап булмагач, ни үзебезнең, ни немец техникасын нык-лап өйрәтә алмады. Сугыштан, һичшиксез, ганимәт мал белән кайтам, дигән иде, сүзендә торды, беренче дәрескә үк дошман тылына соңгы разведканы ясаганда кулына төшергән мылтык белән кайтты.

Габделвәли тел алуга барганда үзе дә каты яраланды, әмма ләкин исән-сау булганга күңеле шат иде. Егет сугыштан кайтуга ук өйләнеп җибәрде, икенче елда баласы да туды. Солдаткалар гына диярлек көн иткән авылда иң бәхетле гаилә булып яшәп тә киттеләр.

Габделвәли сугышка кадәр Өркет мәктәбендә директор булып эшләде. Ул кайту яшь директор кызның күңеленә сары май булып ятмады. Иртәгә-бүген эшеңнән аласыларын көт тә тор, дип уйлады ул. Укытучының ачык дәресенә кереп утырып, балаларның абыйларын яратуларын, һәр сөйләгәнен авыз суларын корытып тыңлап утыруларын күргәч, ул үзенә чын куркынычның киләчәктә әллә кайтачак, әллә кайтмаячак егетләр ягыннан булмыйча, шушы институт бетергән тәҗрибәле укытучыдан — карт солдаттан янаганын тәмам аңлады.

Җиде сыйныфлык кына белеме булса да, дүрт класс тәмамлап кына укытканнардан ул үзе дә шактый аерылып тора. Авылда дәрәҗәсе дә юк түгел, һәркем әллә кайдан баш иеп исәнләшә, юлда очраганы арбасына утыртмыйча үтми, утыны яздан ук китертелгән, бакчасы кешенекеннән алда казылган булыр. Өстендә — шәп кием, аягында — заманына күрә затлы туфлиләр. Инде ул башкалар рәтендә йөрүне, аннан да битәр иртәдән кичкә чаклы колхоз кырларында бил бөгүне башына да китерергә теләми һәм ничек тә шушы урында мәңге калырга тырышачак.

Сугыштан контужен булып кайткан авыл советы Хәләф белән дә серләре килешкәч, Хөршидәнең бәясе бермә-бер артты. Тегендә-монда юлласы язуларын да аннан яздырттылар, киңәшкә дә аңа чаптылар. Инде Габделвәли кайткач, шул дәрәҗәдә бераз кимеп киткән кебек тоелды.

Хәләф тә Хөршидә кебегрәк фикер йөртә һәм сөйгәненең гади укытучы булып калуыннан бер дә риза булмаячак икән. Төн кордылар планны, көн кордылар, һич кенә дә Габделвәлидән котылу юлларының кулаен таба алмадылар, әмма озакламый җай да чыкты. Габделвәлинең мылтык белән кайтуы сәгате-минуты белән бөтен авылга таралса да, моның үз файдасына икәнлеге Хөршидәнең башына шул вакытта ук килмәде.

Директор кергән ачык дәрестә бер укучы:

— Абый, сугыштан трофей алып кайтырга ярыймыни? — дип сорагач, солдат аптырапмы, куркыпмы калган сымаграк күренгән иде.

Чыннан да, ярыймы, дип уйланды Хөршидә. Әгәр ярамаса? Әгәр ярамаса... бик яхшы! Дошманнарга төбәлгән мылтыгы бик шәпләп Габделвәлинең үзенә атачак! Ул башына килгән фикерне тиз арада түкмичәчми Хәләфенә җиткерде. Уйлаштылар-уйлаштылар да Габделвәлидән ничек тә котылырга булдылар. Ипләп кенә әнә шул турыда райком секретареның үзенә хәбәр иттеләр. Ул мондый четрекле мәсьәләне җиңел генә хәл итә алмадымы, бу хакта гариза язып, өч кешедән кул куйдыртып, беркемгә сиздермичә генә, ЧКга хәбәр салырга киңәш итте. Шулай иттеләр дә.

Өченче кешене ничек юлларга дип торалар иде, анысын да тиз таптылар. Кызының таныкнамәсендәге бердәнбер дүртлесен бишлегә үзгәртеп язган иде, Халидә кулны күршесе Сабирдан куйдыртты.

...Беркемгә сөйләнмәгән булса да, авыл халкы Габделвәли югалуның сәбәбенә дә, бу эшкә гаеплеләрнең кем икәнлегенә дә тиз төшенде. Инде кире әйләнеп тә кайтмагач, укытучы башына әлеге дә баягы мылтыкның җиткәнлеге бик ачык аңлашылды.

Габделвәли суга төшкән кебек юкка чыкты. Аннан хәбәр дә булмады, хатлар инде килмәде дә килмәде. Ул арада баласы да үсеп аякка басты, хатыны Халисә, күрше авылның карт кына бер кешесенә кияүгә чыгып, икенче оясын корды.

...1958 елның язында авыл капкасы янына бер машина килеп туктады. Аннан затлы күн пальтодагы бер ир-ат төште. Кулында — яхшы саквояж. Башында — кара эшләпә. Килгән машинасы очраклы гына иде булса кирәк, ничек тузан туздырып туктаса, шулай ук хутлы гына китеп тә барды.

Мосафир читән кырында каз бибиләре саклап утырган Бибигөл карчык белән дә, йорт нигезенә утырып гәүдә җылыткан Халиулла белән дә елмаеп исәнләште, әмма туктап, сөйләшеп тормады. Ашыкканы, бер-бер эш белән генә килгәнлеге күренеп тора иде, алай да Күпбеләм Харис яныннан җиңел генә үтә алмады.

Каравыл йорты алдында тезелешеп утырган бала-чагадан аерылып, Харис кунакның алдына чыгып басты.

— Бәрәч! Син түгелме соң бу, Габделвәли?

— Булсам...

— Булсаң. Менә шул. Исәнләшик. Ни эшләр бетереп йөрисең? Сөйләшик. Әле дә ярый исән икәнсең!

— Исә-ә-н... — диде Габделвәли, сузып кына. — Сизәм, сез җиргә дә күмеп куйгансыз... Миңа үләргә ярыймыни?! Биргән нәзерем үтәлмәгән килеш. Менә кайттым. Инде тагын алып китмәсләр! Андый чаклар үткән! Үз аягым белән китәрмен. Малайны, хатынны гына күрим дә.

— Хатының — күрше авылда. Анда бару ярамас. Малаең да — җиткән егет инде. Тач үзең! Белмим тагын, күрергә дип ныклап кайткан булгач. Узганны кайтара алмассың да алуын.

Габделвәли дәшмәде. Кесәсеннән портсигар чыгарып, тәмәке алды, берсен Хариска да сузды.

— Күрәм дигәч күрәм! Күрше авылга икән — күрше авылга! Аларга үпкә белән йөрмим лә мин. Ә менә кайберәүләргә... —Габделвәли теш арасыннан гына чертләтеп җиргә төкерде. — Кайберәүләрнең битенә төкерми ярамас! Кан төкергәндә дә, авызда саклаган өч тамчы төкерекне ияләренә тапшырам дип, никадәр ара үттем мин! Себер урманнарыннан исән кайттым! Донбасс шахталарының астында калам дигәндә дә, Ходай коткарды мине. Кайберәүләрнең битләренә төкерер өчен яшәлгән гомер иде бит ул!

Күпбеләм Харис төк баскан ияген сыпыргалап, тамак кыргалап тыңлап торды да:

— Соң! Анысы — синең эш! — дип куйды. — Без нәрсә... Булган-беткән дип яшибез шунда. Беркемгә рәнҗеш сакламыйбыз. Кешенекенә тимибез, үзебезнекен бирмибез. Бездә дә бар инде ул андый гына...

— Уналты елыңны читтә каңгырып уздырсаң, болай сөйләнмәс идең дә сөйләнүен. Әйттем — бетте! Йә, күрешмәсәк, бәхилләшик.

Харис аның сүзен гаепкә алмады. Габделвәлигә авыр эш эшләп җәелгән көрәк кадәр кулларын чын күңелдән сузды:

— Бәхилләшик. Безгә кереп, чәйләп утырсак, гәпләшер идек тә. Ашыканга охшыйсың. Ярый, исән-сау йөр. Үзебез турында сөйләп, сине шаккатырып булмас. Барысын да белеп яшәгәнгә охшагансың.

Әле төш вакыты җитеп кенә килә иде. Габделвәли туп-туры мәктәпкә таба атлады. Ишеген каерып ачып — коридорга, аннан директор бүлмәсенә таба атлады.

Директор дәрестә икән. Апаларының кызып-кызып тема аңлаткан вакытында, рөхсәт тә сорамыйча, ишектән кергән һәм чартлатып битенә төкергән ир-атны күрүдән балалар телсез калгандай булды. Хөршидә кызарды-бүртенде, нидер әйтергә теләгәндәй булды, кулыннан акбуры төшеп китте, тик берни дә дәшә алмады. Усаллык белән чәпәлгән кайнар төкерек күзеннән агып төшкән яшь белән бергә буталды да, йөзен ямьсезләтеп, иягенә таба тәгәрәде.

Габделвәлинең кайтканлыгын, нигә кайтканлыгын каравылчы бөтен авылга таратып өлгергән иде инде. Шул сәгатьтә үк Хәләф белән Сабир, эш тапкан булып, районга чыгып качтылар.

Габделвәли, мәктәптән чыккач, зиратка таба атлады. Атасы белән анасының ташландык кабере янына утырып тын алды. Нигезе беткән, гаиләсе таркалган, туганнары кайсы кая таралышкан. Авылда шушы ике караучысыз калган кабердән башка берние юк.

Ул быел гына җимерелеп төшкәнлеге күренеп торган чардуганның черек такталарын койма кырына чыгарды, кабер өсләрен чүп-чардан арындырды.

Сугышка китәр алдыннан утырткан зирекләр инде биек булып үскәннәр, матур яшелләнгәннәр. Башларында карга оялары юк.

Кайчандыр ясаган утыргыч та искергән, шулай да чыдатырлык икән. Габделвәли, ялгызы гына утырып, дөнья гаме, бала чагы, сугыш, гаиләсе, лагерьда үткән тормышы турында уйланды. Зират эчендәге йорттан ак сакаллы бер карт килеп чыкты. Үлем-җитем юкта, читтән кайтучы күренмәгәндә, эш өстендә, көндезләрен зиратны бимазалап йөрүчеләр булмаганга, утыргычтагы адәмнең кемлеген беләсе килде, ахрысы — туп-туры аңа таба юнәлде.

— Улым, быел әле каберлек каралмаган. Чүп-чарга баткан дип аптырама. Мәктәп балалары бу шимбә төзәтерләр, тазартырлар инде, — диде ул, аның янына килеп утыргач. — Үзең кем соң? Ата-анаң кем? Монда тукталгач, Габделсаттар малае дисәм, аны инде киткән җиреннән юкка чыккан, диделәр. Вәйт бит дөнья нишләтә! Нинди әйбәт кешенең дә башына җитә, ә?!

Габделвәли күзләре начар күргәнгә охшаган бу картны таныды. Авылның кайчандыр үзе дә Себергә сөрелгән мулласы Хәсәнгата иде ул. Менә бит кайткан, исән калган! Каберлек турында да кайгырта икән. Шулай да аңа кемлеген әйтергә ашыкмады. Сүзен хәл белешүдән башлады:

— Хәсәнгата абзый, хәлләр ничек соң? Яшәүләр...

— Алланың биргәненә шөкер. Авыл кешеләре ярдәменнән ташламый. Карчык белән яшәп ятабыз чөкердәшеп. Исәннәргә — озын гомер, үлгәннәргә җан тынычлыгы теләп. Бу кабер ияләрен дә догадан калдырган юк. Баласын да искә алам. Рухы шат булсын, кеше хөсетлеге белән дөньядан киттем, дип рәнҗеп ятмасын, дим. Кем хаталанмый? Заманы нинди иде бит... Гөнаһларыбызны бер Алла гына белә, җәзасын да ул бирер, барыбызны да гафу кыла күрсен инде.

Габделвәлинең бу сүзләрдән башы томалангандай булды, күз аллары караңгыланды. Шул ук Хәләфләр этлеге аркасында үзе дә көнен көнгә көчкә ялгаган бу картның, байлар белән бергәттән сөрелеп, олауда ерак Себер якларына озатылганлыгын күз алдына китерде. Басу капкасы янында хушлашырга килүчеләр арасында Габделвәли дә бар иде. Нигә якламаган ул аны? Нигә бер сүз дә дәшмәгән? Шулай булгач, вәхшигә әйләнә башлаган авылда аның үзен яклап кем сүз әйтсен? Аны эзләтерлек, аны аклатырлык хатлар язарга ике башлылар яшәгәнмени ул чакта?!

Кемнәр яши бу авылда хәзер? Шул ук Хөршидәләр, Хәләфләр, Сабирлар... Иртәгә кемнәр яшәр? Әтисе кабере янында үзенә дип калдырган бушлыкка кем күмелер? Аның кабере кайда булыр? Калган төкерекне эчкә йотаргамы, барысын да оныткан кебек, җиргә төкереп ташларгамы, әллә ияләренә илтергә дә яңа, тыныч тормыш белән яшәргәме? Әгәр шуның белән генә тынычлансаң... Әгәр тынычланмасаң?

Габделвәли, изге күңелле карт сөйләгәндә, үз уенда булды диярлек, әмма бер карарга да килә алмады. Каберлектән китәргә уйлап кузгалгач, ул кесәсеннән берничә кәгазь акча чыгарып картка сузды.

— Монысын әтием Габделсаттар белән әнием Маһисәрвәр ризалыгы өчен багышларсың, монысына каберләрен карап торырсың, боларын улым Раухатка бирерсең, бу урынга башка берәүне дә күммәгез, үзем кайтам...

Хәсәнгата карт телсез калды. Садакачы киткәнче, бергәләп дога кылырга кирәклеген дә онытты. Бер — ашыга-ашыга зираттан чыгып баручы Габделвәлигә, бер — кулында дерелдәгән акчаларга карады.

...Каберлекләр арасыннан узганда, Габделвәли аяк астында аунап яткан корыган ботакка абына язды. Иелеп алды. Ботак шактый юан иде. Габделвәли, бөтен көчен җыеп, гасырлар буе яткан каберләрнең тынлыгын җимереп, ботакны урталай сындырды. Якындагы агачларга кунаклаган кошлар, мылтык тавышын ишеткәндәй, дәррәү күккә күтәрелделәр. Баш очында әйләнеп очкандай иттеләр дә, куркыныч юклыгын белгәч, тынычланып, кире үз урыннарына кунакладылар.

Габделвәли үзен алар кебек хис итә алмады. Гомере читтә — читлектә узган ир, шул читлек ачылып, канат җилпеп очканнан соң да, җанына кадерле булган урынга куна алмады. Ул кайчандыр канат очларын кискән авылдашлары янына кайтырга, алар арасында яшәп китәргә әзер түгел иде. Аның күңел түренә эленгән мылтык соңгы тапкыр аткан кебек булса да, соңлап атуның мәгънәсе калмагандай тоелды.

Беркемгә тукталмыйча, чәй дә эчеп алмыйча, авылдан китеп барганда, Габделвәли электә еш кына авыз эченә җыелгандай тойган төкерекне дә, шул ук вакытта җанына иңгән җиңеллекне дә сизмәде. Бу авылны яратып кайту өчен аңа тагын берничә генә ел булса да гомер кирәклеген аңлады. Борылып, кайтырбыз әле дигәндәй, һаман да читән буенда бибиләр саклаган карчыкка кул болгады.

*2004*

## Аромотерапия

— Сезгә, һичшиксез, аромотерапия сеанслары алырга кирәк. Нервыларыгыз бик тә какшаганга җыелган инде бу авыруларыгыз, — диде санаторий табибы, алып килгән хасталык тарихымны тегеләй-болай

әйләндергән булып. Алай бер-бер кәефсезлек кичергән чагым түгел дә түгелен. Алырга икән алырга! Кошлар җыры, көй астында хуш ис белән дәвалауның ни икәнен үзеңдә сынаудан зарар булмас.

Аромотерапиягә бөтен кешене дә язалар, ахрысы, файдасы зур инде, алай булгач, зур. Таяк тоткан әбиләргә кадәр, этешә-төртешә, чиратсыз үтәргә азапланмас иде. Ишек төбендә үк торуымнан файдаланып, хуш испең нәкъ тарала торган җиренә — түр кәнәфигә кереп утырдым. Монда кошлар җырына да якынрак, гел керә торучылар да борчымый. Ул да булмады, мин белмәгән әллә нинди кошлар, бер-берсен уза-уза, сайрарга да керештеләр.

Гәүдәмә уңай бер рәвеш алгач, кичерәсе рәхәтлекләргә әзерлегемне белдереп, күзләрем дә йомылдылар. Керә-керешкә дигәндәй, күрше утыргычтагы абзый гырлап йокыга ук киткән икән, бераздан янындагы хатынының аның касыгына төрткәне аңлашылды:

— Габделхәй, кеше көлдереп, монда да гел йоклап утырма инде, бераз нервыларың тынычланыр, кош җырлаганын тыңла әнә!

— Авылда тыңламаган кошмы?! — Абзый аның ягына таба борылыбрак утырды булса кирәк, шактый авыр терсәге минем баш түбәмә ял итәргә чамалап кунган иде, әллә нинди бер тупаслык белән аны эттем дә төшердем.

Урынымны тагын җайладым, тагын рәхәтлек дөньясына чумарга хәзерләндем.

Хыялдагы ялны мин бала чагымнан башларга булдым. Җәйләрем Ерак әбиемнәрдә узгангадыр инде, шунда ук күз алдыма алар авылының каршы як урманында кура җиләге җыеп йөргәннәрем килде. Башта — чөеп бәйләгән косынка. Өстемдә — чуар кофта. Кулымда — зәп-зәңгәр чиләкләр. Туганнар, дус кызлар белән куралыкка кереп барабыз, имеш.

Менә төрлебез төрле якка таралыштык, мин, башкалардан алгарак китеп, иң эре җиләкләр үскән бер җиргә тукталдым. Ул җиләкләрнең сусыллыгы, кызыллыгы, муллыгы! Баш өстеннән карап торган кояш эссесенә дә чыдарга хәл җитсә... Җиләк җыймаган кызмы без?! Уч тутырып салган җиләкләрдән зәңгәр чиләкләрем чөмәкәй тулды дигәндә генә, абайламыйча, кара еланга баскан күк тидем дә, ул-бу булганчы дип, бөтен урманга шар ярып, алны-артны күрми чабарга тотындым. Урман кырына җиткәч кенә аңладым: елан мине куа барырга уйламаган да, ә мин тиле... йөгерәм дә йөгерәм икән. Их, кулымнан төшеп калган чиләкләремдә җиләк тә яртылаш кынадыр. Кош тавышын тыңлый-тыңлый, биттән аккан яшьне сөртә-сөртә, кирегә — куаклыкка киттем.

Бер түгелгән чиләкне тагын тиз генә тутырам димә. Җиләкнең яңа пешкәненең дә хәлсез чагы. Күбесе кипкән, куырылган. Бөрешә башлаганнары, көн эссесеннән качып, яфрак асларына елышкан. Инде яфракларда да иртәнге сусыллык, җетелек, шәплек юк.

Чиләкләрне кабат тутырганчы, шактый вакыт узды, алай да башкалар күренми иде әле. Алар килгәнче, бераз ятып ял итеп алыйм, дип, бер агач төбендәге хәтфә үләнгә сузылып яттым. Әллә нишләгән бу кошлар, кояш төшлекне үтте дә димиләр, сайрыйлар да сайрыйлар. Кайдадыр якында гына чишмә дә агып тора шикелле. Аю гына, бүре генә аваз чыгармый инде! Калган барысы урманга җыелган диярсең.

Шул илаһиятне бозып, ниндидер ят кешеләрнең сөйләшкәне ишетелде. Күзне ачсам: өстемә берничә кеше иелгән. Берсе, аптыраган сыманрак, икенчесеннән:

— Чья же она дочь? — дип, урысчалатып сорап тора. Кот тәмам ботка төште. Кабат йокыга киткәнгә салышып, күзне йомдым.

— Не из нашенских, — диде усалрак ирләр тавышы.

Бабамның, ул як урманга эчкә кермәгез, анысы безнең җирләр түгел — урысларныкы дигәне бар иде, шунлыктан бик-бик курыксам да, күзне кысык кына ачып,ерактарак торган берсенә карадым да, бернигә ис китмәгәндәй:

— Я — гостья, — дигән булдым. Таныш түгел кешеләр, кем икәнлегем, кемгә кайтканлыгым турында бәхәсләшә-бәхәсләшә, урман куелыгына кереп югалдылар. Ул да булмады, Туган абыем да күренде, аның белән әкрен генә авылга юл тоттык.

Ачыгып, арып капкабыздан кергәндә, бабамның кояшның сүрән чагында печәнгә барырга дип әзерләнүе иде. Ул кедалар эчендә калачак чолгауларын тыгызлый-тыгызлый тарта. Үзе, сөенеп, тум-тулы чиләкләребезгә караган.

Кайдан килә соң авылда да шул ук кошлар тавышы?! Юк, тукталдылар. Баш очыннан гына козгын кычкырып узды. Бу тавыш күңелдән тын гына аккан моңга ят, өшеткеч иде.

Бабам, күзләрен мут елтыратып, тум-тулы чиләкләремне күтәреп үлчәгәндәй итте дә:

— И минем тәти кызым, никадәрле җыйган бит бабасына! — дип, башымнан сыпырды.

Кинәт мине яраткан бабамның юклыгыннан, бу сурәтләрнең хыялда гына терелгәнлегеннән бик тә авыр булып китте. Юкка кычкырмаган бит козгыннар! Үкереп еламас өчен, иреннәремне тешләдем. Юк,

еларга ярамас. Тынычланырга кирәк. Әле бабам да, әбием дә, әниемнең әбисе дә... — барысы да исән көннәр ләбаса! Үзебезнең болыннарда гына йөргән булсамчы!

Кошлар җыры, бакалар бакылдавы, дулкыннар чыпырдавы мине Изелгә — Нократның аргы як аланнарына алып китә. Без, миннән бер-ике яшькә өлкән Расим белән, мыжгыган бака оясыннан — тымызык күлдән төнбоеклар җыябыз. Ул күлгә иелеп төшкән талларга асылына да суның нәкъ уртасына сикерә, иң матур, иң күпергән сап-сары төнбоекларны гына өзеп алып миңа ыргыта. Алтын чәчәк диләр аларны бездә.

Бу тирәдәге күлләрдә төнбоекларның алтыннары гына. Бик матурлар да үзләре, ә минем акларын — мәхәббәт чәчәкләрен җыясым килә... Ераккарак барырга, шуңа олылардан рөхсәт сораргамы әллә?

Расим белән җитәкләшеп алабыз да Тирән күл янындагы шалашы каршысында чалгы кайрап утырган әтиемә таба юнәләбез. Чаж-чож килеп ут уйната аның кулындагы кайраклар. Ул печәннәрнең каерылып үскәнлегеннән бәхетле елмая. Кыяк үләннәрне дә эх тә итмичә кисә ул кайраган чалгылар! Нинди бетмәгән моңсу музыка бу?! Ярый әле аны печәнчеләрнең болын ерып килгән тавышлары бүлә.

— Кайда йөрисең син, сагынып беттем үзеңне! Мондагы күлләр бик тирән, сак булыгыз, — ди әтием, йомшак кына. Мин аның янына килеп утырам. Ул чалгы-кайракларын бер читкә куя да яратып аркамнан сөя.

Шунда аның инде юклыгы, ятимлек елларым искә төшә, тамакка тагын төер утыра, күзгә яшь бөялә, мин әти утырган шалаш яныннан еракка — яшьлеккә таба, мине яраткан, әтисез калган гомеремдә үзе белән җитәкләп алып киткән икенче егеткә таба йөгерәм.

...Без аның белән ак каеннар шаулап үскән тау итәгендә күккә карап ятабыз. Тау астында җидегән чишмә ага. Арчада чишмәләр күп булса да, тәмле сулылары бу калкулык астында гына. Мәхәббәт тавы ла бу!

Күктә ап-ак болытлар йөзә. Каеннар ботагында кошлар бихисап. Алар безгә бәхет, пар гомер теләп сайрыйлардыр шикелле. Ул мине үзенә таба әйләндерә дә ныклы кочагына ала:

— Минеке бул, матурым!

— Иртә шул әле, — дигән булам. — Әле укыйсы да укыйсы! Әнине дә ялгыз яшәтәсе килми.

— Без бит аңа икәү булачакбыз! — ди мине үлеп сөйгән чибәр егет.

Ул мине — үпмәкче. Бу миңа әрсезлек, бозыклык кебек тоела. Кошлардан, чишмә тавышларыннан оялмыйча! Күзгә карап торган кояш астында диген?! Аннан ычкынам да каеннар арасына кереп югалам.

Ул көлә. Нигә көлә ул? Туктале, безнең барыбер дә аерылышуыбызны белеп көлгән мәллә ул чакта? Кирегә борылып, аңа таба йөгермәкче булам. Каеннар арасында инде ул үзе юк. Еларгамы миңа, көләргәме? Йөрәгем ярылганчы баш очыннан аккан болытларга аны ратуым хакында кычкырыргамы? Әллә, бу кадерле урыннарны онытыр өчен, күземне генә ачаргамы?

...Каен төбендәге түмгәккә килеп утырам. Югалткан кешеләрем бер-бер артлы тезелеп күз каршымнан узалар. Алар арасында әти, бабам, әби... Сәер, исән булса да, Ул да бар! Сеанс бүлмәсендәге кәнәфидән сикереп торганны да сизми калам.

Җыелган яшьне тыя алмыйм, кычкырып еламасам да, бит буйлап яшь агызып, ишеккә таба атлыйм. Күршеләремнең барысының да күзләре йомык. Кайсы йокыга ук киткән, ахрысы. Аларның күрмәве яхшы... Мин аларга бу сагышны теләмим. Моңсу музыка аркамнан сыпыра. Кошларның сайравы бер көлү булып ишетелә. Кайдандыр кубарылган карга төркеменең тавышлары ул көлүне каһкаһәгә әверелдерә.

Яшьне сөртә-сөртә ишектән чыгуыма аптыраган шәфкать туташы:

— Ни булды? — дип сорый.

— Билем кузгалды. Утыруның җаен тапмыйм, — дим мин, сулкылдый-сулкылдый.

— Ну во-о-от... — ди ул, гаҗәпләнеп. — Сидели бы еще, может быть, музыка вылечила. Все болезни ведь из-за нервов. Вам не надо плакать, нужно успокоиться. Пенье птиц как раз успокаивает, а хвойный запах нервы укрепляет. Может вернетесь?

Юк, кирәкми, аромотерапиягез генә кирәкми. Иҗат йортындагы бүлмәгә керү белән, караватыма капланам. Монда рәхәтләнеп еларга була. Монда тыныч, монда кошлар сайрамый, монда, бәла хәбәр иткәндәй, козгыннар кычкырмый. Монда минем белән бүгенгем яши.

*2006*

## КЫЙССАЛАР

### Тауның башын болыт кисә

Үзебез яшәгән җир куышы төбендә искереп беткән сандалиемның табанын сумалалы җеп белән тегеп утырам. Ташлар идең, мәктәпкә барыр вакыт җитеп килә, яңасы әле буламы-юкмы. Рәткә китереп, шушы иске сандалилар белән тагын бер кыш мәктәп идәнен кырып уздыруыңны көт тә тор... Әле язга чыккач та, ни булыр... Минем кебек тугызынчыга баручы егетләр аларны күптән күн ботинкаларга алмаштырып бетерде инде. Авыррак тормышлыларның да аягында кытай кедасы.

Кояш баеганда, карлыгач оялары тирәсендә бөтерелгән, кырдан бер-бер артлы карга көтүләре кайткан эңгер-меңгердә, шушы яр астыннан авылыбызга карап утырырга яратам мин. Көн буе һәр җан иясен әлсерәткән кояш, инде үзе дә арып, кайчандыр мин яшәгән йортның нәкъ урта тәрәзәсенә кереп югаладыр шикелле. Аның утлы кызыл шәүләсе саргылт такта белән тышлаган өебезне тагын да сихриләтеп, серләндереп җибәрә. Бик нык курыксам да, минем шул өйгә керәсем, әтиемнең анда ничек яшәгәнен күрәсем килә. Тик әнине үпкәләтермен дип уйлыйм да батырчылык итмим. Хуш исле печән түшәгебезгә яткан-да, ул муенымда кыршау сыман торган кутәренке сырга карап:

— И-и-и балам, ярый исән калдың бит шул мөртәттән, — дип сөенә. Аның мөртәт дигәне — җирән башлы, тук корсаклы, акай күзле әтием. Килбәтсез-әлкәш кыяфәтле булса да, элек һәр иртәне йокымнан төрткәләп уятса да, минем аңа мөртәт дияргә телем бармый. Каты кулларыннан миннән дә күбрәк кыен ашаган әнигә дә каршы төшәргә теләмим. Әти әти инде ул. Шушы иске сандалиларны ташлап, яланаяк йөрергә, һич югы юкәдән үргән чабата кияргә, йә инде бөтенләй мәктәпкә дә бармаска була, ә менә әтине алмаштырып булмый...

— Берәрсенә өйләнсә, без дә тынычта яшәр идек, — ди әнием, уфтанып.

Шушы салкын, дымлы, эт куышы кебек землянкада тыныч яшәп буламыни инде?! Аның «тыныч»ы әтиебезнең, вакыт-вакыт тау астына төшеп, безгә «акыл өйрәтеп китүе»ннән котылыр идек дигәнне аңлата.

Өстемдә кырык ямаулы кием, тамак ач булгач, мин авыл малайлары янына уйнарга барырга да базмыйм. Хәер, уеннарын онытып, алар инде күптән кызлар артыннан чабадыр. Беләсе иде, минем Разиләмне кайсы да булса озата микән?

Баеган чагында кояш алар тәрәзәсенә дә бер уч ут яктысы ташлый. Разиләләрнең өе безнекеннән зуррак, биегрәк. Урам якка караган түбә очында «сандугач оясы» бар. Разилә шулай ди. Сандугачларның өй тирәсенә ояламаганын каян белсен ди ул! Бөтен сандугач безнең янда — тау астындагы таллыктадыр шикелле тоела миңа.

Разилә яраткан сандугачларның исәрләнеп сайраганын тыңлап, аның турында уйлап, хыялланып утырам.

Разиләләр өе дигәннән, ярый әле безнең урам бер яклы гына. Тәрәзәләре монда таба да — бәрәңге бакчасы ягына да караган. Безнең куышыбыз каршы яктагы тау итәгеннән шул тәрәзәләргә ишек ачып утыра.

Мин агач төбендә, телемне чыгарып, мыш-мыш килеп, күгәргән инә белән табан тегәм. Инә бер яктан икенчесенә чыккан саен, күтәрелеп, авыл урамына карыйм. Разилә үзләренең «сандугач оялы» түбәләренә менеп баскан да миңа кызыл яулыгын болгый. Бу — әтиләр эшкә китте, безгә мен, чәй эчәрбез, дигәнне аңлата. Разиләләрнең әтиләре сарык фермасында эшләгәнгә, аларга ял көне юк.

Күршеләре күрмәсен дип, мин бәрәңге буразналары арасыннан шуыша-шуыша менәм. Күлмәк-ыштанны тәмам балчыкка буяп бетерәм. Минем шулай эшләвемә Разилә гел дә гаҗәпләнә. Син кеше шикелле генә кыланмассың инде, дигән була.

Алар өендә чәйне бөтнек, мәтрүшкә салып эчмиләр. Андый чәйдән мин үзебезнең тау куышында эчеп тә туйган инде. Монда һинд чәе, ак май, гәрәбәләнеп торган бал...

Разилә каядыр китеп, югалып торганга, минем өч көн буена авызга бер кашык пешкән ризык капкан, болай итеп тәмләп чәй эчкән юк. Әнинең бөтен эшләгәне — әтигә, ул кешеләрдән сораттырган бурычны түләүгә китеп бара.

Ындыр табагындагы көшелләргә, инде эчләрем авыртып бетсә дә, әйләнәм дә киләм, әйләнәм дә киләм. Без, ягъни берничә авыл агае белән мин, шуның янында гына келәтләр төзәтү эшендә.

Бүген ял. Тәннең арыганлыгы, йокысызлык аеруча шушы көнне сиздерә.

Разилә чәйне үзе яраткан пар зәңгәр чынаякларга ясый. Нәрсәнедер ничек итеп әйтергә белми торганлыгы чәй агызганда җиңелчә генә дерелдәгән кулыннан ук күренә.

— Мансур, мин бит китәм, Арчага китәм. Укырга... Инде... фатир... эзләп кайттык, — ди ул миңа береаздан.

Кулымдагы баллары тамып торган калак идәнгә тәгәри.

Разилә китә. Минем бердәнбер дустым. Нигә китә? Шушы тәмле һинд чәен, җылы өйне, йомшак түшәкләрне калдырыпмы?

Идәндәге бал калагын Разилә, иелеп, үзе ала. Шул урынны юеш чүпрәк белән сөртә-сөртә:

— И юләр, мин бит кайтмаска китмим, — ди. — Синең инде кашларың өем болытлар булып ук җыерылды.

— Китмә, Разилә. Мин персидәтелдән киләсе елга көтү көтәргә рөхсәт алдым. Шулчак туләрсең, дип, бераз акча да биреп тормакчы. Гөлбикәттәйләрнең иске өен җыештырып күчмәкче әле без. Җәй эшләгәннәргә дә бераз бирсәләр... Пәлтә-мазар, итек алып җибәрсәм, кышын клубка да йөрербез.

Хыяллар аның саен куера... Үземне утырган урынымда куышыбыз каршындагы таудай күтәрелгән итеп тоям.

— Мин бит кайтам, синең яныңа кайтам. Укытучы булып. Менә күрерсең!

Мәктәптә дә гел бишкә укыган Разиләнең анда укый аласына кем ышанмый инде?! Ә мин соң, мин? Ансыз нишләрмен?

Бу юлы качып-посып тормыйча, бакча сукмагыннан үзебезгә төшеп китәм. Сукмак буена утыртылган миләшләрнең сарылыгына да, алмасы коелып бетә язган алмагачларга да, башын игән бердәнбер көнбагышка да ачуым килә минем. Тик Разиләгә генә ачулана алмыйм.

* * *

Колхоз рәисе сүзендә торды. Әле бер-ике булышчы да бирде. Октябрь азакларына без, Гөлбикәттәйләрнең иске өен сипләп, куышыбыздан күчендек. Җанга, тәнгә җылы йөгерде, тамакка ризык керде.

Шулай да кышларын, Разилә ялга кайткан вакытларда, җитәкләшеп, көрт ерып, без шунда төшүдән туктамадык. Инде анда яшәмәсәк тә, көн дә сукмак ача торган булдык.

Разиләнең сүзе гел бертөрлерәк.

— Син шушында өч ел яшәдеңме? — ди ул, ишектән керә-керешкә.

— Өч ел. Күпмени ул? Гомер буе куышта яшәүчеләр дә бар.

— Ул әллә кайдадыр. Җылы якларда...

— Өлешеңә тигән көмешең. Тау астында да таллар бар... Тау өстенә үскән тирәкне дә күргәнем бар минем. Тамырларын барыбер суларга кадәр суза ул.

— Син үзеңне шул тирәк кебек чыдам димәкчедер инде.

— Юк. Мин бары тик яшәргә генә телим! Сулар эчеп, һава сулап... Менә сине күреп яшәргә!

— Мин синең кебек яши алмас идем, — ди Разилә, тагын да әкренрәк тавыш белән.

— Әле кайвакыт шушы куышны да сагынып куям. Мин аннан сине күбрәк күрә идем бит.

Әйе шул. Сагынам. Монда кышын да җәй исе килә. Шушы хуш исле мендәрләр өстендә күргән татлы төшләрне сагынам. Куышның ян-якларына элгән мәтрүшкәләрдән килгән ис, яшел яфрак килеш кипкән каен ботаклары, җиләкле печәннәр монда туган буй җитмәс кебек хыялларны искә төшерә.

— Өч ел! Өч ел! — ди Разилә кабат-кабат.

— Каршы як таудагы йортыгыздан синең кызыл яулык изәгән еллар бит ул...

— Шулай да мин түзмәс идем...

— Тау башында болытлар бар бит, Разилә. Ап-ак болытлар! Мин шул болытларга менәсемне белеп яшәдем.

— Ул болытлар тауның башын кисә, Мансур!

— Алай булса булсын, ирнең башын кайгы кисмәсен, Разилә!

Ул сүзсез кала. Мин күзләремне йомам. Хыялымда тау калка. Тау башында — болытлар. Болыт өстендә кызыл яулыгын болгаган Разилә. Ул әкрен генә болытлар белән бергә каядыр еракка-еракка агып китеп бара... Аны югалтасы килмәгәнгә, керфекләремне күтәрәм. Куышка сеңеп калган җәй исен соңгы тапкыр иснәгәндәй, күкрәкне тутырып сулыйм.

Түрдә, юан каен агачыннан кисеп ясалган бүкән өстендә, лампа яна. Аның сүрән яктылыгына кушылып чыккан сөрем генә әлеге исләрне күмеп китә һәм безнең күз алларыбызны да караңгыландыра.

Беренче тапкыр Разиләнең иреннәреннән үбәм. Көчсез терсәкләре белән эткән сымаграк кыланса да, аның шушы мизгелләрне күптәннән көткәнлеген аңлап, мин тагын да хисләнебрәк, дәртләнебрәк иркәләргә тотынам.

Безнең тау куышыннан чыкканны көтеп торган кояш, гадәттәгечә, әти яшәгән өйнең урта тәрәзәсенә кереп югала.

— Сау бул! — дип кычкырасым килә аңа минем. — Сау бул, кояш! Әтиемә сәлам әйт!

Әти дә бакча артына чыккан икән. Баз авызы баганаларына сөялгән дә Разилә белән минем бакча буйлап күтәрелгәнне карап тора.

— Улым... — ди ул миңа, Разиләләр белән ике арадагы сукмактан без аның янына җитәрәк. — Улым...

Мин туктыйм. Разилә дә туктый.

— Улым, кереп чык әле миңа, сөйләшик.

Ул кулындагы очсызлы тәмәкене кайракланган фуфайкасына гына басып сүндерә. Корсаклары шиңгән, акай күзләре кечерәеп калгандыр кук. Җирән башы — ялангач.

Мин, кайчандыр аның кулларындагы чыбыркыдан буылган шикелле, пәлтәмнең өс төймәсен ычкындырам.

Разиләгә китәргә ишарә ясап, алгарак уздырам да, кулыма җепшек кар алып, шуны әвәләргә тотынам.

Разилә лапас ишегеннән кереп югала.

— Улым...

Мин кулымда йомарланган карны үзебез яшәгән землянка ягына, тау астына ыргытам.

Әтинең күзләренә кабат карарга базмыйм. Өскә кием, аякка итек алып була, үлми калып була... әтине сайлап булмый, дип уйлыйм мин эчемнән. Әти әти инде ул.

Дәшми генә керегә, әни белән зәмһәрир суыкларны чыккан тау куышына төшеп китәм.

Мин аннан иртән, инде савытларда керосин калмагач кына, кайтам. Җир астының кечкенә уемыннан калай савытта саклаган бер рәсемне кулыма алам да лампа яктысында әйләндереп-әйләндереп карыйм. Анда — мин, әтиемнең күн итекле аякларына тотынып атлап китәргә чамалап торам.

Әнинең тавышында моңа кадәр беркайчан да сизелмәгән хәвефлек.

— Улым... — ди ул да. — Улым...

Иңенә ишелеп төшкән яулыгы, кара чәчләре шул шомны тагын да арттыралар.

— Улым, кайда йөрисең син? Әтиең вафат бит. Авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын.

Гомер буе әтидән тукмаудан башканы күрмәгән әни шулай ди. Бугазыма төер тыгылган хәлдә, шапылдап, ишек тупсасына утырам.

— Кайда? Ничек?

— Лапасларында... Сине буган чыбыркы белән асылынган. Инде кичтән үк тәдер. Тәне тәмам суынып беткән, диделәр.

— Әти... лапаста... кичтән... чыбыркы белән... — Оештырып сүземне әйтә алмыйм, ни дияргә теләгәнемне үзем дә белмим.

* * *

Кешеләр күпме кыстасалар да, әнием килен булып төшкән, минем михнәтле балачагым узган ул йортка без кире кайтмадык. Инде яңа нигезгә дә ияләшелгән, монысы үзебезнеке, дип тора идек. Язга чыккач, кирәксез калган йортны балачага уен урыны итте. Тора-бара коймалары җимерелеп, тәрәзәләре ватылып бетте. Балта алып рәтләргә кул бармады.

Җәен Разиләләрнең бакчасы буйлап күтәрелгән вакытларда, бәрәңге базы турысында тукталып, мин озак-озак итеп уйлана торган булдым.

Баз өстен чүп үләне каплаган. Тирә-ягын кычыткан күмеп киткән. Балачактагы мин атланып йөргән кола биябезнең ыңгырчаклары, ияр ише нәрсәләре лапас артындагы кадакларда теләсә ничек асылынып тора. Эшкә дә, кыенга да җитез куллы әтиемне алар да сагыналардыр шикелле.

Разилә бу ялда үзгәреп, сүзсезләнеп кайтты. Клубка да чыгасы итмәде. Соңгы имтихан дигән булып, көне буе минем тау куышының ачып куелган ишеге төбендә утырды. Авылга да, үз бакчаларыннан менмичә, хәзер әнием белән без яши торган йортның сукмагыннан кайтасы итте. Бу үзгәрешләрнең сәбәбен мин арт капка янында гына белдем.

— Мансур, өйлән миңа, — диде ул, кинәт кулларыма үрелеп. — Өйлән, зинһар...

— Ничек итеп? Нинди акчага? Уйламаганда-нитмәгәндә... Әле тагын бер ел укыйсы бар бит. Синең дә күпме...

— Өйлән миңа, минем авырым бар...

— Ничек? Бер тапкыр кочагыма кермичә дәме? — Бу сорауларны бирү үзе үк мәгънәсезлек иде.

— Мин алдандым. Башка берәүдән алдандым...

— Әти-әни күзенә ничек күреним? Авылдашларга? Барысы да синең белән йөри дип беләләр...

Эсселе-суыклы булып басып торам. Мин күкрәгенә дә кагылырга базмаган, авылда иң чибәр, иң акыллы кыз саналган Разиләнең алданган булуына ышанасы килми. Аркадан чишмә булып су ага.

— Булдыралмыйм, Разилә, ышаналмыйм.

— Кичер, Мансур, бөтен өметем синдә иде, инде булмады... — диде дә Разилә, кызыл яулыгын салынып төшкән кулларында өстерәп, бакчалар аркылы үзләренә таба юнәлде.

— Разилә, тукта, Разилә!

Тау башыннан, миңа сандугачлы өй түбәсеннән шушы яулыкны болгаган, миңа хуш исле һинд чәйләре эчергән, салкын кышларда, әнисеннән үтенеп, өйләрендә кундырган Разилә китә... Инде Разиләсез дә калыйммы дигән уй тәннәремне тагын да чымырдатып җибәрде.

— Тукта, Разилә, мин риза... — Соңгы сүз әкрен генә әйтелсә дә, Разилә аны ишеткән иде. Ул моңсу гына елмаеп миңа таба атлады.

Без, беребез — мәктәп укучысы, беребез — ярым-йорты укытучы, җитәкләшеп, ирле-хатынлы булырга сүзләр куешып, өйгә килеп кердек. Кердек тә көтелмәгән хәбәр белән мичкә ипи салып йөргән әнине аяктан да ектык.

Икенче көнне, күрше-күләнне җыеп, безгә никах укыдылар.

— Сиңа мәктәпкә юл ябык, малай актыгы, — диде әни, Разиләгә ишеттерми генә.

Мин икебез генә калган бу төнне Разиләне хәтта үпми дә уздырдым. Ул иртәгесен, китап-дәфтәрләрен тутырып, имтиханга китте. Китте, әмма кайтмады. Атна артыннан атна үтте. Разилә һаман да юк иде. Бусаганы таптап бетергән әниләре, эшкә җибәргәннәрдер, дип тынычландырдылар. Барып белешергә беркемнең башына килмәде. Минем өй бурычын түлисе бар, көтүне ташлый алмый идем. Ерак, юлсыз арага әнине дә җибәрәсе килмәде. Бөтенебез дә, аның исән-иминлегенә ышанганга, көтә бирдек.

Шулай билгесезлектә яшәгән көннәрнең берендә ул үзе килеп керде. Өстендә мин моңарчы күрмәгән нindидер яшькелт матур күлмәк. Озын кара толымнарын кистергән. Аягында — шундый ук яшелдән туфлиләр.

Керде дә, тагын да аптыратып:

— Мин китәм, Мансур, — диде.

Инде кая? Нигә? Яшәп тә карамаган килешме? Бөтен авыл миннән алданган икән, дип сөйләгәндә... Аның өчен мәктәпне ташлаганда.

— Мин китәм, Мансур, кичер...

Тагын. Инде тагын. Нигә гел кичерергә генә соң?

— Мине алдаган егет сиңа кияүгә чыкканны белү белән килеп җитте. Алам, бергә булыйк, рәнҗетеп ялгыштым, ди. Баламның атасы бит.

Атасы. Әйе, атасы. Баланың атасы да була бит әле. Менә мин әти була алмыйммыни? Минем кай җирем кешедән ким? Эштән башканы, әни белән Разиләдән башканы белмим дә ич мин.

— Әтине сайлап алып булмый, дисең бит, Мансур. Ул — аның әтисе, — диде Разилә кабаттан.

Әтине сайлап алып булмый... Шундук бәрәңге базының баганасына таянып калган әти күз алдына килеп басты. Инде аның күзләре дә бик килешледер, үзе дә әйбәттер шикелле тоелды. Әти булсамы?! Әти булса!

Күземә яшь килеп бөялде. Бәреп чыкканын да көтеп тормастан, керфек төпләреннән җыеп, мин аны Разиләнең туфли очлары алдына ыргыттым. Әтигә атарга йомарланган кар кебек...

— Сине дә сайлап алып булмый икән ләбаса, Разилә...

...Разилә китте. Әтием кебек, мин көтмәгәндә китте. Мин исә, үзеннән-үзе ярсыган үгез шикелле, шул көнне үк, төшеп, әтиле чакта яшәгән тау куышын җимердем. Шунда яшәгән гомеремнең бердәнбер истәлеге итеп костюм түшендәге кесәдә теге рәсемне генә калдырдым.

*1997*

*Мине карап үстергән кадерле әбиемнең*
*якты рухына багышлыйм*

## Югалту ачысы

Әтисе кайтып кергәндә, Шәмсенаһар сәке кырыена бүкән куеп баскан да тырыша-тырыша камыр изә иде. Озын итеп тегелгән күлмәгенең итәкләрен, җыеп, ыштан бөрмәсенә тыккан, яулыгын артка чөеп бәйләгән. Нәкъ мәрхүмә әнисе инде менә, дип уйлады, аңа карап, Габидулла, нәкъ әнисе...

Энесе Гариф искергән кызыл ашъяулык өстендә шакмаклар тезеп утыра. Патша хезмәтенә китәр алдыннан абыйсы койма тотканнан калган имән багана калдыкларыннан озаклап, яратып ясаган иде аларны. Әллә каян гына буявын да юнәткән, үзе яраткан сурәтләр дә төшергән. Әнә шулар Гарифка бер юаныч булды. Аннан да, төпчегенең балаларыннан да калыр бу чуар шакмаклар.

Әти кеше Шәмсенаһарны да, Гарифны да эшләреннән бүләргә теләмәде. Плитә кырына килеп, утын, су кертелгәнме дип карады да мич башындагы сәкегә менеп ятты. Бераздан аның янына өч яшьлек Гариф та үрмәләде. Монысы да исәеп килә, дип уйлады Габидулла, әмма аңа барыбер йортта ялгызы көн итүе авыр, һәм ул аргы якның Мулла Хатимәсен хатынлыкка алырга сөйләшеп кайткан иде.

Габидулла ничек сүз башларга белмичә бик озак ятты. Әллә ничә тапкыр талпынса да, тамак кырудан ары китә алмады. Ахырда түзмәде, мич башыннан төште дә камыр изгән Шәмсенаһар янына — сәкегә килеп утырды.

Шәмсенаһарга инде алты тулып килә, кул арасына керә башлаган, ипине дә үзе сала, этисе карап торганда, сыерны да үзе сава иде.

— Авыр түгелме, кызым? — дип сорады Габидулла, күз төпләренә килеп бөялгән яшьне ничек тотып калырга белмичә.

— Була, әттә.

— Нәнәң исән булса... — Габидулла, сүзне ялгыш яктан башлавын аңлап, кисәк туктап калды.

Бераз эндәшми торганнан соң:

— Кая, үзем алып куешыйм әле, — дип, камыры тыгызланган кисмәкне мич алдына күтәреп алып китте. Кисмәк шактый авыр булып чыкты. Габидулланың Шәмсеямал белән яшәгән рәхәт чакларын искә төшереп, аннан әчкелтем татлы ис килә.

Нәнәсе исән булса... Нәнәсе исән булса... ул хәзер су буенда уйнаган үзе кебек кызларга катнашыр, энесе Гариф белән юаныр, абыстайга йөрер... Нәнәсе исән булса, ипи пешкәнгә торыр, ягымлы сүзгә уяныр иде лә... Габидулла комгандагы җылы су белән камырлы кулларын юдырганда, Шәмсенаһар шулай дип уйлады.

Камыр күпергәнне, ипи пешкәнне көтеп, көн дә үтте. Кыз идәнне сөртеп алды, тәрәз каплап үскән гөлләргә карап юанып торды, төпләрен йомшартты, кибеп киткәннәренә сулар сипте.

Өй җылынды. Аңа җылы, татлы ис — көз исе, икмәк исе таралды. Барысы да аш бүлмәсенә җыелдылар. Мич төбендә тәгәрәшеп, кызарып пешкән ипиләрне Габидулла үзе алды, әйләндереп, әле иртән генә Шәмсеямал белән килгән сандык төбеннән чыккан өр-яңа ашъяулыкка китереп салды.

Бик ачыккан булсалар да, балалар икмәк кайрысын сорарга да батырчылык итмәделәр. Шәмсенаһар плитә тирәләреннән дымлы канат белән көл сыпырган итенеп, комганга җылы сулар өстәп йөрде. Гарифны юындырып алды, үзе ыспайланды. Аннан алар сәкегә килеп утырдылар. Кайнар икмәкнең бераз суынганын көтеп, тын гына утыра бирделәр. Габидуллага да кабат сүз башларга җай чыкты.

— Нәнәгездән башка бик авыр... — дип куйды ул.

— Әйе...

— Әйбәт кеше иде мәрхүмә, уңган кеше... — Габидулла тагын шул ук сүзгә килеп төртелде.

— Ярар инде, борчылма, әттә, менә без бар бит, — диде Шәмсенаһар, аны тынычландырырга теләп.

— Апагыз Шәмсекамәр дә кул астына керә башлагач кына ...— Ярар инде, әттә, ярар...

Юк, сүзне болай башларга ярамый иде. Габидулла:

— Әйдәле, кызым, ипине үзең кисәсең мәллә? — дип, иң матур, иң түгәрәк ипине куна тактасы өстенә алып куйды. Ул әле барыбер дә кайнар, рәхәтләнеп, күкрәккә терәп, каерып кисәрлек түгел иде.

— Пешерә бит әле, әттә.

— Пешерә икән шул, — диде Габидулла, тагын бер мәртәбә тотып караган булып. — Алайса үзем генә кисәрмен, син чәй ясый торырсың. Самавыр күптән өстәлдә, әмма әкрен генә көйләп утыруында иде әле.

— Сыерның сөте кимүгә таба бара, озакламый савудан туктарбыз, ахрысы.

— Ярар, әттә.

— Синең дә абыстайга йөрер чагың җитә. Укымыйча калырга ярамас.

— Ие, әттә.

— Әле менә сезгә әни дә алып кайтсам, эшең дә бераз кимеп китәр.

Шәмсенаһар, сәерсенеп, атасына күтәрелеп карады. Шаяртканга охшамаган иде. Кара инде, никадәр үзебез генә яшәгәч, дип уйласа да, кычкырып әйтмәде. Аның каравы кечкенә Гариф, аптырап:

— Үлгән кеше кире кайта мәллә ул? — дип сорады.

— Юк, улым, кайтмый, авылда әниләр тагын бар бит әле, без башкасын алып кайтырбыз.

Инде бу юлы Гарифның сөенүле тавышы ишетелде:

— Ярар...

Ул, әнисеннән бик яшьли калганга, аны тәмам оныткан, үлгәнлеген дә сөйләгән сүзләр буенча гына аңлый иде. Аңа тагын әниле булу бик кызык бер эш сыман тоелды.

— Миңа кибет уенчыклары алып килер микән?

— Килер, улым, килер. Шәмсенаһарга менә дәфтәр, карандаш бирер, сиңа — пәке. — Ата, бу турыда алдан ук уйлап, базар көнне Китәк дигән мари авылына барып, кырык тартмачыдан алган һәм, сандык төбенә салып, яшереп куйган иде.

Шәмсенаһарның киләсе бүләккә исе китмәде. Ул болай да хәреф таный, моңа аны абыйсы Нигъмәт өйрәтеп киткән, солдаттан ул да бүләккә дәфтәр белән каләм алып кайтачагын әйтеп хат язган иде.

— Миңа Нигъмәт абый бирер әле...

Нигъмәтнең әле кайчан кайтасы билгесез. Дөньясында да төрле хәлләр булырга тора, аның солдат гомере дә озакка сузылмагае, дип уйлады ата.

— Миңа да абый алып кайта. Башка төрле бүләк алып килсен, чиккән кәләпүш!

— Ярар, улым, ярар!

— Читек, кәҗәки... — дип тезеп китте Гариф.

— Ярар соң.

Габидулла абыйның тормышы нык, боларны гына алырга хәленнән килә иде. Икенче көнне ул, авыл сәүдәгәренең йорт янындагы кибетенә кереп кенә, Гариф сораганнарны алды да Хатимәне җитәкләп кайтып та керде.

Яшь хатын Шәмсенаһарның эшен җиңеләйтергә уйлап килмәгән икән. Кыз гадәтләнгән эшләрен үзе эшли бирде. Бүкәнгә басып камыр изде, кечкенә чиләкләр белән кисмәккә су ташыды, сыер астын җыештырды... Дәфтәре-каләме булса да, абыстайга йөрергә җае чыкмады.

Мулла кызы тәрәзә каршысына утырып чигү чикте, ямау ямады, дога китаплары укыды. Укыган саен, Шәмсеямалны телгә алмый калмады.

— Аллага шөкер, җаны шат булыр, догага иреште, — дип сөенде Габидулла, балаларның һаман да үзләрен үзләре карауларын күрмәскәрәк, йөрәген бозмаскарак тырышып. Илдә әле яңа гына большевиклар хакимлек итә башлаган, гражданнар сугышы бара, тормышның кайсы якка тәгәрәсен күзалламаган атаны янындагы балалары Гариф белән Шәмсенаһардан бигрәк олы улы Нигъмәтнең язмышы борчый, һәм ул аның кайсы яктан торып сугышканлыгын да белми иде.

...Шундый ыгы-зыгылы көннәрнең берсендә төн катында тәрәз шакыдылар:

— Әттә, ачыгыз әле, Нигъмәт бу...

Габидулла тынсыз калды. Ышанырга-ышанмаска белмәде. Аш бүлмәсендә йоклап яткан балаларны да, түрдә — йомшак ястыкларда изрәгән яшь хатынны да уятмаска тырышып, чоланга чыкты. Шакучының кемлеген кабатлап сорамады, әкрен генә келәне күтәрде. Аның каршысында басып торган шәүләнең Нигъмәтнеке икәнлегендә шик юк иде. Тик нигә болай, уйламаганда-нитмәгәндә, кара төндә, нәрсәдәндер курыккан бер кыяфәттә?..

Ата белән бала аһылдашмыйча-уһылдашмыйча гына кочаклаштылар да икесе дә, бер-берсенә билгесез хәлләрне эчләрендә калдырган килеш, йорт ишегеннән уздылар.

Габидулла абзый йорт эчендәге яңалыкларны ничек җиткерергә белми аптырады. Аны Нигъмәтнең ачылып китеп сөйләшмәве сагайта иде, шуңа күрә сүз башларга ашыкмады. Сүрән итеп куелган бишле лампа яктысында, башкалар уянмасын дип, пыш-пыш килеп кенә балалар турында сөйләшкән булдылар. Нигъмәт күрше-күлән хәлен белешкән сыман итенде дә тынып калды.

Габидулла улының тынгысызлыгын, нәрсә турындадыр баш ватуын күреп тора иде, әмма, үзе әйтер әле дип, сәбәбен тикшермәде. Шулай булып чыкты да. Нигъмәт, мич куенына сыенып утырган өчаяктагы ботканы капкалап алгач, атасыннан җылы кием, киез итек сорады. Аның:

— Әттә, беркемгә ычкындырасы булма, мин качтым, нишләргә белми аптыраганнан качтым, печәнлеккә салам астына күм, зинһар, — дигән сүзләре Габидулланы башына суккандай итте. Йа Раббым, нәрсә булып бетәр бу? Хәерлегә генә булса ярар иде...

Алай да ата кеше үзен тиз кулга алды. Кече якта болай да сүнәм-сүнәм дип кенә утырган лампаны басып, улы белән лапаска чыгып китте. Кеше-фәлән генә күрмәсә ярар иде, диде ул эченнән. Кара төндә һичкемнең башка кешедә йомышы юк, иллә мәгәр мулла кызы, уянмаганга салынса да, түр яктан да боларның һәммәсен ишетеп яткан һәм эшне аңлаган, башлы-күзле булыр егетнең кайтып төшүеннән үз тормышы кысылыр дип куркып калган иде.

...Таң атар-атмаста тагын тәрәзә шакыдылар:

— Откройте!

— Хто там? — Ишеккә бу юлы да ата кеше үзе килде.

— Ваш сын дома? Он сбежал с армии, — диде тыштагы усал тавыш.

— Ваше былгарудие, ничава низнаем.

— Откройте, кому говорят!

Габидулла, ватып ук ташламасыннар тагын дип, тиз генә ишекне ачты. Аны бар дип тә белмичә, атылып йортка кергән ике-өч мылтыклы куптарган тавышка балалар да уянды.

— Ни эш анда, Габидулла? — дип сораган булды күзләрен уа-уа түрдән чыгып килгән Хатимә.

— Менә, малайны эзлиләр, качкан, ди...

Тентүчеләрнең берсе татар егете икән. Кояш күтәрелеп килгәндә дә, йомшак урында иркәләнгән яшь хатынга ире күрмәгәндә генә күз кысып алды ул. Тегесе, оялганга салынып, яулык очлары белән битен каплагандай итте, әмма тәмам качмады.

— Беркем дә юкмыни соң, тути?

— Ю-у-ук, — диде Хатимә, сузып кына, үзенең шунда ук күзе малайлар йоклаган сәке кырыена кичен Нигъмәт куеп калдырган кызыл саплы пәкегә төште. Төште дә аптыраган сыман карап тора башлады.

Аның күз карашын солдат та тотып алган һәм эшне аңлаган иде.

— Синекеме бу, энем? — дип сорады ул, таныш түгел абыйларының кыланышына аптырап утырган Гариф янына килеп.

— Юу-у-ук... Безнең андый пәкебез юк. Минем пәкем зәңгәр саплы. Күрсәтимме?

Солдат абыйсы дәшмәде. Мич артын, сәке, караваt асларын, өй астын караганнан соң, алар кызу-кызу киңәшләшеп алдылар да каралты-курага таралыштылар.

Солдатларның берсе туп-туры Нигъмәт күмелгән печәнлеккә менеп китте. Өйдәге гауганы егет күптән ишеткән, шым да чыгармыйча, салам астында ята иде. Тик ул озак ята алмады, бер-бер артлы тәненә кадалган штыкларның авырттыруына түзмичә:

— Есть, ваше благородие! — дип, үзе үк сикереп торды.

Нигъмәтне шунда ук алып киттеләр. Кулларын бәйләгәндә дә, төрткәли-төрткәли урам буйлап куганда да атасыннан күзен алмады. Шул каерылган килеш авыл урамын чыкканда, соңгы тапкыр күрүен сизгәндәй, артларыннан көч-хәл белән җитешеп барган Габидуллага:

— Әттә, хуш! Бәхил бул! — дип кычкырды.

Ак солдатлар авылдан чыгып күп тә үтмәде, тау астындагы чишмә буеннан ату тавышлары яңгырады. Габидулла түзмәде, аягына чабата гына элеп, туп-туры шунда йөгерде. Су буендагы ак карлар эзләр белән тапталган, бер урында ике-өч тамчы кан тамган, әмма бернинди мәет юк иде.

Ата бозны җепшекләндереп, язга чыгуны көткән чишмә буена килеп утырды. Башын тотты. Ни дияргә белмәде. Яланбаш икәнлеген абайлады. Карашын су юлы буйлап югарыга күчерде.

Аннан берничә адым читтә, яр астында, солдат кепкасы ята. Ул аның улыныкы икәнлеген аңлады. Барып кулына алды, башына киеп караган булды. Зуррак тоелса да, салмады. Солдат кепкасын кигән хәлдә, башын кыңгырайтып, йортына кайтып керде.

Керде дә, ни әйтергә белмичә, мич кырына чүгәләде. Ел кебек озын бу төнне, таңны ул әле дә аңлап җиткермәгән, әмма аның хәсрәте, сөйләшмәслек хәлгә китереп, бугаз турысына утырган иде. Салып, кулына тоткан фуражканы алай әйләндерде, болай. Тезләренә куеп бик озак карап утырды. Күзеннән тамган яшь чылаткан чүпрәген сыпыргалады. Аннан, беркемгә берни сөйләмичә генә, хатыны Шәмсеямалга ияреп килгән сандыкка, нәнәсе әйберләре өстенә куйды.

Хатимә чәй әзерләп йөри, Шәмсенаһар — үз эшендә. Гариф абыйсыннан калган кызыл саплы пәке белән, үткенлеген сынагандай, мич алдына телеп куйган чыраларны юнып утыра.

Шәмсенаһар, әтисенең борчылган уйчан йөзен күреп, эшнең начар беткәнлеген тойды. Эндәшмәвең яхшы булыр дип санап, сүз катмады. Габидулланы тынычландырырга ашыкмаган яшь әнисенә карады. Аның, гаеп囲 эштә тотылгандай куркып калуын, йөзен яшерергә тырышуын күрде.

Ай үтте, икенчесе. Март җитте. Ул арада авылга кызыллар килеп керделәр. Керделәр дә аяктагы бар ирне сугышка демобилизацияли башладылар. Хатынлы булып өлгергән Габидулла абзый да алар арасында иде.

Озакламый, ятимнәр белән торуны авырсынып, мулла кызы атасы йортына күченде. Сигез яшьлек Шәмсенаһар белән кеп-кечкенә Гариф үзләре генә торып калдылар. Ниндидер ерак авылдан килгән бер хәлфәгә кияүгә чыгып, йорттан китеп барган апалары Шәмсекамәрдән дә бернинди хат-хәбәр юк иде.

Шулай берничә ай яшәп ятканнан соң, туганнары җыелып сөйләштеләр дә, сыерны, Гарифны берсе үзләренә алырга булып, Шәмсенаһарны күрше авылдагы ниндидер чирмеш-әкәйгә* бала карарга урнаштырдылар. Беркемгә беркайчан каршы әйтергә күнекмәгән кыз язмышына сүзсез генә буйсынды.

Хуҗалар начар кешеләр түгел иде. Кызны киендерделәр, ашаттылар, какмадылар, сукмадылар. Ул әкренләп мари теленә дә өйрәнде. Шулай да авылын, энесе Гарифны, сугыш кырларында тилмереп йөргән әтисен бик сагынды. Бала йоклатса да, су китерсә дә, эченнән гел аларны уйлап, «Сак-Сок» бәетен көйләп, ямансулап йөрде.

Авыл аша узган бер юлчы атасы Габидулланың үлүе турында имеш-мимешләр йөргәнне әйткәч, гомерем гел бәхетсезлектә генә үтәр микәнни, дип үксеп-үксеп елады.

Ятимлек язмышына буйсынган кыз тыныч кына хәзергә Микулай дәдәсендә яшәр кебек иде, әмма, авыл советыннан тикшерү белән килеп, яшь баланы үзеңә эшләтәсең, мәктәпкә йөртмисең, дип, ниләр

беләндер куркыттылар, янадылар. Ул инде, үз йортыннан мәңгегә чыгып киткән кебек, Шәмсенаһарны туган авылына кире кайтарып куярга мәҗбүр булды.

Шәмсенаһар, Микулай абзасында торганда, татар авылындагы яңача укыткан хәлфәгә берничә дәрескә барган, Мәҗит Гафури дигән бер шагыйрьнең «Кызыл байрак» декламациясен яттан сөйләп бишле алган һәм алдынгы укучылар исәбенә дә кергән, әмма ара ерак булгач, үзе үк мәктәпкә йөрүдән туктаган иде. Кызга, укы, зиһенең бар, дип, бер килделәр, ике. Инде кул селтәделәр дип уйлаган иде югыйсә...

Шәмсенаһар, шулай итеп, тагын туган нигезенә кайтып төште. Әле кайчан гына хуҗаларның булганлыгын күрсәтеп, кукраеп торган йорт ярым җимерек хәлгә килгән. Кыз киткәч, кызыллар тагын монда тукталганнар. Мунчаны, абзарларны, өйнең тераткән ягын утынга кисеп якканнар булып чыкты. Түре дә абзарга әйләнеп калган йортны кыз көн юды, төн юды, кеше яшәрлек хәлгә китерде, әмма ул арада Микулай абзасы биреп калдырган ризыктан җилләр исеп өлгерде.

Көз көннәре булганга, кыз аптырап калмады. Ул эштән курыкмый иде. Келәт почмагына кадап куелган иске уракны алып, шул ук мари авылына көнлекчелеккә китте. Әле берсенә, әле икенчесенә эшләп, тамак туйдырырлык ризыгын туплады, кышка энесен үз янына алды.

Гариф чит җирдә мәктәпкә йөргән, үскән, кул арасына керә башлаган, әмма ата-анасыз баланы авылда калдырырга ярамый, үз көнен үзе күрәсе бар дип санаганга, Шәмсенаһар яше җиту белән, туганнары белән киңәшеп, энесен һөнәр бирә торган уку йортына — калага җибәрде. Өстеннән зур бер йөкне төшергәндәй булды. Шул көннән иң кадерле кешесен югалтканлыгын да аңлады, күңелсезләнеп, моңаеп калды.

Гомер уза торды. Ул арада калхузлашу еллары башланды. Көнлекчелеккә исәп тотарлык түгел иде. Кияүгә чыгар яшькә дә җитеп килә. Ир-атлардан да озынрак буйлы, чандыр бу кызга күзе төшәрдәй егетләр табылмады, иллә мәгәр эшкә булганлыгына, сабырлыгына шаккатмаган кеше юк иде.

Инде утызы тула дигәндә, күрше Чалпыбаш авылының үзе шикелле үк ябык, озын буйлы егетеннән аңа яучылар килеп төште.Шәмсенаһар, ялгыз калудан бик курыкканга, шунда ук ризалыгын бирде. Әнисе Шәмсеямал белән килгән затлы сандык әле исән иде, шуны алып, каенана йортына күченде.

Ике кыз туган арасында үскән Шакир сабыр холыклы, аз сүзле, гаилә эчендәге ыгы-зыгыдан бик туйган күркәм холыклы бер егет иде. Шәмсенаһарны да, үзенә охшаганлыгы өченме, ул бер күрүдә яратты. Барган җиреннән буләксез кайтмады, чыраен һичбер вакыт караңгылатмады.

Бәхет дигәннәре тагын озакка насыйп итмәгән икән. Ул арада Бөек Ватан сугышы башланды, сугышның беренче көненнән үк Шакир фронтка китеп барды. Яшь ярымлык баласы белән Шәмсенаһар каенана йортында тагын ятимә кебек ялгызы торып калды. Шул елны ук җәй ахырында кулына, яшен суккандай итеп, иренең вафатыннан хәбәр тоттырдылар.

Йортта кияүгә чыкмаган Җәмилә белән, бала күтәреп, иреннән аерылып кайткан Кәримә дә булгач, килмешәк рәтендә йөргән Шәмсенаһарга тәмам көн бетте. Эшләсә, эше ярамады. Сөйләшсә, сүзе килешмәде. Барыр җире юк иде, ул тагын таныш мари абзасының тупсасына килеп егылды.

Инде Микулай дәдәй үлгән, Шәмсенаһар карап үстергән балалар үзләре әти булганнар, әмма ләкин аның яхшылыгын онытмаганнар иде. Ять-яшь килеш ул Симун балаларына нәнә булып китте. Һәр атна, ризык күтәреп, каенана йортында көчләп калдырылган Хамматы янына йөгерде.

Вакыт аның саен үтә торды, Хаммат та, Василий, Виталийлар да үстеләр. Шәмсенаһар кулына инде эш тә тими башлады. Көннәре бушка үтә шикелле тоелганга, каенанасы да картаеп барганга, анда кирәгем зуррактыр, дип, ул кабат алар йортына кайтып төште.

Тормышлары авырлыктанмы, дәрәҗә саналгангамы, бу өй бервакытта да укымышлы фатирчылардан өзелмәде. Шулардан Фәйзрахман исемлесен Шәмсенаһар апасы аеруча яратып өлгерде. Аңа әтисез калып, үз тормышын үзе күргән, институт бетергән, әле яңа гына әнисен дә җирләгән яшь егет кеше хәлен аңлый, үтә дә миһербанлы кебек тоелды.

Кичләрен, дәфтәрләр тикшерә башласа, Шәмсенаһар аның янына килеп утырырга, дәшми-нитми генә күзәтергә, баласы кебек якын итеп карап торырга гадәтләнде. Ул биргән күлмәкләрне яратып, саклап киде, ул биргән сабыннарны тиз генә тотарга ашыкмады. Үзе янында юк чакларында әйберләренең әле берсен, әле икенчесен иснәп, сандык төбенә кире салып куя иде. Инде ул да үз авылына кайтып киткәч, Шәмсенаһар тәмам боекты, күңеле төште, әле дә ярый Хамматы бар, шуңа карап, үскәненә сөенеп, юаныч таба иде.

* * *

Көннәрнең берендә, артык кашык булуда гаепләнүгә рәнҗеп, тәрәзә төбендә елап утырганда, Фәйзрахман килеп керде. Шәмсенаһар апаларында фатирда торганда, ыгы-зыгылар кеше күзеннән, колагыннан яшерелгәнгә, ул гаиләдәге киеренкелекне бөтенләй белмәгән-сизмәгән икән. Әллә, эшкә күмелгәнгә, игътибары гына җитмәгәнме?.. Үзе өчен көтелмәгән хәлләр аны сабырлыгыннан чыгарды. Бераз карап

торды да, кинәт барысын да аңлагандай, ике уйларга да бирмичә, Шәмсенаһарны җигүле чанасына чыгарып та утыртты.

— Әйдә, безгә, үзебезнеке булырсың! Авыр сүз әйтмәбез, әнкәм урыны — синеке, Шәмсенаһар апа.

Инде мәктәпне тәмамлаган, калхузга эшкә йөргән Хаммат, бу йортта үскәнгә, аннан китүне күз алдына да китерми, хәер, аны куып җибәрергә беркем дә ашыкмый һәм, үз каннары санаганга, бик яраталар иде.

— Малаең синең белән китми! — диде каенана.

— Кул арасына керә инде ул, үзебездә калсын, безнең дә көн итәсе бар, — диде йомшаграк тавыш белән каенсеңлесе. — Улым белән дә бик дуслар. Өйләнер яшькә җиткән егет йорттан купмас.

Хаммат, акыл кергән, атасы кебек үк сабыр егет булса да, йомшады, түзеп кала алмады: еламсырап ишек яңагына сөялде, әмма, синң ияреп китәм, дип тә, китмә, дип тә әйтмәде. Бу йортта һәрнәрсәне әби кеше хәл итә иде.

...«Гөбәернең урамнары ике яктан канаулы» дип җырлаганнары дөрес булмаган лабаса! Кешеләре усал телле дигәннәре дә хак чыкмады. Авыл әле Түшшел тау башыннан ук ялтырап, калай түбәле йортлары белән балкып күренгән иде. Асылда тагын да матуррак икән. Кешеләре тырыш, хәлле, якты чырайлы. Әллә кайдан сәлам биреп киләләр, бер белмәсәләр дә, хәлеңне сорашалар. Күрше-күлән бер-берсе белән үз туганына кебек керешә.

Әле беренче көнне Шәмсенаһар йортның ишеген каерып ачып, башын бөгеп эчкә узуга, каршысына туп кебек малай йөгереп килде дә:

— Әби! — дип кочаклап та алды. Аның кулына икенче яктан курчак кебек кенә кеп-кечкенә кызны китереп тоттырдылар:

— Менә монысы кызың булыр!

Шәмсенаһар апа, балалар белән бергә олыгая торгач, чыннан да, әби булды. Инде намаз-ниязын калдырмады, авыр эш эшләмәде. Кызына әйләнгән Зиләне кочаклап йокыга китте, аның белән бергә уянды. Бергә китаплар укыдылар, дөнья хәлләре сөйләштеләр.

Дөрес, күңеле бик тулган вакытларда, тәрәз төбенә утырып, Малмыж шәһәрендә үз көнен үзе күргән, инде әти булган энесе Гарифны уйлап моңлана да, кешегә ишетелмәслек кенә итеп, әлеге дә баягы «Сак-Сок»ны көйли иде.

Мондый чакта балалар, урыннарыннан да кузгалмыйча, шым калып торалар. Җырлаудан туктаса, янына килеп кочаклап алалар.

— Елама инде, әби! — ди Зилә.

— Җырлый гына ич ул! — ди абыйсы.

Туган авылын бик сагынган көннәрендә ул чишмә буйларында, болыннарда йөреп кайта. Сабыйларга бик нык ияләшсә дә, күңеленнән кеше йортында калган, хәзер башлы-күзле булган улы китми иде.

...Хамматның гаиләсе тиз ишәйде. Ул арада, йорт төзеп, башка да чыкты.

Инде олаеп барган Хаммат әнисе янына хәл белергә төшә һәм һәрвакыт үзе янына чакыра иде. Бер кире какты Шәмсенаһар, ике, кеше әнкәңне дә карамыйсың, дип, битемә төкерә ич минем, дигәч, түзмәде, баласына кара ягып дөньядан китәсе килмичә, ризалашты, тик үз аягы белән соңрак кайтырга булды.

Бу төн йортны кара кайгы чорнагандай тоелды. Беркем ашамады, эчмәде. Иң кадерле кешесез калудан туган сагыш ике баланың да йөрәгенә таш сыман утырды.

— Менә сиңа ун сум акча. Минем кучтәнәчем кебек, тәмле әйберләр алып ашарсың, — диде инде зураеп бетсә дә, алдына утырырга яраткан Зиләгә әбисе.

Уеннан кайтып кермәгән Маратка җылы оекбашлар сузды.

— Кара аны, аякларың туңмасын! — Бераз уйланып торганнан соң: — Бик чабасың, сызламасыннар, — дип өстәде.

Әбиләре киткәч, тәмле әйберләрнең дә, җылы оекбашларның да кирәге калмаганны аңлап, балалар дәррәү елап җибәрделәр. Шәмсенаһар апаның да күзләренә яшь килде.

— Әллә бездә генә каласыңмы соң? — дип сорады соңгы тапкыр инде ни дияргә дә белми аптыраган Фәйзрахман. — Балалар бик яраталар бит. Кеше әбисе дип тә белмиләр. Ничек түзәрләр дип торам әле...

Җыясы әйберләр җыелды. Әйтеләсе сүзләр әйтелде. Дога кылырга дип, ишек катындагы урындыкларга утырыштылар.

— Үз баламны рәнҗетә алмыйм инде, болай да күпне күрде, — диде ана кеше, бу карарга яңа гына килгәндәй, нык итеп. Диюен диде, әмма шул арада бите буйлап яше тәгәрәде. — И-и-и... сез дә үземнеке кебек бит инде...

Тынычландылар. Дога бер сабырлык биргәндәй булды. Китәргә дип кузгалгач кына, Шәмсенаһар әбиләре, чүгәләп, соңгы тапкыр тотканын аңлагандай, ике баланың да аяк башларыннан сыпырды, елаудан дерелдәгән йомшак кулларын җылыткандай итте. Аннан пышылдап, ишетелер-ишетелмәслек кенә:

— Инде ничек сагынмыйча түзәргә? — диде.

Күчтәнәчләр төяп, машинага утыртып, карчыкны ерак юлга озаттылар. Яз җиткән көннәр иде. Шундый матур чакта, исән булса да, әбисез калуны балалар аңлый да алмадылар, аңларга да теләмәделәр. Зилә, печәнлеккә менеп, бик озак елады.

Җае килгәндә, Шәмсенаһар карчыкның хәлен белделәр, ярдәменнән калдырмадылар, әмма балалар янында аның хакында азрак сөйләшергә тырыштылар.

Бу югалту һәркемгә бик авыр иде. Өстәлендә самавыры җырлап, миче ягулы булып торган йорт элекке ямен югалтты. Аның ишегенә хуҗалар эштә чакта бик эленде, җомга көннәрендә хәл белергә күнеккән карчык-корчыклар да килүне сирәгәйттеләр.

...Бервакыт, көтмәгәндә, Шәмсенаһар карчык үзе кайтып төште. Инде балалар укуда — читтә, Фәйзрахманнар да икәүдән-икәү генә чөкердәшеп яшәп яталар. Бу күрешү йортка ямь, җанга рәхәтлек китерде.

Ерак юлдан җәяү килсә дә, аяклары сызлау булса да, әбекәйнең дә күңеле шат, көр. Чалпыбаштагы тормышыннан да бик канәгать икәнлеге сизелеп тора. Тик менә, сагынган булса да, балалар өйдә түгеллеккә генә бераз пошынды ул, бик күрәсе килгәнгә түзмичә килгән идем, дип әйтә куйды, әле тагын килә аламмы-юкмы...

Кыш җитте. Шәмсенаһар апаның бераз авырып торганлыгын ишетеп, балалардан башка гына хәлен дә белеп кайтканнар иде.

Озак та үтмәде, урман кисәргә төшүендә хәл алырга кергән Хаммат әнкәсенең вафат икәнлеген әйтте. Кышкы ялга кайткан Зиләне көтелмәгән яңалык аяктан ектымыни?!

— Нигә безне чакырмадыгыз? — диде ул, яшенә буылыр хәлгә килеп. — Әбине күмгәндә, юк, әле авырганда ук нигә безгә хәбәр салмадыгыз?

— Уку кешесенең вакыты кадерле, эшләреннән бүленмәсеннәр, минем риза-бәхиллегемне әйтерсең, диде әбиегез. Үзем юындырып үстергән балаларның аяк-кулларын гына тотып карасым килә, дигән иде дә... язмагандыр инде.

Әбисе, авылның иң акыллы, иң булган, иң сабыр әбисе, аны иң нык яраткан әби юк, һәм моңа ышанырга да авыр иде. Ичмасам, өйдә хәтта рәсеме дә калмаган, дип ачыргаланып үйлады Зилә. Рәсеме дә калмаган! Бите, иреннәре буйлап туктаусыз аккан яшьләр белән дә аны кайтарып булмый иде инде...

— Борчылма, гомере кеше кулында узганга, ул ничек үз йортында торырга теләгән иде бит! Шуңа иреште, миңа да риза булып китте, — дип сөенеп әйтеп куйган Хамматка Зилә, үртәлгән җанына чыдый алмыйча:

— Монда да аның үз өе, ул безнең әби иде ләбаса! — дип җавап кайтарды.

Сүзгә бер читтә тын гына торган әтисе кушылды:

— Ие шул, никадәр якын кешесе булгач, балалары аякка баскач, кадере арткач кына, менә безне калдырып китеп тә барды. Үлем үкенечсез булса икән ул!

* * *

Очраклы рәвештә Чалпыбаш авылы яныннан узганда, кешеләрдән сорашып, Зилә әбисе яшәгән йорт янына тукталды. Яңа, кояш төсенә буялган капкасыннан узмады. Каршысындагы тау башына килеп утырды.

Аста, бераз түбәндәрәк, тирәкләр арасында мәчет сыман эшләнгән йорт эчендә әбисе дә сукмагыннан көн дә төшкән чишмә ургып утыра. Аның мул сулары тыштагы улакларга агып чыга да тагын, очан су булып, югары күтәрелә. Тагын аска коя, тагын күтәрелә. Менә нинди матур җирдә яшәгән икән ул! Якынгарак төшсәң, таралып сибелгән тамчылары кояш нурларыннан янадыр.

Бераз ерактарак, агачлары урман кебек күкрәп үскән зиратта, кадерле кешесенең кабере бар. Барыргамы анда, бармаскамы? Хатын-кызга эченә керергә ярамас. Каберен күрсәң, бу югалтуның чынлыгын бөтенләй аңларсың...

Доганы әллә шушы чишмә буенда гына укыргамы? Әбисенең очан су кебек кояшка үрләгән якты җаны тар сукмаклы, тимер читлекле каберлек өстендә бөтерелми дә торгандыр. Ул бит иркенлекне — болыннарны, чишмә буйларын ярата торган иде.

— Исәнме, әби! — дип куйды Зилә. — Мин сиңа килдем. Бик сагынып килдем. Барлыгыңны тоясым килгәнгә килдем!

Аста, чишмәдән мөлдерәп чыккан суларда, әбисенең тавышы бар бит! Моңлы «Сак-Сок»ны җырлаган тавышы калган! Чишмә әнә шуңа, кош кебек, кат-кат күккә күтәреләме әллә? Кошларны да тормыш җиргә төшерә, ризык эзләргә төшерә...

Чишмә, очынып-очынып улактан улакка сикерә дә, сабырланып, чуерташлы ярлар эчендә тын гына ага башлый, аннан башка шундый бик күп чишмәләр аккан мул сулы елгага кушыла. Ул сулар Зилә яшәгән авылга таба юл ала.

Елга ага да ага. Ник гомер чишмәләре генә агар сулар кебек мәңгелек түгел? Ник аларның тәме гел үзгәрә? Әгәр, сукмагыннан төшеп, әбисе эчкән чишмәнең суын татысаң, көмеш тамчыларында югалту ачысы бар микән?

*2004*

## Елан читлеге

Галимәбануның, капка келәсен төшергәндә, йөрәге дертләп куйды. Нәрсәдән туганы да билгесез бер хис умырып алды аны. Бераздан, хәл җыеп торгач, гадәттәгечә урам тәрәзәләренең иң кырыйдагысына күтәрелеп карады. Кечкенәсе, Хафизы, тәрәз тупсасына менеп баскан да ике куллап рамга ябышкан. Йөзен тигезләткән пыяла баладан куркыныч бер җан иясе ясаган. Галимәбану елмайды, сак бул дигәнне аңлаткан хәрәкәт ясады.

Кичә татар теле дәресендә бер тыңлаусыз укучы каршысында яткан кәгазьдәге карачкыга күрсәтеп:

— Бу нинди кикимора? — дип сораган иде. Укучылар көлеште. «Рәссам» башын түбән иде, укытучысының үз сурәтен ясаган икән.

Кайвакыт ярату аркасында башкарылган эшләр дә иясен йә көлкегә калдыра, йә көтелмәгән бер хәл китереп чыгара. Шул сурәт кыяфәтенә кергән Хафиз да кызганыч булып китте. Әйтерсең, ул ямьсезләнгән, әйтерсең, анасыннан аерылып, өйдә калганы өчен үпкәле.

Ә бит Хафиз, әти-әнисе эшкә киткәндә, бикләнгән ишек артында калса да, көн дәвамында караучысыз булуына үзе дә риза түгел. Кайвакыт, уку башланып бер-ике сәгать үтүгә, арт ишектән чыга да әнисе артыннан мәктәпкә килеп тә җитә. Ул күрмәгәндә генә, тәнәфестә сыйныф бүлмәсенә үтә һәм парталар артына кереп яшеренә.

Сабыйның бу гадәтенә ияләнгән, аны үзләренә тиң, иш санаган укучылар Галимәбану апаларына серне ачмыйлар. Ул, шулай итеп, дәрес буе поскан килеш, тын да алырга куркып утыра. Шуннан да канәгать...

Кайбер көннәрдә әнисе аны үзе дә ияртеп эшенә алып бара. Шуның белән Хафизга бәйрәм ясый. Күпкә олырак балалардан да остарак укый, яза инде ул! Тагын, тагын алып килсеннәр дип, Хафиз бик тәртипле утырырга тырыша, күнегүләрне пөхтә эшли, янәшәсендәге балаларга да ярдәм итә. Тәнәфесләрдә дә чабып, уйнап йөрми, дәрескә хәзерләнгән әнисе тирәсендә кайнаша.

Галимәбану аны һәр көнне мәктәпкә алырга кыенсына. Яшь директор мондый гадәтне өнәп бетерми. Балалар бакчасына гына йөртәсе дә үзен. Әле анысы кайчан төзелер... Югарыга язып та, рәиснең үзеннән сорап та карадылар. Йөк кенә урыныннан кузгалмады.

Галимҗанының да эше көйсезрәк: Каенлыктан биш чакрым ераклыктагы Үзәнкәйдә МТС җитәкли ул. Көне район буенча йөреп уза. Хатыны, балалары янына да эңгер-меңгердә генә кайтып керә.

Керми — ишектән уза да егыла. Йорттагылар белән сөйләшер хәле дә калмаган була. Балаларның олылары аны күрми генә үстеләр. Инде менә монысы да...

Шул турыда уйлый башладымы, Галимәбануның күңелен моң баса. Үзәнкәйгә эшкә җибәрелгән Галимҗанга чыкканда, икенче районга караган Каенлыкта яшәрбез дип һич тә башына китермәгән иде. Әтиләренең нигезе нык. Егетләр төп йорттан китеп беткән. Барысының — үз эше, торыр урыны. Авылда калган Габделкаюм абыйсы да, гаилә корып, яңа өй салып керде.

Галимәбану дигәнчә барып чыкмады шул. Үтә горур Галимҗан кыз йортына бару түгел, ата-баба яшәгән нигезне күчерүгә дә каршы иде. Инде хатыны авылында яшәүне әйтеп тә торасы юк. Шулай итеп, Галимәбануны таралып беткән каралты-кура уртасында берүзе кукраеп утырган йортка килен итеп төшерде. Үзеннән сорамый-нитми дә, икенче көнне үк, район үзәгенә барып, эшеннән исәп-хисап ясатты һәм Каенлык башлангыч мәктәбенә мөдир итеп билгеләгән боерык тотып кайтып та керде.

Үзсүзле, эшкә булган, кирәген табучы Галимҗан белән гомер итүе кыен да, җиңел дә иде. Киям дисә — киеме бар, ашыйм дисә — ризыгы җитешле.

Тиз арада абзар-мунча да, яңа йорт та өлгерттеләр. Кесә яклары бервакытта да артык юкармады, иллә мәгәр Галимҗан, матди якны мин кайгыртсам, башкасы хатын җилкәсендә дип исәпләде. Какмады, сукмады, өф-өфләп кенә дә тормады. Аның, бик теләсә дә, моңа вакыты да юк — партия боерыгын үтәр, колхоз тормышын кайгыртыр бер җан булып яратылган иде ул.

Ике хуҗалыкка баш булып калган Галимәбану көн дәвамында мәктәп белән йорт арасын тигезләде, кич ялгыз калган әнкәсе янына йөгерде.

Үзе укыткан башлангыч мәктәп бинасын да үзе сипләтте ул, койма белән әйләндереп, ишегалдын да үзе ясатты, балаларга күз алдында уйнарга бер җир булсын дип тырышты.

Укучылар саны арткач, мәктәпне сигезьеллык итү хәстәрен күрде. Кабинетларын җиһазлады. Инде барысы да булды, укыт та укыт кына дигәндә, аны директорлык вазифасыннан азат итеп куйдылар. «Галимәбану апа, син бик әйбәт эшләдең, мәктәпләргә яшь ир җитәкчеләр кирәк, андыйларны Сезнең кул астында тәрбияләп калу хәерлерәк» диделәр. Булачак директорның завроно туганы икәнлеге турында гына бер сүз дә әйтмәделәр.

Директор әзергә бәзер генә яшәп ятуның кадерен аңлый торганнардан булып чыкмады. Галимәбану апасыннан чишәрлек проблемалар калмаганлыктан, бар белгәне укытучыларның мәктәптә тәүлекнең ничә сәгатен уздыруларын тикшерүгә кайтып калды. Кайчан килә, кайчан китә. Балага ничек белем бирәсең — анысы синең үз эшең. Кәгазьгә язылган, журналга теркәлгән булсын. Район җитәкчеләре килгәндә, директорның йөзе кызармасын.

Укытучыларның кыска кышкы кичләре дә халыктан йомырка җыеп, җыелышка куып, фермада, кәнсәләрдә кизү торып, клубта яшьләр өчен чаралар уздырып үтә иде. Урыны өчен җанын да бирергә әзер директор аларның санын тагын да арттырды, сәбәп табып, калхузның бер генә эшеннән дә баш тартырга җөрьәт итмәде. Тыштан караганда бернинди бәйләнеш булырга мөмкин түгел тоелса да, мәктәп белән рәиснең исәпсез-хисапсыз җепләр белән тоташтырылганлыгын аңлый иде ул.

Район җирендә, гадәттә, калхуз рәисе — Фәлән Фәләнов, авыл советыныкы — кодасы, мәктәп директоры — баҗасы... Ә бу — әллә кайдагы авылдан килеп төшкән, яңа гына институт бетергән малай, һәм авыл беренче көнне үк тоттырган дәрәҗәне саклау аның өчен бик мөһим иде.

Директорның иң игътибарда тоткан кешесе Галимәбану апасы булды. Аны мактаулары, аны сагынулары, аңа хөрмәтле карашлары белән Каенлык кешеләре гомере буена җанына тоз сибәсен уйлаганда, күзенә йокы эленмәде.

Каршысына очраганда, яртылаш бөгелеп, исәнләшеп китсә дә, берничә адымга ераклашканнан соң, теш арасыннан гына бер тәмле сүз сыгып чыгарып, җиргә төкереп куярга гадәтләнде.

Үзе аны җыелышларда яхшы яктан гына телгә ала, остаз дип башкаларга үрнәккә куя, әмма уенда, ничек тә гаебен табып, аннан тизрәк котылу иде.

Галимәбану да моны белә, белгәнгә күрә, һәр адымында кечкенә генә ялгыштан да саклана, секундлап дәрескә керә, эшенә сәгатьләп алдан килә. Гомерен багышлаган мәктәптән аерылу аның өчен үлем белән бер булганга, бөтен сабырлыгын җыеп түзә. Әле балалар да кечкенә, аякка бастырасы бар дип уйлый. Күзгә артык бәрелеп тормаска, үзара гауғаларга кушылып китмәскә тырыша. Туктый белмәслек итеп борылган сәгать кебек, үзалдына гына карап, укучыларына тәрбия, белем бирүдә иде.

Уйларына батып, капка төбендә туктап калганлыгын абайлаган Галимәбану тагын тәрәзәгә карады. Хафиз инде, җылылык торбалары өстеннән шуышып, уртадагы тупсага күчкән, әнисенең дә урыныннан кузгалуын көтеп тора.

Ана аңа соңгы тапкыр кул изәп елмайды. Ул да аңлады булса кирәк, җавапка күзләрен кыскач, тәрәзә төбеннән төшеп китте. Менә ул, диванга утырып, кулына китап алыр, бер дә булмаса рәсем ясарга утырыр... Шул уйлар белән Галимәбану бу иртәдә тагын мәктәпкә таба атлады.

* * *

Әнисе күздән югалганчы ук тәрәз төбеннән төшеп киткән Хафиз, нишләргә белмичә, өй борынча йөрергә тотынды. Бүген әтисе, төш вакытында кайтып килермен, дигән иде, әллә электр чәйнегендә чәй кайната торыйммы, дисә дә, соңыннан бу уйдан кире кайтты. Иртә әле. Уникегә бик ерак. Малай, сәгать минутларын бик төгәл исәпли алмаса да, кече теле иң өскә килеп җиткәндә, төш турысы икәнлеген яхшы белә иде.

Кече як тәрәзәсеннән ишегалдында кытаклашкан тавыкларны карап утыра башлады. Шул карашы белән текә кикрикле әтәчне сагайтты. Башын бора-бора, Кызылтүш аны, йорт эчен күзәтергә тотынды.

— Тавыкларым янына чыксаң, тәпиеңне тешләрмен әле, дисеңме? — дип эндәшкән булды Хафиз.

Бу эш бераздан аны туйдырды. Тып-тын гына калып, өй астыннан килгән тавышларны тыңларга хәзерләнде. Олы якның идән астында нәрсәдер (комык кына була күрмәсен!), бик тырыша-тырыша, почмак кимерә.

Тавыш торган саен катылана барды. Инде аның өйдә, диван астында икәнлеге дә аңлашыла башлады. Тычкан бу, билләһи!

Аягындагы башмагын салып, Хафиз ишектән генә диван тәпиенә томырды. Тавыш тынды. Ул да булмады, кечкенә генә тычкан малае, диван астыннан чыгып, сервантка таба йөгерде һәм шуннан, мөгаен, үз өенә дә кайтып киткәндер.

— Бу эш тә бетте, — дип куйды Хафиз. Әле домино тезәргә, шырпыдан өй ясап уйнарга, ватык радионы актарырга, китаплар карарга була иде, тик көн саен бер башкарып чыга торган эшләргә кул селтисе итте.

Шөгыль тапмыйча, бер бүлмәдән икенчесенә кереп-чыгып йөргәннән соң, өстәл өстенә басып, сәгатьнең телләрен унике турысына китереп куйды. Әтисе тизрәк кайтсын, янәсе.

Хафиз әле вакытны кем санатканын, ни өчен бөтен кешенең сәгате бертөсле йөргәнен аңламый, аны алдап, үзгәртеп була, тик моның өчен авылдагы сәгатьләрнең барысын да бер үк вакытта кирегә чигерергә генә кирәк дип саный иде.

Малайлар белән сүз куешасың да олыларны хитрит-митрит итәсең! Ә менә радионы нишләтергә? Ул да көн саен сәгать әйтеп тора бит. Авылда булган бер-ике генә радионы ватып котылырга да була иде. Шулай итеп, радио мәсьәләсе Хафиз башында туып килгән шәп планны өзде.

Тышта яз. Өйдә әле аның исе юк. Түбәннән күтәрелгән, базга салган бәрәңге чыгарган һава, кыш буе тупланган тузан исе генә. Алай да бүген көн тагын да матуррак буласы. Әнисе генә менә ул мәктәптә чагында урамда уйнап йөргәнне бер дә яратмый. Мин синең өчен кайгырып торам, ди. Ә менә бер генә сәгать уйнаса, белми дә калыр. Белсә дә, соңыннан инде үпкәләми. Бер сәгать нәрсә инде ул?!

Хафиз өстенә абыйсыннан калган иске свитерны киде, башына әтисенең шакмаклы кепкасын элде. Кедалары баскыч төбендә калган булып чыкты. Яңгыр явардай түгел дә, җылы, кояшлы көннәрдә аларда иске аяк киемнәрен эчкә кертү гадәте юк. Бик озаклап, тырышып, алай да акай-чукай гына кеда бауларын бәйләгәч, Хафиз урамга элдертте.

Күрше малае Илгизәр инде күптән тыкрыктадыр. Аның да әбисе юк, әти-әнисе — укытучылар.

Шулай булып чыкты да. Башта алар икәүләшеп мәктәпкә бармакчы иделәр, тик Хафизларның ишегенә эленә торган зур йозакны тапмадылар. Бик урынына чыра кыстырып кына еракка китәргә ярамас. Әнисе, соңгы вакытта урамда чегән хатыннары еш күренгәли башлаганга, йортны бикләмичә калдырганны яратмый.

— Башкаларның күз-колак булыр кешесе бар, безнең бөтен ышаныч — синдә, Хафиз, — диде ул әле беркөнне генә, ишегалды уртасында кояш астында су талыктырырга утыртылган чиләкнең юкка чыкканлыгын белгәч.

Малайлар, икесе генә уйнарлык уен уйлап тапмагач, иптәшкә Сәрияне чакырырга булдылар. Елаграк, иркәрәк кызыйны, башкалар мәктәптән кайткач, үз араларына кертмиләр дә югыйсә. Йөгереп уйнауны яратмагангамы, Сәрия качышлы белән кызыктырды:

— Сез беркем дә тапмый торган җиргә качасыз, мин тилергәнче эзлим!

— Тиле дип әйтергә ярыймыни, дурак! — диде аңа каршы Илгизәр. — Әшәке сүз бит ул!

Сәрияләр, башка авылдан күчеп килгәнгә, Каенлык кешеләре әйтми торган сүзләрне дә кыстыралар. Бу авылда әшәкенең әшәкесе саналган тиле сүзен дә балалар арасында ул гына әйтә иде. Хафиз кычкырып көлде:

— Юләр дә, тиле дә, дурак та — бер үк сүз инде ул, ди әни. Бәйләнмәгез Сәриягә!

— Менә минем әни әйтми! — диде Илгизәр. — Нинди начар сүз әйтсәң, шул кешегә әйләнәсең дә ул!

Буйга озынрак, яше дә бераз зуррак Илгизәр үзен гел дә башкалардан өстенрәк тотканга, Хафиз каршы төшеп маташмады, кул гына селтәде.

Малайлар бушаган он ларына кереп шылганда, Сәриянең әче тавыш белән санаганы һаман ишетелә иде әле. Менә ул санаудан туктады, инде эзләргә керешкәндер. Шактый гына көткәннән соң, Илгизәр, кызны күзәтү өчен, лар капкачын күтәрмәкче булган иде дә, капкач ачылмады.

— Беттек, малай, келәсе төшкән, бикләнгәнбез!

— Ярар, Сәрия, ишегалдына кергәч, ачып чыгарыр әле...

Шулай дисә дә, Хафиз да пошаманга төште. Кызның Әүхәт абыйларының ташландык каралтысына кергәнен нихәтле көтсәләр дә, аяк тавышлары ишетелмәде. Лар янына килгәч куркытырга дигән хыяллары да тормышка ашмады. Кычкырып-кычкырып карасалар да, беркем дә ишетмәде бугай. Килүче, эндәшүче табылмады. Кычкырганнары да үзләреннән еракка ишетелерлек түгел — хәлләре беткән иде.

— Сәрия! — дип кычкырды Илгизәр бераздан, соңгы көчен җыеп, ларда һава тәмам беткәч.

Малайлардан шабырдап тир акты. Күлмәкләре тәннәренә тәмам сыланган иде.

— Сәрия... — дип өстәде Хафиз да, чак кына ишетелерлек итеп. Сәриянең якын-тирәдә юклыгы анык иде. Ларның бер почмагында кечкенә генә кадак тишеге тапкан Илгизәр:

— Тегендәрәк кит әле, — дип, Хафизны икенче яккарак күчерде дә борынын шул тишеккә китереп терәде. Аннан киемнәрен салып ыргытты. Хафиз да зур авырлык белән свитерыннан, майкасыннан арынды. Аларны бер почмакка өеп куйганнан соң, моңсу гына итеп:

— Илгизәр, синең киемнәреңне дә астыма салыйм әле, йомшакта үләсе килә, — диде.

Дустының сүзеннән күзеннән яшь атылып чыкса да, Илгизәр дәшмәде. Ул яшәп калу өчен көрәшә иде.Исән калырмын дип ныклап ышанмаса да, үзенә эләктереп калырга өлгергән кадак тишегә аркасында, аның өмете бөтенләй үк сүнмәгән иде әле.

Бераздан ул Хафизның, көч-хәл белән тел әйләндереп, дога укыганын ишетте:

— И Ходаем, җанымны алганда, әниемә бәхиллегемне ирештер, мин аңа дөньядан рәнҗеш белән китмим.

Малай шушыңа охшаганрак сүзләрне Галимәбануның әтисе Садрый карт карчыгы белән хушлашканда тыңлап торган иде. Әнисеннән дә кадерлерәк кешесе булмаганга, иң элек күңеленә ул килде.

— Илгизәр, син дә бәхил бул. Муеныма кара еланнар чорналалар. Синең аяк асларыңда да бик күп алар. Җаным чыккач, ычкындырырлар әле. Әти, миңа дип алган мәктәп сумкасын, исән калсаң, сиңа бирсен. Бисмилла... иррахман иррахим... И Хо...

Хафизның утырган җиреннән лар идәненә авып төшкәне ишетелде. Тычкан-фәлән кермәслек итеп шыплап эшләгән савытта берүзенә үле гәүдә янында калу Илгизәргә куркыныч булып тоелды. Хафизны буган еланнардан да куркынычрак... Тик ул инде кычкырып елый да, ярдәмгә дә чакыра алмый, дер-дер генә килә һәм ничек тә кадак тишегеннән аерылмаска тырыша иде. Тора-бара аның аңында дустының бер генә тапкыр суларга ялварган җөмләсеннән башка берни калмады, ул үзе дә аның белән саташа иде инде.

Еланнар, кадак тишеге, Илгизәр үзе, кечкенә Хафиз күз алдыннан үтеп киткән кебек булдылар.

* * *

Галимәбану ашыга-ашыга мәктәптән кайтканда, Әүхәтләр капкасының бераз ачык калдырылганлыгына игътибар итте. Һич тынычлык юк бала-чагадан шул йортка. Йә сүтсеннәр, йә кешегә бирсеннәр, йә үзләре яшәсеннәр иде. Ни җәен, ни кышын кайтып күренгәннәре юк. Туган-тумачаларының төпләнүенә дә ризалык бирмиләр. Яшә син монда, янгыннан, яман күздән, угрыдан саклап.

Кереп, карап чыгыйм мәллә дип тә уйлаган иде, тукталмаска булды. Хафизны ашатып алуга, кире мәктәпкә йөгерәсе бар иде. Сәгать өчтә — педсовет.

Капканы ачуга, ире Галимҗанның аптыраулы карашына юлыкты:

— Хафиз синең белән түгелмени?

— Юк.

— Алайса кайда йөри микән? Төш турыннан бирле көттем. Эшкә китәргә нишләптер күңел тартмады. Менә кайта, менә кайта дип...

— Кайтыр әле, — диде Галимәбану, иренә борчылуын сиздермәскә тырышып. — Алай да син эшеңә китми тор. Безнең бүген — педсовет.

— Атна уртасында да — педсовет, атна ахырында да. Нинди бетмәгән мәктәп бу, ә?!

Болай да җаны ярсыган Галимәбану да гомер булмаганча тупасрак әйтеп ташлады:

— Укытучыга өйләнмәсләр!

Хатынының мондый кыртлыгына өйрәнмәгән Галимҗанның эченә ут төште. Өй борынча ары сугылды, бире сугылды, инде дә кала алмый иде, капкалап, эшенә китеп барды. Галимәбану да мәктәпкә юл тотты.

Җыелыш җыелыш булмады. Әллә аның дәресләренә анализ ясыйлар, әллә икенче берәүнекенә. Галимәбануга, әйтерсең, барыбер иде. Ишетмәде дә, күрмәде дә. Кем нәрсә сөйләде, кем мактады — аңышмады, тыңлаган кыяфәт чыгарыр өчен генә, вакыт-вакыт башын селкеп утыра бирде. Ахырда, түзмәде, беркемгә берни әйтмичә, ут капкандай, ахылдап, мәктәптән чыгып ук йөгерде.

Урамда эңгер-меңгер төшеп килә иде инде. Алар Галимҗан белән тагын капка янында очраштылар. Аның МТСына да, көннең каһәре, әйтми-нитми генә тикшерү килеп төшкән булган, эшләре шәптән түгел иде. Галимҗан, Галимәбану булса да иртәрәк кайтыр әле дигән өметен өзмичә, ары чапкан, бире чапкан, өенә кайта алмаган.

Түр якта ут элдерелмәгәнлектән, кеше юклыкны аңладылар. Артларыннан ук Сәлимә килеп керде.

— Безнең Илгизәр сезнең Хафиз белән түгелме?

Балаларның кайдадыр бергә икәнлеге аңлашылды. Тик кайда? Бөтен урамны аякка бастырсалар да, ни Хафиз, ни Илгизәр табылмады. Куркудан тиле рәвешенә кергән Сәриядән торып-торып кына сүз чыкты:

— Без качышлы уйнаганыек, мин тапмадым да кайтып киттем...

Галимәбануның йөзенә кан йөгерде. Ул үзен-үзе белештермичә әйләнде дә Әүхәтләр капкасы янына килде, әйләнде дә килде. Эченә керерлек хәле юк, аяклары исә башка җиргә илтмиләр иде. Су буйлары, урман эчләре калмады. Ике баланың берсе табылмады. Галимәбануның гел бер урында таптануын күреп, каралтының астын өскә дә әйләндерделәр, тик файдасы гына булмады. Ахырда күршеләр:

— Борчылма инде, Галимәбану апа, табылыр, без аннан карадык, юк, башка урамда берәрсендәдер әле, — диештеләр.

Шул чакта Галимәбануның колагына Хафизның:

— Әнием, хуш! — дигәне ишетелгәндәй булды да, ул, күзен-башын акайтып, ишегалдына атылды һәм лапас уртасында кукраеп утырган ларга ташланды. Капкачын күтәрерлек хәле булмаганга, янәшәдәге такталар өеменә килеп егылды.

Ирләр, ларны ачып, Илгизәрнең ярым үле, Хафизның җансыз гәүдәсен өскә чыгардылар.

Төн узып, таң атып килгәндә, Галимәбануны да хушка китерә алдылар. Ул барысын да аңлаган, әмма күз яшьләре барлыгын оныткан һәм өнсез тора иде.

Дәшмәде-нитмәде Галимәбану. Үзе өчен алдан хәстәрләнгән үлемтек сандыгына юнәлде. Төш турысына мәетне җирләп тә куйдылар. Ананың кап-кара, тез турысыннан толымы кичкә җитен учмасына әйләнгәнлек кенә аның хәсрәтенә чик-чама юк икәнлекне күрсәтә. Икенче көнне Галимәбану, дәфтәрләр белән дыңгычланган авыр сумкасын күтәреп, мәктәпкә китте. Туктап, тәрәзәгә күтәрелеп карый алмады, әмма алмашынган бер кыяфәт белән елмаеп:

— Мин хәзер кайтам, исән-сау тор, — диде.

...Ел арты ел узды. Төпчек булып дөньяга килгән Гали дә Хафизның хәсрәтен оныттырмады. Башта аны да Хафиз дип атамакчылар иде дә, гомере кыска булудан куркып, бу уйдан кире кайттылар. Галимәбану белән Галимҗанныкына охшатып, әйтергә дә җиңел, кыска да, дип, Гали исеме куштылар.

Бу бала тыныч, уйнарга атлыгып тормаучан, гел өстәл тирәсендә мәш килә торган, китаптан аерылмаучы өй корты булып үсте. Мәктәбеннән бушый алмаган Галимәбану аның шундыйлыгы өчен куанып бетә алмады. Хафизга охшавыннан, терелегеннән курыккан иде, алай булмагач, Аллага шөкер, дип юанды. Директор сүзләр дип тә тормады, үзеннән беркайчан калдырмады. Хәер, инде ул да, урынына шактый нык береккәнлеген, бу авыл кешесенә әйләнә барганлыгын күреп, шактый йомшарды. Гаилә дә корып җибәргәч, хатыны, балаларын әле бер, әле икенче кешегә калдырып, мәктәпкә чаба башлагач, башкалар хәлен дә бераз аңлый башлаган иде.

Әнисе белән сөт планына кул куйдырып, хуҗалык итүчеләргә йомырка бурычларын исләренә төшереп, бер җыелыштан икенчесенә йөри торгач, Гали дә исәйде, мәктәпкә барыр яшькә җитте.

Авылдагы һәр кешенең исем-кушаматын белгән, холык сыйфатлары турында такмазалар әйтеп шаккатырган, уку-язудан, рәсем ясаудан башка тора алмаган малайга күрше-күләннең дә хөрмәте зур, олы кешегә караган кебек карыйлар иде.

Урамнан узып барганда, кайбер апайлар, туктатып:

— Галимәбануның кече баласымы син? Ай-яй нинди зур икәнсең! Ничәнче класста укыйсың? — дип сорамыйча калмыйлар. Яшен чамалауларын белсә дә, Галинең ачуы килми, иренмичә, матур, тәфсилле итеп җавап бирә. Күңелләренә шуның белән тагын да ныграк үтә иде.

Гали беренче сыйныфка, Галимәбануның бәхетсезлегенә, үз сыйныфына эләкте. Күп белүе белән башкаларга комачауламасын, мөстәкыйль шөгыльләнсен дип, Галимәбану аны почмакта аерым торган партага ялгызын гына утырткан иде, әмма иптәш тиз табылды. Каяндыр ерактан, Әүхәтләр пуҗумында яшәргә дип, яртылаш үзбәк, яртылаш татардан чыккан, нәсел башы Каенлыкныкы булган бер ханым кайтып төште. Кирәкле кәгазьләрен үзләре белән алып кайтырга өлгермәгәннәр икән. Артыбыздан ук килеп җитәр дип ышандырып, директорның кушуы буенча, Галимәбану классына алып керде.

Күрер күзгә җиде-сигез яшьлекләрдән аерылып торган бу баланы, күңеленә ниндидер шик килеп, бераз карулашып торса да, укытучы биреште, өстән дә кушылгач, чирек ахырында билгеләр чыгарырга кирәк булса да, Ходайбирдене класстагы бердәнбер буш урынга — Галие янына утыртты. Татарчага да өйрәтер, белмәгәне булса, төшендерер дә, диде. Һәм шулай булды да.

...Галимәбануның бик тыгыз көннәре иде. Үзәнкәйдә берүзе яшәп яткан әнисенең хәле хәл. Көн саен янына барып, өен җыештырып, ашарына пешереп, суын китереп йөри. Хафизны ялгыз калдырудан туган хәсрәт күңелендә таш булып утырганга, Галине дә гел үзе белән ияртә. Менә бүген дә, чәйләп алуга ук, әбиеңнәргә барасы бар, дип ашыктыра башлады. Галие аңа башка чактагыдан акрынрак кыймылдый һәм бераз сәеррәк тә тоелды.

— Әнием, мин өйдә генә калыйм әле, — дип, иңнәренә үк килеп сарылды ул бераздан. — Галимәне корт чактымыни:

— Юк, юк! Нинди калу! Әйдә, киен!

— Минем бер дә барасы килми, дәресемне дә юньләп хәзерли алмадым, аяк-кулларым да арып тора...

— Чанага утыртып менәрмен, үзеңә дә күңелле булыр, — дип сөендергәндәй итте аны Галимәбану. Әнисен кызганыпмы, чыннан да, чанада бару кызыктыргынмы, Гали ризалашты, җылы киез итекләрен, тире бияләйләрен, колакчынлы бүреген бик тә җиренә җиткереп киде дә, астына иске шәл салып, чанага барып ятты.

Галимәбану:

— Утырып бар инде, улым! — дип караса да, анысын тыңламады.

Ана иртән генә шат көлеп торган баласының инде утырырлык та хәле булмаганлыгын аңлап бетерми иде. Үзәнкәйгә барып җиткәч, аның агарып каткан йөзен, авызына килгән күбекләрен күргәч кенә үкереп елап җибәрде:

— Ходаем!

— Әнием, тамагым... Мине сөйләштермә, — диде дә Гали, башка сүз кайтармады. Тиз генә фельдшер кызны дәштеләр. Грипп дигән диагноз билгеләсә дә, ул хәвеф беләнрәк:

— Дифтерия булмаса ярый инде, — дип куйды. Галимәбану, улын тагын чанага салып, авыр хәлдәге анасына да юньле сүз ката алмаган килеш, кире Каенлыкка йөгерде. Баш астына колак мендәре куеп, диванда черем иткән Галимҗанны да бик кисәк уятты:

— Атыңны җик, районга чап, малай үлә!

Әйткән сүзләреннән Галимәбану үзе дә дертләп китте. Галимҗанның аты болай да җигүле, эш белән каядыр китәсе булганга, тыкрык коймасына бәйләп куелган икән, малайны чанага чыгарып салгач, Аккашны бөтен көченә район үзәгенә куды.

— Ничек тә исән-сау илтеп җиткерергә! — Эченнән бертуктаусыз әнә шулай дип кабатлады.

Кабул итү ишегенә өч-дүрт тапкыр саллы йодрыгы белән суккач, ишек тәрәзәсе яртылаш кына ачылды да аннан кемнеңдер мыгырдаганы ишетелде:

— Ял дип уйламыйсыз, кайсыгыз баш катыра тагын?! Көн беткәнме?!

— Малай үлә! — дип ачыргаланды ата кеше.

— Барыбыз да үләбез! — диде ишек артындагы һич кенә дә йомшарырга уйламаган тавыш.

— Сабый үлә! — дип ачыргаланып әйтелгән икенче җөмлә тәэсир итте булса кирәк, ишек ачылды да, Галимҗанны эчкә уздырдылар.

— Үлсә, үзегез янында үлсен, иртәгә утыз бере, бүлнискә врач килер, дип беләсең мәллә? Әйдә, кер, кал, мине генә борчыма!

Галимҗан:

— Боз, янам, янам... — дип пышылдаган Галине коридор башындагы караватка илтеп салгач, тыштан идәндә торган ниндидер тазга тутырып, кар алып керде. Бер уч кар «эх» дигәнче эрде дә төште, эрде дә төште. Баланың киемнәре, төренеп яткан юрганы юешләнеп бетте, әмма ләкин ул боз сораудан туктамады.

Таң атты. Аның ютәлен үз күкрәгендә, тамагында тоеп, көн узды, тагын бер төн үтте. Инде кичә генә каты булып күренгән вахтер карчыкның да күз төпләренә яшь утырды. Кемгәдер шалтыратты, кемгәдер ялварды, әле бер медсестраны алып килде, әле икенчесен... Больницада да Яңа ел башланганга, бүлмәгә кертеп салучы, ныклап караучы, дару бирүче генә табылмады.

Табиблар бәйрәм уздырып эшкә килгәндә, Галинең җансыз күзләре йомдырылган, хәерсез ютәл тынган иде.

Үзем эшләгән районга илткән булсамчы, кеме дә таныш бит, ахмак түгел диген инде, дип үз-үзен ашады Галимҗан. Укытучының кемгә кирәге бар? Әле табиблары да — Галимәбану укытып чыгарган балалардыр? Инде аның янына ташка әйләнгән баланы ничек алып кайтыр?

Больницада авыру саклаганда, кемдер атын коймага бәйләп куелган җиреннән алып киткән. Машина белән илтәсе итмәделәр. Бөтен больница карап торган бер төзек машинабыз бар, диделәр. Авылдан транспорт җибәргәннәрен көтеп, тагын хәйран вакыт узды.

Инде көтүнең мәгънәсезлек икәнлеге аңлашылды. Шофер дигәне дә әле Яңа елны бәйрәм итә иде булса кирәк.

...Галимҗан, улын икенче мәртәбә кулына күтәреп, ишектән узды. Шул ук юрган, шул ук ата, бөтенләй башка халәттә каршы алган туган-тумача, күрше-күлән...

Сүзләр артык. Яшьләр юк. Кипкән. Каенлыга менгән чанасына салып соңгы юлга озаттылар. Галимәбану шулай теләде. Ата шулай теләде. Урамда тартып йөргән кебек кенә, янәшә тартып, кабергә алып киттеләр. Болай килешми, дип әйтергә беркем батырчылык итмәде, уйламады да булса кирәк.

Галине бер генә минутка да калдырырга теләмәгән ана, авыл гадәтләрен бозып, зиратка кадәр барды. Еламаган, дәшмәгән, каядыр еракка караган ананы күрү баланы күмгәннән дә авыррак иде. Ул, чананы тартып, зират коймасына кадәр килде дә, калдырып, каршыдагы мәктәп капкасына таба атлады.

Ачык мәктәп ишегеннән узып класска керде, баласының партасына утырып, соңгы вакытта беренче мәртәбә туарылып, үксеп-үксеп елады. Буылып торган чишмәләр ерылгандай, яшьләре чиләкләп акты. Тавышы бөтенләйгә кайтмаска югалганын белмәсә дә, пышылдап кына сыктады да сыктады.

Мәктәпнең икенче башындагы киң коридорда соңгы Яңа ел кичәсе бара иде. Укучыларның шат тавышлары, җыр-бию көйләре ишетелә. Гомер буе шуларга куанган, кеше балаларын кайгыртып, үз баласын карарга вакыты да калмаган Галимәбануның бүген берсенә дә исе китмәде.

Мәктәпкә кабат аяк басмаска, кайтырга да аңа юлны ук онытырга дип, урыныннан күтәрелгәч, өстәлдә яткан кәгазьне күреп алды. Якынгарак килде. Директор кулы белән язылган сүзләрне укымыйча чыгып китәргә генә уйлаган иде, булдыра алмады. Утызынчы декабрь белән имзаланган кәгазьдә:

«Галимәбану апа!

Ходайбирдене сыйныфташлары белән аралаштырмагыз, класска кертмәгез. Ул дифтерия белән чирләгән икән, больницадан качып киткәннәре турында хат килде», — дип язылган иде.

Галимәбану сүзсез калды. Яшьлеген, акылын, балаларының гомерен мәктәпкә биргән хатын-кыз тәүге мәртәбә аңа нәфрәт күзе белән карады. Парталары иләмсез, диварлары шыксыз, бергә эшләгән иптәшләре җансыз булып тоелды. Кабер салкынлыгы иңгән бу мәктәптән, аның эчендә колхоз проблемаларын хәл итеп узган җыелышлардан әллә кая, еракка качасы килде. Бәйрәм уңаеннан укучыларыннан рәхмәт тулы килгән хатлар да, ата-аналарның хөрмәтле мөнәсәбәте дә, балаларның ихластан мәхәббәте дә — барысы да шушы минутта юкка чыккандай булды. Шушы бәйрәмдә кышкы кабер салкынында яткан Хафиз белән Галигә мәхәббәтне, аларның юклыгын боларның берсе дә тутырмый иде.

Нәрсә эшләде ул аларны саклап калу өчен? Нәрсә эшләде аларны белемле итәр өчен? Алар үзлекләреннән укырга-язарга өйрәнделәр, өйдәге китаплардан гына белем җыйдылар, үзләрен үзләре карадылар, чит кеше балаларын караштылар. Башкалардан карусызрак, хокуксызрак, йомшаграк булдылар.

Укытучы баласына анысы да, монысы да ярамый икән. Аның балачагы да булмый, аның туңганда кулларын җылытучысы да, арганда хәленә керүчесе дә юк. Ул мәктәп белән өй арасында, парта артында үсә.

Дустына каршы төшеп, кадак тишегеннән бер тапкыр сулу алырга да җөрьәт итмәгән Хафизы, кемлеге дә билгесез бер балага дәресләр биргән Галие шулкадәр кызганыч, аңлатып бетермәслек кызганыч тоелды.

Фонарь яктысында дәфтәр тикшереп үткән кичләр, ферма йортында кизү торган төннәр, кояш чыкканчы ничә кат суга илткән чишмә юллары тезелеп күз алдыннан уздылар. Ананың үзе өчен дә сулар һавасы шушы ике нарасый белән киткән, дөньясы үзе бер тап-тар, эш өчен генә ясалган читлек булып калган иде. Әнә шул читлекнең һәрьягыннан аңа таба, муенына сарылырлар да соңгы сулышын да алдырмаслар кебек, еланнар шуышты да еланнар шуышты. Тыны буылган, хәле киткән Галимәбану өстеннән ишелеп кенә төшкән пәлтәсе өстенә утырды.

— И Ходаем, гөнаһлы уйларымны кичерә күр, — диде ул, кофта изүенең сәдәфләрен ычкындыра-ычкындыра. — Балаларымның рухын шат кыл.

*2002*

## Дагалы дулкыннар

*Үзе каккан дулкын*

Бер кочагыңа кергән дулкын кабат синеке түгел. Лепердәшеп-йөгерешеп киләләр дә, «без монда булдык» дигән шикелле, көмеш-мәрҗәннәр калдырып, диңгезгә йөгерәләр. Ул да булмый, зуррак дулкыннар өере, әлеге мәрҗәннәрне дә ияртеп, кирегә — үз оясына, диңгез кочагына ташлана. Диңгезнең тут комыннан аерылмый да башлаган аякларым алар артыннан чабарга, җитез кулларым берсен генә булса да тотып калырга уйлап та карамый.

Кочагыңа үзе килеп кергән дулкын барыбер синеке түгел.

Миңа рәхәт — хәлсезләнгән, ярым йокылы аякларым дулкыннар иркендә. Мәңге бетмәс тоелган шушы халәттән айнытып җибәргән синең дәшүеңә дә җавап кайтарасым килми. Үпкәләгән булып кылanучы күзләремне кысып, сүнеп барган кояшка карап ятам.

Кояшта дулкыннар сурәте юк. Минем тәнемдәге дулкыннар сурәте юк.

Кояш — утлы дулкыннар өермәсе. Кояш — минем җанымның адашы.

— Кочагыңа үзе килеп кергән дулкын барыбер синеке түгел! — дип, аңа да кычкырасым килә.

Поезд мине, текер-текер генә атлап, Кукмарага алып кайтып бара. Эч поша. Җан тынычсыз. Каршыма утырган авыл агае сәгатьләр буе нәрсәдер сөйли. Аннан тозлы тир, абзар исе аңкый. Кайракланган көртиенә текәлеп утырсам да, мин аны тыңламыйм, ишетмим. Әмма ихластан яшьлегемә, озын кара чәчләремә сокланганын тоям.

Мин инде моңа гадәтләнгән. Шулай да вакыт-вакыт, шушы кызны да кешеләр яратмый башласа... дигән уй, йөрәгемә шом салып, гүя тәнемне аркылы кисеп үтә.

Мин мине генә яратканнарына гадәтләнгән. Мин — минминлеләнгән бер авыл кызы. Миңа бар нәрсә дә килешә, дип уйлаганга, үземне бик иркен тотам. Гаҗәпләнер дәрәҗәдә ирекле.

Әле дә менә сәгатьләр буе сөйләп утырган сүзләрен һич тә игътибарга алмаган җөмлә әйтәм булса кирәк:

— Бу көртли тавыкның тәпиләре төрле озынлыкта, ахрысы?

Агай чәчәк кебек җыерылган күзләрен тагын да кыса төшә:

— Кызым, сиңа бер-бер хәл булдымы әллә? Авырыйсыңмы әллә?

— Юк ла, бигрәк нык титаклый ич, көртли тавык өстендә кайтканнан бер дә ким түгел, — дип кычкырып көлеп җибәрәм. Шунда кылт итеп бабамның биреп калдырган фатихасы искә килә.

— Кызым, күргәнең-белгәнең булмаган кешеләр арасында берүк кычкырып көлмә, — дигән иде ул. — Җиңел акыллыга санарлар. Минем кыз икәнлегеңне белмиләр ич әле алар. Араларында начар кешеләр туры килеп, зыян сала күрмәсен.

Эш белән киемнәре керләнеп беткән карт, үзен көч-хәл белән сөйрәп йөргән авыл агае миңа нинди зыян салсын инде, дип уйлыйм. Үзем, аны тагын да ныграк аптыратып:

— Минем бабам — бик тапкыр, җор кеше, — дип әйтеп куям. — Менә минем кебек...

Титаклаган аксак поезд сүзләремне бүлә.

— ... гел көлә дә көлә иде. Күп көләсең, дип, яшь чагында мәчет астына ябып куйганнар.

— Хәзер мәчетләр юк шул, кызым. Үсә төшкәч, үзең бер акыллылансаң гына инде...

Мине яраткан әтием, синең тавышың — чәчәкнеке кебек, әллә ничә төрле итеп чыңлый, дигән була иде тагын. Чәчәк тавышын да ошатмагач...

Эче поша башлаган кулларым кесәмә кереп китә. Анда Арча вокзалыннан Кукмарага кадәр алынган билет бар. Бер сум кырык тиенлек ул билетны миңа югалтырга ярамый. Хөкүмәт абзаң үзе түләячәк аңа, дим мин эчемнән, үземне әһәмиятле бер зат санап. И-и-и, апаеңның кая барганын, кем икәнен бу авыл агае белсәме?! Шундук, карчыгымның туган көненә бер шигырь чыгар әле, дип, аягыма егылачак.

Мохер береткамны кыңгырайтып куям да, әфлисун төсендәге курткам белән бөтен вагонның күз явын алып, ишеккә юнәләм.

Агай артымнан:

— Пәтәч, кызым, син төшәсең дәмени? — дип кычкырып кала.

Көлүем кебек үк йөзгә тиз бәрә торган оялчанлык аркасында юньләп саубуллаша да алмыйм. Бары тик:

— Авырмагыз... — дип мыгырданам.

Киткән чакта әтием, озын-озак уйланып торганнан соң:

— Бер әйбердә дә чикне белмисең син, кызым, күңелең бер нәрсәгә дә озак утырмый, укып бетерә күр, — дигән иде. — Шигырь язып, рәсем ясап башыңны катырма. Башта укырга кирәк. Өлгерерсең.

Дөрес әйтә. Ни эшләсәм дә, — көлсәм дә, еласам да, шигырь язсам да туктый белмим мин. Әкияттәге кебек. Әйтерсең, бер-бер серле нәрсә тоттырганнар. Оялсам да, курыксам да, чиге юк. Ә нигә чикле булырга тиеш соң әле ул?!

Менә бу кояш беркөн чыгудан туктаса? Менә бу җилләр беркөн исмәсәләр? Беркөн мин елмаеп тормасам?.. Әнием, гадәттәгечә, шундук:

— Нәрсә булды? — дип сораячак. Кулымдагы төенчегемне күккә чөеп җибәрәм дә, тота алганыма сөенеп, ике баскычны бер итеп, Кукмара урамына менәм. Эчкә, бик тирәнгә яшерелгән эч пошуны басар өчен, тагын да яңгыратыбрак, бөтен кеше ишетерлек сөенечле итеп көлеп җибәрәм.

Район мәдәният йорты каршында мине әти каршы ала. Ул бар да, ул юк та кебек бер уй туа. Каян килеп чыккан соң ул? Минем янгамы, нинди йомыш белән? Әллә төш, әллә өн... Ул да булмый, халык арасына кереп югала. Эч пошуны тагын да арттырып югала. Кесәмнән нәрсәдер төшеп калган шикелле, мин һаман бер тирәдә бөтереләм, үзем туктаусыз аны уйлыйм. Мин әле, еллар узгач, аны шулай бик сәер югалтачагымны башыма да китермим.

Яхшылап агартылган бина каршысында халык быжылдый. Зал да килгән кунаклар, район кешеләре белән тулган. Буш урынга таба атлаган җиремнән туктап калам. Каршымдагы чибәр егетнең күзләрендәге утлы кояшлар куркыттымы әллә?

— Кояш ике буламыни? — дим мин үз-үземә. — Мине сөйгән кояш ике буламыни?! Ә мин сөйгән кояш? Ә кояшны сөйгәннәр?..

Капыл бер уйга киләм дә, хәвефтән сакланган шикелле, алгырак рәттәге урынга барып утырам.

— Туташ, эчкәрәк узыгызчы... Яңагымда утлы дулкыннар өермәсе кузгала. Мине гомеремдә беренче мәртәбә өркетә алган бердәнбер егет яныма килеп утыра.

* * *

— Кочагыңа үзе килеп кергән дулкын барыбер синеке түгел! Мин моны ул чакта ук аңладым, — дим мин Ришатка.

— Аңладың, әмма качмадың.

— Ә син көчле дулкыннар өермәсеннән качып кара! Һич югы, әйдә, сикер диңгезгә, каршы йөз! Минем кадәр генә булса да...

Үзе белән ияртә алмаган дулкын да аяктан ега.

Мин җәһәт кенә сикереп торам да дулкыннар кочагына ташланам. Бер дулкыннан икенчесенә сикерә-сикерә, кире киткән дулкыннар өерендә Ришаттан ерагаям.

Чалкан яту рәхәт. Өстә — кояш. Өстә — җанымның адашы. Әмма аның тәнендә дулкыннар сурәте юк...

Куркак җанлы дустым, моңаеп, сары яр итәгендә басып тора. Ул әле минем шулай җиңел генә аннан кайчан да булса китеп барасымны күз алдына да китерә алмый торгандыр.

* * *

Кичә нәрсә турында бара — мин аны ишетмим, күрмим. Янымдагы күн курткалы егет, башын җилкәмә үк салып, гыйшык сүзләре сөйли. Сул колагымның инде кызарып беткәнлеген сизсәм дә, дәшмим, аны да ишетмәмешкә салышып, зур сәхнәне томалаган пәрдәнең ертыгына карап утырам.

Кызык, мин әтинең артыбыздан ерак та түгел утырганын аркам белән тоям. Бу егетнең төче сүзләрен ишетәме ул, дип уйлыйм. Ияк тирәсендә минем кечек борыным кадәр миң төртеп торган берәү минем исемне дә атады булса кирәк. Авылдагы күрше апабызның авыша башлаган өе шикелле икенче берсе, күз карашы белән залны әйләндереп алып, минем тирәдәрәк тукталгач, бераз тамагын кыргалаган итенде. Аннан бөтенләй башка бер кыз турында сөйләп китте. Сөйләгән саен, башы иелә төште, карашы сөзәкләнде.

— Иптәшләр, әгәр бу шигырьне мин язган булсам, әлбәттә, ул башкача, әйбәт булыр иде. Әйтик, менә болайрак... Әмма ул шулай итеп үзе язарга тиешле. Без аңа ышанабыз... Бу кечкенә иптәш... язу эшеннән тукталып калмас.

Ул да булмый, янында утырган карсаграк буйлысы сикереп торды:

— Агайне, минем шулай язган бер шигырь бар бит. Әле аны сезгә укыган юк. Мәскәүдәге урыс иптәшләр әйтәләрие...

Кызык, шигырьне күбрәк карсак кешеләр яза икән. Менә минем янда утырган бу егет, картаеп юанайса, шундый ук булыр микән?

Менә юләр, мине яраткан кеше юанаямыни?!

— Игътибар белән тыңла, әнә анысы безнең башлык ие... — дигән була егетем.

Башлыгыгыз шундый карсак булгач, синнән киләчәктә нәрсә өмет итәсең? Авызым ерылып ук китте бугай. Гамил Афзалның бер шигыре искә төште. «Яшь үгезнең йөрәгендә сөю дәрте...» дип башлана ул. Менә шулай... Үгез дә биш йөз процент сөт бирүчеләрне эзләгәч... Шулай язган шагыйрь алдамас.

— Тыңлап утыр! Көлмәкче буласың мәллә?

Бик тә белдекледер, ахрысы, зур кеше булыр бу дип нәтиҗә чыгарып куям. Озак та үтми, мине алгарак дәшәләр һәм ике шигыремне укыттырып күрсәтәләр.

Шул урында кичә дә тәмамлана. Мин ыргылам гына дигәндә, озынча буйлы бер адәм сөяктән генә торган куллары белән эләктереп тә ала:

— Рафилә туташ, гафу итегез, бер генә минутка.

Мин дә йөземә җитдилек төсе чыгарам:

— Сөйләгез.

— Сезнең белән күзгә-күз мөһим мәсьәләләр турында сөйләшергә иде.

Күзгә-күз. Мондый зур күзлекләр артында күз дә буламыни тагын?

Ярый әле күн куртка ярдәмгә килә:

— Мөгыйн дус, синең, ни, теге, журналга тәкъдим итәсе фотоң.

Әй, ни, менә бу кызның фотосы... һич тә үзенә охшамаган инде. Кара син аның чибәрлеген!

— Ришат, безнең әле сүзебез бетмәде. Сезнең белән соңрак дәвам итәрбез, — дип, озын сыйрак мине читкәрәк алып китмәкче булса да, куртка эченнән беленер-беленмәс кенә түгәрәкләнеп килгән корсагы белән ул аңа аркылы төшә һәм әллә каян, тирәннән гыжлап:

— Бу — минем туташ-ш-ш, — дип җавап кайтара.

* * *

Мин икенче бер дулкыннар белән Ришат көткән ярга йөзеп киләм:

— Дулкыннар белән бергә ал мине, Ришат!

— Син үзең дулкыннан да шома түгелме соң?!

— Дулкынны яраткан кебек ярат мине, Ришат!

— Ә дулкын минем телемне аңламаса?

— Әйе... Ул синең яңагыңа сугачак.

— Рафилә, син дулкынны учларыңда гына булса да тотып торып кара. Минем бит әле аны тота да алганым юк!

Мин көләм. Иреннәрдә — шул дулкыннардан калган тамчылар. Алар Ришатның аксыл аякларына сикерә дә, үзенә кечкенә генә сукмак салып, сары комга аерым-аерым төшеп югала. Сары яр тәнендә дулкын сурәте бар. Беләсе иде, җаныңдагы дулкыннар нинди икән? Әгәр җаны булса... Әй лә, мине сөйгән комнар җансыз була аламыни? Дулкын-дулкын сары яр аякларымны пешерә...

* * *

Мин, озын сыйрактан да, күн курткадан да ычкынып, бистә урамнары буйлап йөгерәм. Артымнан искән җил:

— Кич киләсе икәнеңне онытма! — дип пышылдый.

Бик озак баш ватканнан соң, мин, кичәгә барырга да, гафу үтенеп, авырганга салышып, кире кайтып китәргә уйлыйм. Өстемә көн дә кия торган чигешле якалы күлмәк, шундый ук кофта, ап-ак колготкилар кигәч, көзге каршына килеп басам да үз-үземне:

— Бигрәкләр дә сабый инде, — дип бәялим. — Көзге чебеш.

Урамда шыксыз. Җилле. Караңгы. Төнлә йөргән яшүсмерләр багана башындагы лампочкаларның берсен дә калдырмаган. Якынлашкан хатын-кыз сагаеп, шикләнеп карый. Кемне дә булса узган саен үзем дә тынычлап бер сулыш алам. Теләр-теләмәс дәвам иткән юл инде яп-якты булып утырган мәдәният йорты каршында өзелә. Китәргә дип киләсемне беркем дә көтмәгән икән. Җирле шагыйрьләр түгәрәге җитәкчесе, йомшак тавышлы, итагатьле генә бер кеше, аеруча үз итеп:

— Рафилә, син мине ике кулсыз итәсең, кичәдән соң калып, стенадагы стендларны җыясы бар, — ди.

Мин калам. Теләр-теләмәс калам.

Менә концерт өлеше башлана. Сәхнә түренә унтугыз урындык тезәләр дә минем күн курткамны нәкъ шуның уртадагысына кертеп утырталар.

Янымдагы, бераз дусрак булып йөргән кыз, Казанда алар арасында кайнап, аралашып кайткан. Һәрберсе турында белмәгән нәрсәсе юк. Кайчан туган, нәрсә язган, кемне сөйгән, кемнән нәрсә өчен көлгән, хәзер кем, кем урыны хакында хыяллана?.. Хәер, миңа алар әллә ни кызык та түгел. Мин үзем күзәтәм.

Менә бөдрә мыеклы, бөдрә чәчле, шактый усал кыяфәтле берсе. Маңгай җыерчыкларын чәч төбенә өйгән икенчесе. Комган кадәр күзлек кигәне, инде бераз танышыбрак алганы, тәнкыйть-мазар язмый микән?! Күзлеген вакыт-вакыт күтәребрәк куйган булып, гел кызларны күзәтә... Шундый зур күзлек артында да күз була микәнни, дип уйлыйм мин кабат. Ул да булмый, иптәш кызым гайбәтләре урта тирәгәрәк җиткәнен чамалап:

— Өйләнгәнме? — дип кычкырып җибәрәм. Минем, бу минутта башыма килеп, көтмәгәндә үземне дә миңгерәткән сорауга ул:

— Инде баласы бар, — дип җавап биргәндә, бөтен дөньям әйләнә башлый.

* * *

— Кочагыңа үзе кергән дулкын мәңге дә синеке түгел.

— Мин менә синеке ич.

— Син хәтта үзеңнеке дә түгел.

— Әгәр мин, бу көннән синеке генә булам, дисәм?

— Дулкынга дага кирәкми!

— Әгәр ул минем нәкъ менә дагасыз калуым булса?

— Мин, ул сүзләрне ишетмәс өчен, яңгыратып көләчәкмен генә!

— Әгәр мин аякларыңа килеп егылсам?

— Аякка егылган дулкын да кире китә.

— Ничек китә алсын ди ул, Рафилә?

— Менә минем кебек. Күзеңә ком сибә дә китә.

Учымда уйнатып торган комнарны мин аның зур ачылган күзләренә ыргытам да сары яр буйлап йөгерәм. Дулкыннар, дагаланган кебек, егылмыйча, юлыма тезелеп кала.

* * *

Мин айныйм. Нәрсә айнытуын әлегә белмим. Күтәрелеп карасам, бушап калган сәхнәнең нәкъ уртасында егетемнең берьялгызы күзләремә багып утыруын күрәм. Зал, аһылдап, нәрсә булып бетәр дигән төсле, безне күзәтә... Үз-үземне белештерми, коридорга ташланам.

Кичә бетә. Истәлеккә рәсемгә төшкәндә, мине аның янына бастыралар. Урынны үзгәрткән саен, алдан сүз куешып куйган шикелле, фотограф кабат-кабат мине шул урынга илтеп куя.

Мин, эзәрлекләүче карашлардан, янәшәдә йөргән иптәш кызымның эчпошыргыч сүзләреннән гаҗизләнеп, кайту ягына юнәләм. Аның торган саен кызулана барган аяк тавышлары мине барыбер куып җитә. Дәшмим. Сөйләшмим. Дер-дер килеп, аска карап торам.

— Калдырыгыз мине-е-е!

Урамда эт тә юк. Аны куркытырга бер җан иясе юк. Ул, рәхәтләнеп, сөю сүзләре сөйли.

— Калдырыгыз мине! Ниһаять, җиңел генә котылмасымны аңлап, иртәгә китеп барасы поездымның вакытын алдап, өемә китәргә рөхсәт сорыйм.

Озаттырмыйм. Кочтырмыйм. Үптермим.

Алдавымны сизепме, Ходай кушыпмы, ул да мин китәсе поездга төшә. Күзләреннән моң саркыган бөдрә чәчле бер шагыйрь, икебезне ике ягына утыртып, кулларын җилпи-җилпи, мәңге бергә һәм мәңге кушыла алмас тимер юллар турында шигырь сөйли. Ике күземнән дә берәр генә тамчы яшь шул ук шагыйрьнең туфли табаны астында таптала.

— Бәхетле бул, дустым! — ди ул миңа. Әллә бәхетсез булыр дип курыкканга әйтә инде?! Нигә укыды ул бу шигырьне? Нәрсә әйтергә теләде?

Мин шул кушыла алмас тимер юллар өстеннән китеп барырмын микәнни? Аларны кызганмыйча ничек чыдармын, дим...

* * *

Сулышым бетеп егылганда, Ришатның да дулкыннар эчендә ятканлыгын күрәм. Диңгез, ул булып, дулкыннар тавышында сулык-сулык елый.

Дулкынга дага кирәкми, дим мин кабат. Дулкынга дага кирәкми! Кайсыбыз дулкын соң? Минме, Ришатмы?.. Мине сөйгән дулкынга дага кирәкми!

Бер кочак диңгезне умырып алып, кояшка ыргыткан сыман итәм. Ә ул әнә инде керт-керт кенә атлаган дулкыннар булып китеп тә бара...

Өстә — кояш. Аяк астында — килеп-китеп йөргән дулкыннар. Аларга дага кирәкми!

* * *

Мин, чыннан да, китәм. Бу көнемнән. Туган ягымнан. Дусларымнан. Балачагымнан. Эчпошыргыч, хәвефле уйлар белән китәм.

Ул минем каршыма — тәрәзә буена килеп утыра. Тәрәзәгә төбәлгән карашымны йомшак куллары белән читкә бора:

— Син шагыйрьләрдән сак бул, сеңлем!

Үзе исә истәлеккә биргән китабына «Гел шулай матур бул, яшь бул, бәхетле бул!» дип язып куя.

Әлегәчә серле күренгән капу алдында торып калуымны аңлый башлыйм. Нинди төстә, нинди сыйфатта ачылыр ул миңа?

Янәшә купедан кырлы стаканнар чыңгылдаганы ишетелә. Бәдрәф каршындагы бушлык инде зәңгәр төтен белән тулган. Шул төтен арасыннан маңгае сырланып беткән шагыйрьнең очсызлы тәмәкесе ап-ачык булып күренеп тора.

Милләт, милләт дигән сүзләр, әллә кемнәрнең миңа карата ниндидер комплиментлары, тир исе, яшел суган, тозлы кыяр, котлет исе — барысы бергә буталып, минем аңымны томалый. Шул ук нәрсәләр томанында мин үземнең тукталышыма чыгам. Минем белән бергә әйтерсең бөтен поезд кубарыла.

Көзге һавага ачып куелган ишек янында:

— Син мине онытмассыңмы? — ди миңа Ришат.

Ул сүзләрне инде күтәрерлек хәле калмаган керфекләрем аска бөгелә. Миңа бу дөньяда авыр, бу дөньяда урын тар икәнлеген аңлап, поезд туктап беткәнен дә көтмәстән, платформасыз тукталышка сикерәм.

Яңа таңны искәртеп шалтыраган телефон икенче көнне мине:

— Онытмадыңмы? — дип сәламли. Кемне? Нәрсәне? Ни өчен?

— Калдырыгыз мине-е-е... Калды-рыгыз-з-з!

— Эх, син... Ризалык билгесе итеп керфекләреңне төшергән идең тагын... Син дә мине аңламагач?! Тимер юллар, чынлап та, кушыла алмый икән шул...

Тамагыма тыгылган төерне тышка бәреп:

— Үзе кочагыңа килеп кергән дулкын барыбер синеке түгел! — дип кычкырам да телефон төребкәсен атып бәрәм.

Бераздан кулыма алган төребкәдә шул дулкынның өзек-өзек сулкылдаганы ишетелә.

* * *

Мин, комлы ярга яткан килеш, бөтенләйгә китәм дип исәпләгән көннәрем турында уйлыйм. Үз-үзеңнән китеп булмау турында уйлыйм. Язмышымны дулкыннар кочагына тапшырган бер төн турында уйлыйм. Юеш ярда йөрәк эченә парлы рәсемебезне ясагач:

— Теләсә, дулкыннар безне бергә калдырсын, — диган идем. Алар әнә шул җансыз сурәттән дә Ришатның гына йөзен бозып китте. Ә мин, эчемдәге утлы кояш, бугазымны ертып, күккә ашмасын өчен, бөтен нарат урманын яңгыратып каһкаһәләп көлдем генә.

— Дулкын мине синнән аерды, Ришат!

— Мин синсез ничек яшәрмен, Рафилә?! Син минсез ничек яшәрсең?

Хәтерлисеңме, ул чакта да мин синең кара күзләреңә тозлы сары ком сибеп качкан идем. Елатып. Кочагыңа үзе кергән дулкын синеке буламыни, Ришат?!

Шуны аңлаганга качкан идем... Дулкыннан дулкынга сикереп, тауларга менеп киткән шәфәкъ кояшы шикелле...

Ә ул кояшта дулкыннар сурәте юк. Кояшта синең сурәтең юк. Кояш — үзе утлы дулкын. Кояш — минем җанымның аваздашы. Кояш кочагына кергән дулкын барыбер аныкы түгел! Керергә җөрьәт иткәндә дә...

## *Чияләнгән көз*

Көзләрнең әле болай бер дә ямьсез булганы юк иде. Яңгырның тамчысы таммаган көнне дә күге — болытлы, җиле — салкын, кояшы төссез күренә.

Без Ришат белән янәшә Тау асты чишмәсеннән күтәреләбез. Чиләккә су тулганда кочаклап алган иде. Сискәндереп. Өркетеп. Чиләкләремне күтәреп менсә дә, бармаклары җилкә өсләремдә калган төсле. Аркамда — кош кебек кунган җылылык. Аскы урамда безне беркем белми. Ул мине күз хәрәкәте белән генә туктата да моңа кадәр бер дә ишеткәнем булмаган җыр җырлый. Мин, оялып, җиргә куелган чиләкләргә карап торам. Әйтерсең лә аларга әле генә парлы чияләр баткан да, мин шуларны эзләп иелгәнмен. Елык-елык уйнаган су өстендә минем иреннәрем йөзә...

Чишмә юлы озын, бик тә озын. Инде көянтәгә менеп кунган чиләкләр, Ришатның салмак җырлары тагын да озынайта аны:

Син кайда идең?
Кайларда йөрдең?
Ничек мин сине күрмәдем икән?
Син торган йортны,
Синең урамны...

Минем урамдагы мин торган өйнең баскыч төбендә җырлавыннан туктаган Ришат:

— Мин китәм инде... — ди.

Нигә китә ул? Кем янына? Ниләр эшләп яши?

— Мин китәм инде... — ди эчкә узарга чакыруыма өметләнгән тавыш. — Яңа шигырьләр язгач килермен. Онытма, яме.

Тагын дөрес аңламас дип, күзләремне йомарга да куркып басып торам. Күңелемдә өлгереп килгән шигырьне аңа зур итеп ачылган күзләрем аша булса да ничек җиткерергә?

Иреннәрең көяр,
        сулуларың кибәр, —
Картаяммы диеп
        уйлама син һич тә.
Иренемдә киткән

сиңа дигән назым
Шулай тынгы бирмәс
сиңа иртә-кичтә.
Иреннәрем төсле —
кызыл парлы чия ...
Үзләре үк өзелеп
төшәр кулларыма.
Үпми киткән иде,
килер әле бер, дип,
Үбәр әле бер, дип
хәбәр салыр миңа...

Ул, артына борыла-борыла, юлга иелгән өрәңге агачлары астыннан миннән китеп бара.

* * *

Иртәгесен укудан кайтышыма дипломатына бер кочак шигырь тутырган дустым мине шул өрәңгеләр астында үк каршы да ала.

— Син арыгансыңдыр инде, без сине чакыра алмыйбыз шул, — дим мин, кыенсынып кына. Моңаешып, кырык ямаулы кызыл йортыбызның күршеләр турысындагы утыргычында утырабыз.

Эңгер-меңгер җитә. Утлар кабына. Алар яктысында затлы киемдәге бер адәмнең, тыз-быз килеп, ишегебез турысына кап-кап күчтәнәчләр ташыганын карап арыгач, Ришат:

— Миңа да ничек кенә шулай җиңел узарга бу йортка... — дип куя. — Машинадан гына төшеп.

— Машинаң булгач инде, — дип көләм мин аннан. — Әмма машинада йөргәндә, син инде мондый шигырьләр язмассың. Юан, тук бер абзый булырсың.

Мине яраткан кеше дә картаер микәнни? Шигырьләр язуыннан туктармыни соң? Карбыз, әфлисун, балалары-оныклары турында гына язар микән?

Аның адымында, аның сүзләрендә әнә шул туклыкка омтылыш бар. Урам чатындагы кунакханәнең тәрәзәсеннән яктылык сирпелүдән туктаганда, мин шундый уйлар белән йокларга ятам. Күзне йокы алмый. Үз шигырем туктаусыз тел очында бөтерелә:

Үпми киткән иде,
килер әле бер, дип,
Үбәр әле бер, дип,
мине исеңә төшер...

Көзге җил тәрәз төбендә яфраклар санап йөри. Кыштыр-кыштыр... Кайвакыт ул миңа тәрәзә пыяласына җиңелчә генә чирткәләп алган кебек. Аның авыр сулышы кагылган форточканы барып ябарга иренеп, йомшак күпчекләрдә ята бирәм. Янымда хуҗа хатынның юеш борынлы малае мышкылдый. Сабыйның аякларын яхшылап төреп куям. Маңгаена төшкән чәчләреннән тирен сөртеп алам.

Сәгать алты. Йокының килмәсенә тәмам ышангач, ашык-пошык кына киенеп, капкалап алам да училищега йөгерәм.

— Сез нигә капрон оеклардан түгел? — ди миңа ишек төбендә кизү торган кыз.

Татарчалап кына:

— Җаныма суык булганга, — дим дә, фамилиямне дә әйтмәстән, әдәпсезлек күрсәтеп, подвалга — чишенү бүлмәсенә төшеп китәм. Ян-яклар буйлап сузылып киткән яшел торбалар өстенә утырам да...

Инде бөрешкән чия кебек калган иреннәремә рөхсәтсез-нисез чыккан яшь тама. Киемнәр арасында мине беркем күрми. Рәхәтләнеп еласаң да була. Тик еларга ярамый. Еларга бервакытта да соң түгел! Җелт-җелт атлап, өске катка күтәреләм. Аннан, рәхәтләнеп, кычкырып бер көләм. Үземнән. Дөньямнан. Ришаттан. Каршыма безнең белән колхозга бәрәңге чүпләргә барган Фәрит Маннапович килүен күргәч кенә, җир тишегенә төшәрдәй булып, беренче ачык ишеккә үк кереп шылам.

Шул ишек төбеннән үткәндә, аның адымнары әкренәя. Әмма мин аның, йөрәге җитеп, бүлмәгә башын сузмаячагын беләм. Коридорга чыкканда, аның мин сөймәгән зәңгәр төстәге, үзенә кечкенәрәк итеп тегелгән костюмының икенче якка китеп баруын күрәм.

* * *

— Мин сиңа шигырьләр китерәм, — ди Ришат берничә көннән соң телефон аша гына. —...Ник дәшмисең? Сөйләшергә теләмәсәң, калдырырмын да китәрмен. Бик тә укытасым килә.

— Уң тәрәз төбендәге гөлегез чәчәк атмаганмы?

Мин ялт кына шунда карап алам. Күз явын алырдай кып-кызыл чәчәкләрен күтәрә алмый, кеп-кечкенә гәүдәсен аска игән ул.

— Каян белдең син аны, Ришат? Ел буе корышып утырган иде, мескенем...

— Төнлә чәчәк атар,

Шигырь укып чыктым

Тәрәз төбендәге гөлегезгә...

— Шаяртма инде. Болай да эч поша.

— Син минем яратуны гомер буе шаяртуга алырсың микәнни?

Ни сөйли ул? Тагын нинди гомер? Әле яши дә башламаган. Әле бер тапкыр егетләрдән дә үптермәгән!

Нинди ярату? Аңа тагын ярату!

Ул мине яратса, көз болай яңгырга китәр идемени? Минем эчем шулкадәр пошар идемени?

— Мин сине мәңге яратмаячакмын! — дим дә инде үзе дә тирләп беткән төребкәне ыргытам.

Мин әле аның ике сәгатьтән соң ук, кыңгыравыбызга басып, ишек төбендә торачагын күз алдына да китермим.

— Нигә килдең, Ришат? — дим мин аңа.

— Сине ратканга!

— Мине яратырга ярамый!

— Нигә, Рафилә? Сине дә яратмагач!

— Юк. Сиңа яратырга ярамый. Сиңа мине яратырга ярамый.

— ...

— Мин барысын да беләм бит, Ришат...

— Әгәр мин яратмыйча булдыра алмасам?

— Кеше булдырмаган эшләр юк.

— Әле син бик яшь шул. Гомерең моның киресен раслар.

— Гомер, бәлки, раслар. Син — юк. Һе... Мин үлеп яраткан кешемә дә ул хакта әйтмәячәкмен!

— Әйтми калырга була ул.

— Син дә, бик җиңел булса, әйтми яшәп кара! Менә, һич югы, миңа әйтмичә!

— Минем сине яратуыма ышандырасым килә!

— Аннан бернәрсә дә үзгәрмәсә дәме?

— Үзгәрер.

— Әгәр үзгәрмәсә?!

— Үзгәрмәсә дә, үзгәрмәсә дә...

— ...

— Яратам мин сине, Рафилә! Яратырга гына булса да ярыйдыр бит?

— Ярамый! — Усал борылып китеп бармакчы булганымны аңлаган Ришат кисәк эләктереп ала да кочагына тартып китерә.

— Ришат! Миңа сине яратырга ярамый-ы-ый...

Өстебезгә чиләкләп яңгыр бәрә. Керфекләр, чәчләр, киемнәр авырайган. Ул кызыккан парлы чияләр өзелгән...

Көчле кулларыннан, иреннәреннән ычкына алмый газапланам. Шушы көзге яңгыр кебек яшьләремне бәреп-бәреп елыйсым килә. Еларга бервакытта да соң түгел...

Яңгыр һаман ява да ява. Безне түбәсез капка да, киң ябалдашлы карт өрәңгеләр дә саклый алмый. Инде хәлсезләнеп аяктан егылам дип уйласам да, кереп киткән чагымда үземә:

— Сиңа! Мине! Яратырга ярамый! — дип кычкырырлык көч табам.

Чияли-чияли бәйләнгән, чияле шигырьләр белән бәйләнгән көз тәрәзә төбеннән уза. Буяулары кубып беткән савыттагы ут явын алырдай чәчәкләр генә миңа аны хәтерләтә. Усал җил төннәрен яфраклар санап йөрми инде. Тәрәз төбендә төн уздырырга ул да батырчылык итми...

* * *

Кайвакыт, түр бүлмәнең диванына утырып, сәгатьләр буе урамга карап торам. Көтмәгәндә җир өстенә яуган карлар әле куышлы уйнап йөри. Соңга калган өрәңге яфраклары да алар белән бергә югары күтәрелмәкче була. Һава авыр, басынкы. Яфраклар кабаттан салкыннан өшегән чокырлы-чакырлы юлларга ята.

Уенчык телевизорыбызга, бер дикторга охшатып, Ришатның рәсемен ябыштырып куйган идем. Үзем югында кемдер бүлмәбездән алып чыгып киткән. Кемгә, нигә кирәк булган ул? Өебездәге бушлыкны бераз тутырыбрак торган рәсем дә калмагач, кемнедер көтә башлыйм.

Тәписез ягына авышкан, калын келәм япкан диванга кырын ятып, үткән көннәр турында уйлыйм. Аксый-аксый барган поездда очраткан бабакайның сүзләре искә төшә.

— ...Үзең бер акыллылансаң гына, — дигән иде ул.

Акыл да кермәде, шуклыгым, чаялыгым да качып китте бугай. Кем капкасын шакый ул акыл, кайда йөри?

Мичтә сүнеп барган шәфәкъның утлы теле уйный. Мин яшәгән йорт Арча урамнары белән бергә төнгә кереп бара. Ут кабызмый гына, берьялгызым каршы алам мин бу төнне. Түр диварга терәп үк куелган көзге, ишеккә карап, кемнедер көтә шикелле.

Көз үтте. Ришат юк. Үзем юк, үзем дә яшәмим шикелле. Шуны аңламаган көзге, күзләрен чекерәйтеп, ишек тоткасына текәлгән.

## *Дулкынга дага кирәкми*

Бер биргән сүзеңдә торсаң икән ул. Килмә, дип әйтә алгач, көтмәсәң икән. Яратма, дип акыл сатканда, үзеңнең дә яратуың турында уйламасаң... Минем яшәү гел үкенечләрдән генә торыр микәнни? Торса соң?.. Түзә алгач...

Көн аклыгына сөенечтә дә түзмәсәң! Быелгы кыш әнә нинди ак! Тыныч. Карлы. Матур.

...Инде тагын бер генә көнен дә миннән башка уздыра алмаган Ришат белән яңа яуган кардан бер-беребезгә шигырьләр сөйләп узарга яратабыз. Дөресрәге, сабый баланы иярткән кебек, кулларымнан җитәкли дә ул мине шул ак дөнья эченә алып кереп китә.

— Син — нәкъ кар кызы инде. Мин кышны синсез күз алдына да китерә алмыйм.

Аның бу сүзләренә никадәрле сөенсәм дә, тышка чыгарасым килми. Агач ботагында утырган кош кебек, чырык-чырык көләм генә.

Арча урамнары кешесез. Кышкы юллар начар, машиналар аз булгач, үзәккә килүчеләр сирәгәя. Безгә тагын да иркенрәк тоела, хисләргә урын киңәя төшә. Озын урамнардан җәяүләп узганда, ул миңа һәрвакыт:

> Син кайда идең?
> Кайларда йөрдең?
> Ничек мин сине күрмәдем икән?
> Син торган йортны... —

дип җырлый. Бу җырдагы үкенеч авазлары минем күңелемдә яшереп саклаган хисләргә пар.

— Күрсәң ни дә, күрмәсәң ни. Язмышың үз кулыңда булмагач... Менә хәзер белдең бит инде.

Җитәкләшеп, мин торган йортның җилкапкасына атлыйбыз. Йортыбыз урам яктан бераз кечерәеп калды. Күршеләрнең каралып, кыңгыр басып торган өйләре бөтенләй кар эчендә. Көнгә чыккан тәрәз кыерчыгында дүрт-биш пар күз барлыгын беләм мин. Иртәгә үк алар арасыннан бер батыррагы: «Мы ему усы сбреем», — диясен дә беләм. Беләм. Курыкмыйм. Мине яраткан кешеләр мине яраткан өчен икенче берәүгә ничек зыян салсын инде?!

— Мин сине яратам, Рафилә! — ди ул, кышкы төтен кебек әкрен генә сузып әле дә.

— Яратты ди...

Баш очында утырган кош пырхылдап һавага күтәрелә.

— Синең һәрнәрсәгә җавабың әзер. Минем өчен дә үзең әйтәсең. Каян беләсең аны?

— Ходай Хавага Адәмне ялгыштан саклау бурычын йөкләгән бит.

— Кайда, нинди китапта?

— Алар әнә оҗмахтан сөрелгәннәр... Кайсы гаеплерәктер?..

— Минем бу алмасыз дөньям — оҗмах мәллә? Синле дә, синсез дә дөньям — оҗмахмы?

— Ә син алмалы дөньяңда яшә. Алма ашап яшә...

— Мин бит сине яратам, Рафилә-ә-ә...

— Мине яратырга ярамаганлыгы-ы-н әйттем бит инде.

— Матурлыкны яратудан тыярга ни хакың бар синең?

— Ник, ул минем матурлык түгелмени?

Дәшмә. Дәшмә. Менә шулай ул. Кукмара кызлары белән сүз көрәштермиләр. Кеп-кечкенә борыным Кукмара тавы кебек текә күтәрелә. Буем Ришатныкыннан кыска булса да, мин аңа өстән караган кебек карап тора алам. Үртәп. Көлеп... Мин аның сәбәбен дә аңламыйм. Эчке гаҗизлек холкымны кыртлата булса кирәк.

Ярата бит инде... ди икенче бер уй. Яратса соң?! Кем яратмый?! Мине дә яратмагач?!

Әллә менә мин дә яратамдыр... Чүттән генә тышка чыкмый калган уемнан үзем куркып китәм. Нинди ярату ди ул?! Булмаганны! Чәчләренә чал керергә торган кешене.

Башымны аның ягына борам да, яратмаслык сыйфатлар эзләп, бик текәлеп карап тора башлыйм. Ялтырап торган затлы туны астында калынаеп килгән гәүдәсеннән башка берни тапмыйм. Шул җитмәгәнмени инде?! Еш-еш сулаган борынына тукталып:

— Мин сине гомергә яратмаячакмын! — дип, яңагына суккандай итәм.

Мин сине гомергә яратмаячакмын!.. Бу сүздән агачка кунган тыныч карлар коелып төшә. Бу сүздән үземнең йөрәктә дә нидер өзелә. Аныкы дөп-дөп тибә башлый.

Без озак вакыт сүзсез торабыз. Дәшсен иде, хет бер сүз дәшсен иде ул миңа! Бәлки...

— Кирәкми, яратма, дисең,
Бик яратмас идем дә... —

дип, Ришат шигырь укып китә. Үпкә белдергәнен көткәндә, бөтенләй башкача әйтелгән сүзләр мине тынычландыра, көнне үз урынына утырта.

...Безне үз кочагында бергә кушып, ап-ак кар ява башлый. Бу ак кыштан мәңге туймабыз, ахрысы. Син миннән туярсыңмы, Ришат? Кыршыла башлаган перчаткаларыңа карап торганда, мин әнә шул турыда да уйлыйм. Син инде аларны бик аз киясең, бияләе юк дип белмәсеннәр өчен, кулыңа гына тотып йөрисең.

* * *

Бу кыш хәтта Казанны да ак төстә тотты. Карны юньләп көрәмиләр. Шуңа күрә башкала җанга якыная төште. Мин анда ешрак бара башладым.

Менә без Ришат белән карлы, буранлы Казан аша мине алып китәчәк электричкага йөгерәбез.

Вагоннар буш. Җылы. Әмма аның калын туны янында тагын да җылырак булганга, терәлеп үк утырам да башымны җилкәсенә салам. Ак береткамнан чыгып торган кара чигә чәчләреннән кар суы ага. Иреннәрем өстендә генә хәл ала ул.

Кышның соңгы буранлы көне икәне башыбызга да килми. Бу буран бер дә туктамас шикелле. Күңелдәге бураннар бер дә тынмас кебек.

* * *

Урамда җылы. Мин, өстемә дә кимичә, ишегалдында йөрергә яратам. Кайвакыт ишек төбендәге утыргычка утырам да авызым белән түбә кыегыннан тамып торган тамчыларны чүплим. Тәнгә кар салкыны, яз дымы үтә. Без яраткан карлар эри. Без адашкан бураннар каядыр китеп югалдылар... Гомер шулай үтә микәнни соң? Бу яшьлектән ни калыр?

Ришат, иртәгә дә киләм, дип киткән иде. Өйалдының тышкы баскычында әнисенең фотосурәтенә карап утырам. Ришат аны миңа бер генә көнгә карап торырга бирде. Син аңа охшагансың. Аның кебек яшәрсең бу дөньяда, дигән булды... Ник алып калдым мин аны? Кулым утка тигән кебек...

Бәхетлеме Ришатның әнисе? Нинди авырлыклар кичте икән ул? Минеке кебек кара күзләре кешеләргә игелек теләп елмаялар шикелле... Ә миңа нәрсә дип тели икән ул? Гаеплиме? Гаебем юклыгын беләме? Ришатка, күңелемә гел каршы килеп яшәгәнлегемне аңлыймы? Әллә бу дөньяда минем барлыкны бөтенләй белми дәме? Юктыр, ана күңеле тоя ул. Һич югы, сизенә торгандыр.

Ни дип дәшим мин бу рәсемгә? Аның күзләренә ничек карыйм? Әнием сине яратыр, дигән иде. Нидән әйтте ул сүзләрне? Нигә әйтте? Әллә әнисе шулай дип әйтергә кушканмы?

Ярамый, ярамый, ярамый... Мине яратырга ярамый. Беркемгә дә. Ришатка да, әнисенә дә, менә бу рәсемгә дә... Фотоны тиз генә сумочкамдагы кәгазьләр арасына салам. Иртәгә үк онытмыйча кайтарырга кирәк. Анлы дөньямны Ришатка кайтарырга кирәк.

Инде бу карар нык. Ничек ирештерергә икәнен генә тәгаен белмим.

...Килеп кергәнендә бәхетнең үзенә юлыккан кебек күренгән Ришат, кәефсезләнеп, аска карап китеп бара. Кал, дип әйтергә ярамый. Бу, мине яратырга ярый, дип әйтү белән бер булачак. Кичер, дип әйтергә ярамый. Бу, мин дә яраттым, дип тану кебек аңлашылачак.

Мине яратырга ярамый! Их, нигә ярамый?!

* * *

Ришатны Кукмарага командировкага җибәргәннәр икән. Поезд безне кабат очраштыра. Әгәр ул утырган вагонга кермәгән булсам... Их, кермәгән булсам, дим эчемнән генә.

Ул юл буе ни хакындадыр сөйли. Мин сүзенә кушылмыйм. Аның белән бергә төшеп калудан куркам, Кукмараны узып китәм

Тау битендәге кызыл вокзалга җитәбез дигәндә, ул да сөйләвеннән туктый, миңа аптыраулы күзләрен теки. Нигә сөйләшми кайттың, дип сорыйсы килә аның. Нигәдер сорамый.

Без бик моңсу хушлашабыз. Күңелдә нидер өзелә. Мин китәм бит, китәм... Ул әле моны белми.

Кая? Кемнән? Нигә китәм мин? Сүз ул турыда да түгел инде. Мин киткәнемне, китәчәгемне генә беләм. Бүген булмаса, иртәгә...

Вагоннар кузгалганда, Ришат:

— Син мине яратасыңмы? — дип кычкыра.

Тәрәзә яңагыннан кергән язгы җепшек кар, яшь шикелле, эреп, битләрем буйлап тәгәри. Яңакларымны салкын тәрәзәгә куям.

— Мин беләм бит, син мине яратасың! — дип кычкыра ул миңа кабат.

Нәрсә белә соң ул?! Мин үзем дә берни белмим һәм белергә дә теләмим!

Миңа яратырга ярамый! Миңа Аны яратырга ярамый! Моңа кадәр башкачарак мең тапкыр әйтелгән сүз бөтенләй яңа мәгънә ала. Мине кайчандыр башка дөньяга алып кереп киткән Кукмара вокзалы артта кала. Үз урыныма барып тормыйм, тамбурга чыгам. Мәңге аерылмаган һәм мәңге кавыша алмаган тимер юллар бөдрә чәчле шагыйрьне исемә төшерә. Ул белгән бит, белгән...

Вокзалның тынчу бүлмәсендә күзләремә карап шигырь укыганнан соң:

— Бәхетле бул, дустым! — дигән иде бугай.

«Әллә шагыйрьләр берсе дә бәхетле түгел микән?» дип уйлыйм мин калган бөтен юл буена.

— Бәхетле бул, дустым! — дим мин үзен миннән башка көн дә яши алмас кебек санаган шагыйрьгә, изге теләкләремне ишетмәсен белсәм дә.

Мине яратырга ярамый! Миңа яратырга ярамый! Аңа ярыймы соң? Ә аңа ярыймы? Яратмаса, бәхетле булырмы ул?..

* * *

Комлы ярда җәй кояшыннан тән каралтып ятканда, бөтенләйгә китәргә дип уйлаган шул көннәрне искә төшерәм. Үз-үзеңнән китеп булмау турында уйлыйм.

— Хәтерлисеңме, җепшек язгы көн, Кукмара вокзалы, катык поездының салкын вагоны... Син минем белән хушлашканда елаган идең... — ди шагыйрем, тезләренә кулларын куеп уйланып утырган бер кыяфәттә.

— Ни сөйлисең, Ришат? Кар суы иде бит ул.

Елады ди! Еларга беркайчан да соң түгел. Соң түгел... Карлар әнә язда көн дә елый...

Нигә салкын кар булып калырга телим соң мин?! Көтеп алган язларда да ничек тә эремәскә тырышам...

— Син гел шулай инде, Рафилә. Күңелне төшерәсең дә торасың. Ә мин, юләр, ярата икән, дип, сөенгән булдым тагын.

— Дулкынны яратып буламыни, Ришат? Үзең бит, кулдан шуа да чыга, дидең. Килә дә китә, килә дә китә шул ул...

— Килергә китә түгелме соң ул, Рафилә?

— Юк, китәргә дип килә, ахрысы...

— Ә мин, калам, дисәм!

— Дулкынга дага кирәкми! Дагасыз дулкын ничек ярда басып торсын ди!

Дулкыннар абыныр өчен яралган. Абынган саен, кире китә ул... Абына да китә, абына да китә...

— Син каян беләсең аны, Рафилә?

— Шул дулкыннар кочагында ятам түгелме соң?

— Ә син аны үзең кочагыңа ал!

— Кочагыңа үзең алган дулкын да үзеңнеке түгелдер шул, Ришат. Дулкын дулкын инде ул. Аңа дага кирәкми!

— ...

— Әнә синең күзләреңдә кояш сурәте бар. Кояшта синең сурәтең юк. Кояшта дулкыннар сурәте дә юк. Кояш үзе — утлы дулкын. Кояш — минем җанымның адашы. Ул үзе дулкыннар өстеннән йөгерә.

— Алайса, син минем кояшым бул, Рафилә! Мин йөзеңдә чагылмыйча яшәргә дә риза!

— Синең күзләреңдә кояш бар инде. Аларда ике кояш бар! Минем күзләремдә ничә кояш, Ришат?

Мине сөйгән кояш ике буламыни? Сине сөйгән кояш ике буламыни? Ә кояшны сөйгәннәр?.. Мин табыначак кояш әле тумагандыр да...

*1998*

## Әти

Беләгем буйлап сикерә-сикерә уч төпләренә төшкән чикерткә беравыкка туктап калды, аннан әче тавыш белән чәрелдәргә тотынды. Әтиемнең чалгы кайраган тавышы да баса алмый аны. Баш бармагыма кунган, әле мин исемен дә белми торган корт малае, күзен чекерәйтеп, каршысындагы сөялгә текәлгән. Мин, кылчыклы үлән белән арт ягыннан этеп, аны чикерткә туктаган җиргә тәгәрәтәм. Ул тагын кирегә менә, тагын, тагын...

Бу шаяру да туйдыра башлый, икесен дә берьюлы уч төбеннән сыпырып төшерәм дә зәп-зәңгәр күккә карап ятам. Менә шул күк йөзендә кинәттән генә эп-эре, кып-кызыл җиләкләр пәйда була. Аларны кирәксенмәгәндәй итенеп, борыннарымны җыерам.

— И-и-и, маңкуш! — ди миңа әтием, җәенке борынымда бер тамчы юешлек юклыкны белсә дә. — Маңкушым минем. Йә инде, кап, сиңа дип өздем ич!

Татлы сусыл җиләк белән бергә әтиемнең юан бармакларын да эләктермәкче булам, әмма алар тешләр арасына сыймый.

Беренче җиләкне мин бервакытта да үзем йотмыйм, иреннәрем очында кире әтигә сузам. Ә ул әнә, кызганмый-нитми, бөтен авызым белән бергә кабарга чамалап, бер-ике генә теше калган аңкауларын киерә. «Икегезгә бер авыз теш, шуны нишләтергә белмисез», — дияр иде әнием, яныбызда булса.

Без, бүлә-бүлә, тарткалаша-сыйлаша, җиләкләрне ашап бетерәбез, әтием кабат чалгысына үрелә.

Чаж-чож, чаж-чож... Бөтен болынны берүзе чабып бетерә ала ул. Тигез, киң аркасыннан эре-эре тир бөртекләре ага. Борын яфракларында да шундый ук тамчылар.

Чыйжт-пыйшт, чыйжт-пыйшт... Монысы бабай чалгысының бераз гына ялкаурак тавышы. Ул да тирләгән. Буй-буй күлмәген сорылатып, аның аркасыннан да су аккан.

Якында гына кибәннәр утыра. Иң зур кибәнне өч мәртәбә тыраклап әйләнеп чыгам да тагын әтием янына киләм.

— Әти, дим, әти, кара инде, кипкән печәннән сиңа мәтрүшкә табып алып килдем!

Әллә ишетми — борылып та карамый.

— Әти, бүген яңгыр явар микән?

— Яуса, сине болытка чөеп уйнармын! — ди әти, чапкан җиреннән туктап.

Ул мине биеккә-биеккә атып җибәрә. Кояшка аз гына тими каламдыр. Әни күрсә, коты очкан булыр иде, ярый әле, ул Казанда. Киткәндә, кояштан тәннәреңне пешермә, дип әйтеп калды.

Әтием белән бергә сусыл печән өстенә егылабыз.

— И-и-и, маңкуш!

— Алай әйтмә! — дип еласам да, барыбер тыңламаячак.

Әнинең иң акыллы кызына ул гел шулай дип дәшә. Әтинең нәкъ колак янында гына кеп-кечкенә миң кукраеп утыра. Туган чакта шуннан да зуррак җирем юк иде минем, кызым, дигәне бар әтинең.

— Кызым, кайткач, мин сине мунчада чабармын, яме! — ди әтием, инде ирен читләремне кытыклап.

Көненә өч тапкыр мунчага бара ул. Барган саен, мине дә ияртә. Чаж-чож итеп, печән чапкан кебек кенә, каен миллеге белән пешекләпме-пешекли. Аннан ләүкә өстенә утыртып куя.

— Елама, шунда гына утыр!

Минем тиктомалдан елаганым бармы?..

Әти башын тап-такыр итеп кырдырткан. Шул такыр башка чиләге белән салкын су бәргән саен, ни өчендер:

— Йә, ху-у-ш... — дип, эченнән бөтен һавасын кысып чыгара.

Биектән, ләүкә өстеннән, аны күзәтәм. Юан беләкләренә, йонлач аякларына бик ныклап карап торам мин аның.

Менә без, арып-талып, хәле киткән, яңгырга эләккән тавыклар шикелле, өйгә бал белән чәй эчәргә кайтабыз.

Ишектән керә-керешкә:

— Йә, хуш, — ди әтием соңгы тапкыр. — Мунча хөрмәтенә рәхмәт.

Әбием сарык бәрәнләткәндә имгәткән тәпиемнән сыпыра.

— Рәтләнә инде, кызым, рәтләнә. Үзе өч кенә яшьтә булса да, эшкә ярый бит ул, — ди. — Көтү яба, сарык бәрәнләтә, бакчага су сибә...

Соңгысын арттырыбрак җибәрә. Әтием шланг тотып уйнап йөргәндә, бакчага дигән суны миңа сибеп бетергәнлеген беләмени ул! Күлмәкләрем чыланганга, мине дә эшкә ярый башлаган дип куана.

— Кызыма балның тәмлерәген, майның калынрагын як, әбисе, — ди әтием, бөтенебез дә балны бер савыттан ашаганны күрмәгәндәй.

Мәтрүшкәле чәйдән аның борын яфраклары тагын да җәелгән, күзләре ялтырый, муенында — суы тамып торган сөлге.

Бабай гына берни дә сөйләшми. Сөйләшсә — әтием бетәчәк.

— Маладис, кызым, әтиең кебек иркә түгел син! — дисәме, гүпчим кәефе төшәчәк.

Бабай алай димәде. Көлеп карап-карап торды да:

— Әйдә, якланма! — дип кырт кисте.

Мине, мунчадан соң булганга, чип-чиста урынга, әти янына яткырдылар... Урынны кая гына җәйсәләр дә, әгәр ул янымда булмаса, күземне ачып, йокыга китмәскә тырышып ятам. Алай гына да җиңә алмасам, үкереп еларга ук тотынам. Бертуктаусыз:

— Йокламыйм, йокламыйм, йокламыйм! Әти, ярат, әти, ярат! — дип кычкырам.

— Ай, үтерә икән бу бала сезне, — ди әле көндез генә мактап туймаган әбием.

Миңа әти белән рәхәт шул. Аның җылы, йомшак аяк араларына кысылып, йокыга киткәнемне дә сизми калам.

Бүген таңда торсам — янда әти юк. Төшемдә аның иреннәремнән үпкәнен, битләремнән сыйпаганын, өстемә юрган япканын күргән идем, чын булган икән. Әбием белән бабам янында калдырып, каядыр, Казангамы китеп барган. Көн еладым, төн еладым да тынычландым. Инде караватымда беркемне акылдан яздырмый гына йокыга китә башладым.

— Бисмилла ир-рахман ир-рахим, — дип әйттерә миңа әби, яткан саен.

Үзем:

— Спокойной ночи! — дип өстим.

Әтием киткәч, чәчемне үрүче дә, миңа җиләкләр ашатучы да калмады. Көннәр буена капка төбендәге комлыкта күрше малайлары белән уйнап утырам. Шундый эчпошыргыч чакларда, уйламаганда-нитмәгәндә, Казаннан әни кайтып төште.

— Киен, кызым, киттек! — диде ул миңа, күзенә күренүемә. Һәркемнең йөзен хәвеф басты. Алай да, берничә көн йорт эшләрендә булышып, мине калдырырга ризалашып, йөзенә төс кермәгән килеш үзе генә китеп тә барды.

— И-и-и Ходаем, баланың әтисе генә табылса ярар иде, — диде әбием, әнисез калган өстәл кырына утырып самавырдан чәй агызганда.

Өйдә миңа игътибар бетте. Ашаталар-эчертәләр дә, түргә бикләнеп, кунакка кайткан туган-тумача белән ни хакындадыр бик озак сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Аларның сүзе беткәнне көтеп, каңгырып баскыч төбендә утырам. Коелган алмаларның да тәмен тапмыйм, көтү дә каршыламыйм, янымда бөтерелергә яраткан Амур белән генә уйнаштырам.

Әни өйдәгеләрне ничек аптыратып китеп барган булса, шулай ук кайтып та төште. Иң беренче эше итеп мине сүзсез генә кочаклап торды. Күгәргән күз төпләреннән ниндидер зур кайгы килгәнлеге аңлашыла иде. Әбиләрем белән түр якта сөйләшкәннән соң, ул тагын да ябыгыбрак калган, битләре тагын да батканрак кебек тоелды.

Энҗе апам, ашыга-ашыга, киемнәремне чемоданнарга тутыра башлады. Миңа карап көлми, елмаймый. Аның янәшәсендә — бүлмә уртасында басып торам. Инде әбием дә кочагына алып сөймәгән бу йорттан үземнең дә тизрәк китәсе килә башлады, күземә яшь бөялде.

Әни урта ишек яңагына сөялгән. Бабай, йортта урын тапмагандай, бакча тирәсендә йөри.

— Инде әтиең юк дип, безне онытма, — диде әби, мине кинәттән исенә төшергәндәй.

Юк? Ничек юк? Миңа җиләкләр җыеп ашаткан, мине суларда коендырган, китаплар укыган, җилкәләрендә йөрткән, әнием турында шундый матур шигырьләр язган әтием юкмы? Үлгәнме ул? Ник беркем миңа ул хакта берни сөйләми?

Һаман да ишеккә терәлгән әни мышык-мышык елавында. Мине алырга әни белән кайткан Мәрьям апамның күзләрендә дә яшь. Үлгән булса, ник әби-бабай еламый? Ник Энҗе апам, әтиемнең апасы еламый? Әкрен генә Мәрьям апаның итәгеннән тартам.

— Минем әти юкмыни?!

Ул, нәрсәдер әйтәсе урынга, мине чытырдатып күкрәгенә кыса.

— Кайткач сөйләрмен... — ди әни, акылын җыйнабрак торгандай.

Барыбыз да урамга чыгабыз. Анда, капка төбендә, өр-яңа «Җигули».

— Утыра тор, — ди әнием йомшак кына. Мин көтәм. Әби-бабамның кочканын, мактау сүзләре әйткәнен көтәм. Беркем дә яныма килми.

— Әтиеңне онытма, үскәч, карарсың, — ди бабам бераздан. Димәк, ул исән...

— Ә кайда соң ул? — дип сорыйм ялганлый белмәүче әнидән.

— Китте... — дип җавап бирә дә, иелеп, мине җирдән ала.

— Кайтыр, кайтыр, синнән башка кемгә кирәк соң ул? Эчәр-эчәр, йөрер-йөрер дә, беркемгә кирәге калмагач, кире әйләнеп кайтыр, — дип өсти бабам.

— Кайтмасын да! — Әни нигәдер бабама үпкәле караш ташлый. — Минем дә түземлекнең чиге юк түгел! Бер баланы гына үстерермен әле! Абыем, туганнарым, әнием бар. Үзем кешедән кимме?!

Һе... Әти, мине үстермәс өчен, берәр җиргә китте микән әллә? Җиләкләр җыеп ашаткан булды. Мине яратмаган микәнни? Булмас. Әби дә, битләреңнән сыйпады, өстеңә юрган япты, дип тора. Ярата бит инде ул шулай булгач!

— Сезне ачулану түгел... Күрешеп яши алмасак, рәнҗеп калмагыз, риза-бәхил булыгыз... — Әни хәлсезләнә, мине җиргә төшерә.

Аның тәне дерелдәвен йомшак ак танкеткаларым астында лепердәгән җирдән дә тоеп була.

— Елама, әнием, мин сине яратам, — дим, аның аякларына сыпырынып.

— Әтиеңне дә ярат! — дип куя бабай, нык итеп.

— Елама инде, мин сине яратам! — дим аның саен, бабамның ачуын китереп.

Без кузгалабыз. Беркем яныма килеп хушлашмый. Машина тәрәзәсеннән карап урамны узганда, үземнең дә нигәдер елыйсы килә дә, кысып-кысып, әниемнең муенын кочакларга, иреннәреннән үбәргә тотынам.

— Мин сине яратам, әни, яратам!

— Беләм, кызым, беләм, — ди ул, үзе дә яшьләрен тыя алмыйча.

Әтине дә ярату сүзләрен әйтүдән нәрсәдер тыеп тора — мин моны үзем дә аңламыйм. Инде башка беркемем дә калмаган шикелле, әниемнең яшьтән чыланып беткән күлмәгенә елышам...

* * *

Казанны мин сагынмаган да идем. Бакчаны, андагы апаларны да күрәсем килми. Җәйге эсседән кызган бүлмәдә күзгә йокы керми.

Җитмәсә, әни дә гел уйда. Аз дәшә, көлми. Әтинең башка кешеләр белән торасын аңладым инде. Бик иртә сөйләшергә өйрәнгәч, мине беркем бала санамый. Ике-өч сүз әйтәләр дә бетә.

— Әтиең китте. Аны башка сорама. Ул бездә тормаячак. Икенче хатыны бар.

Менә шушы ишеткәннәр минем телемнән әти дигәнне сызды да ташлады. Әнигә артык сорау бирү урынсыз иде. Ул:

— Өйдә эч пошырып утырмыйк әле, — дип, мине паркка алып китте.

Без, мин урамда ныклап йөри башлагач, анда әтием белән Беренче май бәйрәмендә булган идек. Кабарткан шарлар алып биргән иде ул миңа. Салкыннан, җилдән юка, кызыл пәлтәмдә бик каты туңдым, күтәр дә күтәр, дип үрсәләндем. Әтинең яшел курткасына сыенып, беләгендә йөрүне хуп күрдем.

— Бер яшьтән артык бит инде сиңа, авыз тутырып сөйләшәсең, үзең гел әтиеңә күтәртәсең! — дип орышкалаган булды әни, шуңа бик тә сөенгән шикелле күренсә дә.

Бу юлы без көлке бүлмәсенә дә кермәдек, атынгычларга да бармадык. Биеклектән курыккан, көлүдән бизеп калган әнием аларны артык санады. Бөтен батырлыгын җыеп, аю янында фотога төште. Чын аюга охшаса да, ул да нигәдер сөйләшми иде.

— И юләр, үзеңә өч яшьтән артык, кипкән аю икәнлеген дә аңламыйсың мәллә? — дип сорады әни, күзләрен шарлатып.

Менә шулай. Син зур кыз, диләр дә торалар миңа. Минем белән яшьтәш күрше малайлары әле сөйләшә дә белми бит. Аларны нәрсә дип орышалар икән? Ә мин инде хәрефләр дә таныйм. Кушып, матур итеп укый гына алмыйм.

— Әбиең оста синең, өйрәтер әле, — ди әни. Әйе шул, мин тиздән аларга кайтып китәсе.

Яхшы итеп укырга, язарга чынлап та бик тиз өйрәндем. Бик тә, бик тә хат язасы, әтиемнең хәлен сорыйсы килде шул.

— Икенче хәрефне танымый торып, алдагысын әйтүдән туктамагыз, — ди әниемнең әнисе — минем икенче әбием, Нияз белән миңа әлифба тоттырганда.

Шуңа күрә һәрбер укыган сүз «әт-т-т-ти» кебегрәк килеп чыга.

— Әби, әти кире кайтыр микән? — Укудан туктавыма ачуланмаса да, әби җавап бирми. Алайса, кайта инде. Көннән-көн теләбрәк укый башлыйм, хатлар язып маташам. Казанга кайткач, мин аны болайрак итеп яңадан күчерәчәкмен:

«Әти!

Син киттең. Мин дә, әни дә елап калдык. Җиләкләр җыеп ашаткан иең бит. Яратмаган иеңмени? Мин сине яратам бит.

Кайтмасаң, дәү үскәч, карамам да әле. Тик син кайтырсың. Күп акчалар алып кайтырсың. Бүләкләр салырга зур сумкаң бармы? Булмаса, ал. Безнең телевизор да, кресло да, тагын әллә нәрсәләр дә юк бит әле. Алар сумкага сыя микән? Зур булса... Андый зур сумка булмаса, нишләрсең микән инде?

Әти, син миңа матур күлмәкләр алгансыңдыр да инде, име? Кәнфитләр турында язып тормыйм. Аларны да алгансыңдыр. Әти, озак көттермә. Таңсу».

Түлке мин әле хаталы язам икән. Әни шулай ди. Әтиеңнән хаталы язып көлдертмә, дигән була. Әле күрше малайлары сөйләшә дә белми!

Хатны салдык. Ай көттем, икене. Әти килмәде дә килмәде. Инде хатасызрак та яза башладым. Йомыш белән килгән әтинең дус үзбәге артыннан, әнигә күрсәтмичә генә, икенчесен җибәрдем.

«Әти!

Син өйләнгәнсең икән. Мин синең хатыныңны күрдем. Ул минем әни кебек матур түгел. Мин сиңа аның рәсемен ясап җибәрәм. Бик усал дип әйтәләр аны. Менә мине елатып, бездән киттең, ул сине кыйнап бетерер әле. Дәү үскәч, елап килерсең, мин сине карамам, әнине генә карармын. Ул миңа кәнфитләр дә, күлмәкләр дә ала. Ярата да. Син мине яратмагансың.

Җавап яз. Таңсу».

Әти хат язмады да язмады. Инде минекеләрне әни дә илтми башлады. Аңа кадәр, ачуымны китереп, орышасы килгәндә, әтиеңә охшагансың, ди. Киемемне ертсам да, өстәлгә чәй түксәм дә, аз сөйләшсәм дә, телевизор карап кына ятасым килсә дә:

— Бу чаклы әтиең булырсың икән, борыныңа кадәр фамильни... — дип теңкәгә тия.

Ә бит килгән бөтен кеше, әнисенә охшаган — акыллы, дип шакката. Беркөнне урамнан, әтиләр турысыннан узган чакта, әнидән арткарак калып:

— Ичмаса, ташы да күренми бит аның, тәрәзәләренә алып атарга, үзләре безнекен ваткан кебек! — дигән идем, әнием кычкырып көлеп җибәрде. Инде ул аларга бөтенләй ачулы түгел. Менә акыллы бу хатын-кыз диген син! Искә дә алмый, минем белән чырык-чырык килеп кенә яши бирә. Әйтерсең, ул булмаган да!

Әле дә:

— Син аны оныт, тәрәзәләре ватылса, безгә килә бит ул яшәргә, — диде дә бетерде. Алайса, әйбәт бит инде!

Тик үзем дә нигәдер:

— Юк, килмәсен, ватмыйбыз алайса, — дигән булдым, кулымдагы кечкенә генә чуерташ кисәген дә читкә бәреп.

Әнием туктады. Миңа текәлеп торды да:

— Кайтсынмы соң? — дип әйтә куйды.

— Теләсә кемгә кияүгә чык, тик ул гына кайтмасын! — дип кычкырдым мин, үз-үземне белештермичә. — Көн саен елатканын, өйдә күренмәгәнен дә оныттыңмыни?!

— Җиләкләр ашата иде, дисең бит...

— Аны кем дә ашата. Аны мин үзем дә җыям! Ул китмәсә, карарга телевизор да булмый, үзең өстеңә яңа күлмәк тә кия алмый идең бит әле!

— Мине ярата, дигәнеңне хәтерлә.

— Яратса, китәмени ул!

— Әтисез яшәү кыен бит...

— Бер дә кыен түгел. Шушындый акыллы кызың барда!

Шулай дидем дә диюен... Һәм шул көннән соң әни өчен әти эзләргә тотындым. Урамда эндәшкән иратларга да:

— Без ирләр белән сөйләшмибез! — дип, әнигә: — Эндәшмә әле шуларга! — дип әйтүдән туктадым.

Беренче булып безгә Сережа абый килеп керде. Мин аны бакчабыздагы йортны төзергә булышкан чагыннан ук беләм. Ул — татарча, мин русча сөйләшмибез. Килгән саен, кулында — кучтәнәч!

— Сережаның күзләре айныкына охшаган, — ди әни дә.

Мин бит аның нинди күзләрне яратканын беләм! Кайсы җире әти булмаслык?! Ныклы карарга килеп, китәргә дип кузгалган Сережа абыйның ишек тоткасындагы кулына барып ябыштым.

— Әти бул миңа! Китмә!

Әллә ялгыш аңлады микән? Агарды, күгәрде, телләре көрмәкләнде. Ни дә булса әйтмәде, әнигә генә күзләренә тирән мәгънәләр чыгарып карап торды.

— Ул яңадан килә әле, — диде әнием. Үзенең Сережа абыйга:

— Прости ее... — дип әйтүе булды, күзеннән чыккан бер тамчы яшь бите буйлап тәгәрәп тә китте. Күзләре тулган айга тагын да ныграк охшап калган Сережа абый бик озак безнең өйдә күренмәде.

— Кызым, менә хәзер аңа килмәскә куштым бит инде, нигә алай эшләдең, ул татар да түгел әле, — диде әни, мин һаман-һаман аны сорап йөдәткәч. — Аның гаиләсе, синең кебек матур кызы бар.

Әнинең мин ошаткан бөтен танышлары нигәдер өйләнгән булып чыктылар. Өйләнмәгәннәрен үзем өнәмәдем.

Әнинең:

— Юньле ир үз хатыны белән тора, — дигәне белән килешеп, әти сораудан да туктадым.

* * *

...Мин дә мәктәпкә йөрер яшькә җиттем. Хат арты хат язып, әтине көтүдән дә арыдым. Иптәш кызымның әнисен әтисенең кыйнап күгәртеп бетергәнлеген күргәч, өчәү тору теләге дә бетте.

— Кызым, әтиле буласың киләме һаман да? — дип сорады әни үзе бервакыт, кунакка килгән Нәфкать абый белән телевизор карап утырганда.

— Кем? — дип сорасы урынга, мин:

— Юк! — дип, бер сүз белән кырт кистем. Башыма ни өчендер «Нәфкать абый, чыннан да, әллә әнине ярата микән?» дигән уй килеп, бармагымны аның борын очына ук китереп төрттем:

— Только не за тебя! Только не за тебя!

— Алайса кемгә? — дип сорады әни, тыныч булырга тырышып.

— Беркемгә дә! Менә мин, дәү үскәч, сине ялгыз калдырмас өчен, кияүгә чыкмаячакмын. Син дә чыкма! Акча алып кайтмый, эчә, чит апалар янына йөри торган, мине елатып китеп баручы әтиләр кирәкми миңа!

— Бу абыең шундыйга охшаганмыни?

— Аның ниндилеге әтинеке кебек оп-озын борынына ук язылган, күзенә, теленә чыккан. Гел, сине яратам, дип сөйләнеп утырса да, ышанмыйм мин аңа! Әти дә ярата иде бит! Ул турыда йөз, мең тапкыр әйткәндер! Алайса ник китте? Кемгә китте? Иптәш малае хатынынамы? Сине, мине белмәгән кешегә дә түгел, ичмасам!

Минем әле сөйләргә сүз бетмәгән булса да, Нәфкать абый түзмәде, кәнәфидән сикереп торды да әле генә сөйләп утырган төче сүзләрен дә онытып:

— Баланы син өйрәтеп куйган! — дип, әнигә җикерде. — Икенче сыйныф кызы шулай сөйләшәме? Илле яшьлек апалар акылы буламы анда? Әле тора башлаганчы шулай, аннан нәрсәләр әйтмәс ул миңа!

Нәфкать абыйның кемлеге аңлашылды. Әнием:

— Әле сиңа чыгарга уйлаган кеше дә юк, тик кенә утырчы, — дип караса да, өзмәде дә куймады, мине сүкте.

Инде дәшми генә бик озак тыңлап торганнан соң, әни дә чыдамады:

— Ул бит — дөнья хәсрәтендә үскән бала, ник әйтмәсен? Минем ирем дә, иптәшем дә, кызым да, яклаучым да бит ул, — дип, мин чынлыкта бөтенләй белмәгән ир-атны, куалый-куалый, ишеккә озатты.

— Килмә бүтән!

Ишек шапылдап ябылды. Без тып-тын гына, бер-беребезгә карашып, хәвефле көннән хәл алдык. Әнием сүкмәде, тиргәмәде. Ялгызымны калдырып, урамда йөреп кергәннән соң, диванга ятып, сулкылдый-сулкылдый елады.

— Берүзең каласың бит, кызым, — диде ул аннан, мине үзенә чакырып алып.

— Булсын!

— Мин дә синең белән гомер буе яшәмәм!

— Әти өйдә торса, картаеп беткән идең бит инде! Ә болай, яшәрбез әле, әни!

— Үзең, энекәшем дә юк, дисең...

— Әнә Нияз...

— Сез бит бергә картаерсыз, кызым, аның да хатыны булыр, үз әти-әнисе бар.

— Әле аңарчы...

— Алайса... син кемгә дә риза түгел...

— Риза булырлык кешесе бармыни аның, әни?!

— Әтиле буласың да килмиме?

— Юк!

— Инде беркем белән дә аралашмаска дамы?

— Аралаш.

Китегез, дип кусак та, Нәфкать абый да, башкалар да, әнине сорап, кат-кат килде.

— Миңа әти кирәкми, без икәү генә яшәячәкбез, — ди идем мин, ул хакта сүз чыкканда, әнигә ике үйларга урын да калдырмыйча. — И-и-и, кызым, син, үскәч, башкача сөйләрсең әле, — дип әйтә калса, кайвакыт кына йомшап:

— Ну, чык алайса, әнә Камил абыйга, әнә Вакыйф абыйга, әнә... — дип тезә идем, барысының да өйләнгән кешеләр икәнлеген белсәм дә.

Әни әлеге сүзләремә үпкәләгәндерме, юкмы — аңламадым. Инде әнисез дә каласым килмәгәнне аңлагандыр дип уйлыйм. Әтине, хат язып, өйгә кайтару өчен укырга өйрәнгәнемне, шаккатырып, мәктәпкә китерү өчен, бишлеләр генә алганымны, кабат яраттыру өчен рәсемнәр җибәрүем турында үзем дә сөйләмәдем мин аңа.

Әти килмәде дә килмәде. Ул минем ничек укыганны түгел, ничек үскәнне дә белмәде бугай. Эзләп барсам, күтәреп алмады, урамда очрасам, сәлам бирмәде.

— Аның елыйсы килә, ул шуңа дәшми, — дип, аны үз каршымда акларга иярләндем.

Әни белән генә дә рәхәт иде инде миңа. Гел көлешеп, сөешеп кенә торабыз. Өй тулы кунак. Ни теләсәм, шуны киям, шуны ашыйм. Әмма мин әниемнән бервакытта да берни сорамадым. Теләгән әйберләрем әтиемнең төшенә керер дә аларны күтәреп килеп тә җитәр кебек тоелды.

Догалар укып чакырдым. Шигырьләр язып чакырдым. Шул теләгән әйберләр арасында ул үзе дә бар иде бит! Әтием ишетмәде дә, килмәде дә. Үзем дә әниемә, аңа һич исем китмәгән шикелле:

— Күрәсем дә килми шуны! — дип әйтә башладым. — Мине яратмаган икән ул!

* * *

Аны бик сагынган чакларымда Язучылар йортындагы Яңа ел кичәсен искә төшереп тынычлана торганга әйләндем. Күзләремне йомам да әтием өчен өйрәнгән биюне биегәндә, хатынын, балаларын җитәкләп урыныннан торып киткән сурәтен торгызам. Бәйрәмнән кайтканда каршы очраган хатынының, теш арасыннан гына:

— Фу! — дип, җирәнгеч аваз чыгарганын хәтергә алам.

Инде мин шул ямьсез йорттагы бәйрәмнәргә дә йөрмим. Йомыш төшеп, әниемә ияреп барганда да, этләр белән уйнап, ишегалдында торып калам.

Без иске альбомдагы рәсемнәрне карамыйбыз. Яңаларында — әтием сурәте юк. Газетадагы фотолардан, телевизор экраннарыннан аның йөзен эзлим. Әтиемә охшаш кешеләрне күргәндә, ялгышмавымны белү өчен, әнидән:

— Әтигә охшаганмы? — дип сорыйм.

Ә ул көннән-көн үзгәрә. Электәге матур әтием күзгә күренеп югала, ямьсезләнә. Мин дә үзгәрәмдер. Әнием белән яныннан узып киткәндә дә, ул мине танымый, күрми.

Кайвакыт ул, балаларын җитәкләп, йортыбыз янындагы бушлыкларга ял итәргә чыга. Егылсалар — киемнәрен какканын, еласалар — яшьләрен сөрткәнен карап-карап торам да, син аларны булса да чынлап яратасыңмы, дип кычкырасым килә. Син кемне дә булса яратасыңмы, әти?! Син, һич югы, үзеңне хөрмәт итәсеңме, әти?! Минә синең кебек әтиләр турында ни уйлыйсың син, әти?!

— Мин аны оныттым, бәхетле яшәсен, — дип, әни дә ешрак әйтә башлады. Шундый-шундый яраткан әнинең оныткалыгына гына ышанасы килми. Елап җибәрмәс өчен, андый чакта, аш бүлмәсенә чыгып, шигырь язып утырырга гадәтләндем. Әнине ярату, әтигә карата рәнҗеш баскан ул шигырьләрне беркемгә күрсәтмим, чүп чиләгенә салам да тынычланам. Ул чиләктә әни шигырьләре дә бар...

Тынычланам, әмма әтинең, әнинең бер-берсен яратмаганлыгына ышанасым килми! Мин моңа ышанмыйм! Бер, ун, йөз тапкыр әйтсәләр дә ышанмыйм! Икебезне ике җилкәсенә утыртып, урамнар әйләндерә иде бит ул! Әниемә бәлешләр пешереп ашата, чәчәкләр бүләк итә иде! Чәчләремне тигез үремнәргә үрә иде...

Чаж-чож печән чабуыннан туктап, миңа җиләкләр җыя иде. Аның борынынннан аккан тирләренә иреннәремне куясым, аркасын каен миллеге белән чабасым, аңа:

— Әти! — дип дәшәсем килә. Сәлам бирмәсә дә, бүләкләр алмаса да, аның мине яратмаганлыгына ышанмыйм. Йортыбызда, әле бергә яшәгәндә, мыскыллап, көлеп сөйләгән апалардан хатлар сакланса да, шуларның берсе белән гомер итсә дә, аларны, аны яратканлыгына ышанмыйм!

Минә тагын әнинең аның турында сөйлә әле дип теңкәсен корытам, чөнки аның сурәтенең күңелдән бөтенләй юылып бетүеннән куркам.

Сөйлә генә, мин аны барыбер яратмыйм бит инде, — дигән булам.

Әни, ярат та, яратма да, дими. Минем барлыкны сылтау итеп, беркемгә чыкмаса да, мин аны үземчә — әтине ярatkанга дип юрыйм.

* * *

Әни әйткәнен эшләде. Әгәр бишлегә генә укысаң, әбиеңнәргә алып кайтырмын, дигән иде, — менә без, озын юл узып, машинабызда аларның йорт каршысына килеп туктадык.

Таныш ишегалларын, бөтенләй картаймаган әби белән бабайны күреп, ни әйтергә дә белмәдем.

— Әтиеңә охшасаң, бишле генә алырсың шул, — диде бабам, әниемнең аннан да яхшырак укыганлыгын белмәгәндәй.

— Әтиеңә охшасаң, аз сөйләшерсең, озын буйлы булырсың, — диде әбием, эндәшә алмый торганымны аңламаганга.

Бу йорт миңа чит тә, якын да иде.

— Кал, җәйне бездә уздыр, — диде әби.

— Китүең яхшырак, атаңның икенче хатыны сезне бер дә яратмый, — диде бабам.

— Син дә — безнең кыз бит, — диде әби. — Онытма! Менә безне картаймыш көнебездә онытма!

— Бүләкләр бирми, дип әйтмә, үскәч, әтиеңне карый күр! — диде бабам.

— Син кәнфит ашар яшьтән чыккан инде! — диде әбием.

— Аларның үз балалары... — дип, аска карап кына сузды бабам.

— Аның торыр урыны да, карар кешесе дә, ашасы килгән әйберсе дә — барысы да бар, — диде бу сүзләрне өнәп бетермәгән әни. — Без сезне сагынганга гына кайттык...

Беркем дә, Таңсуның әтисе юк, дип, аңа каршы төшмәде.

* * *

Яңадан әйләнеп кайтмас кебек киттем мин бабамнар йортыннан. Әтисез, туганнарсыз икәнлегемне чынлап торып аңлау өчен, шушы кайту да бик җиткән иде.

Җиләкле болыннар, кибәнле бакча артлары, сау булыгыз! Инде монда мин яраткан Амур исемле көчек тә, аягымны имгәткән сарык та, куе сөт эчергән мүкләк сыер да юк. Алар урынында — башкалар. Әбием дә, бабам да үзгәргән.

Миңа кул болгаган урманнарда сусыл җир җиләкләре өзгән эти юк! Мине зәңгәр күкләргә чөйгән эти юк!

Баш астыма кофтамны салып, машина утыргычына яттым. Уч төбемдә сикеренгән чикерткә! Син дә юк икәнсең бит! Әти чалгысының тавышы да синең җырыңны баса алмый иде. Нәзек аякларың инде аның чалгысыннан киселмәсен... Хуш, син дә сау бул, Ык буйларының нәзберек, мине яраткан чикерткәсе!

## Эчтәлек

**Хикәяләр**

Адашкан җан....5
Айлы күлдәвекләр....9
Умырзая....17
Чәчкә абый....22
Көзге каеннар....27
Кәҗә ите....33
Үч....36
Нигә елады?....41
Үзеңнеке — үзеңә....44
Репетиция....49
Бер микъдар былбыл....53
Чикерткә....64
Чегән кызы....70
Җил бизәге....76
Баш очында болытлар....80
Сорый белсәң, Айдан сора....84
Сары шарф....87
Чәчәктә кайткан төн....90
Судан тапкан йөземнәр....98
Аккош җыры....104
Ерактагы офыклар....109
Әлифба....113
Соңлап аткан мылтык....117
Аромотерапия....123

**Кыйссалар**

Тауның башын болыт кисә....................................................................................127
Югалту ачысы..........................................................................................................134
Елан читлеге...........................................................................................................146
Дагалы дулкыннар..................................................................................................159
Әти ..........................................................................................................................177

Литературно-художественное издание

***Рахман*** *Рифа*

*(**Харрасова** Рифа Фатхрахмановна)*

**Лунные лужайки**

Рассказы и повести

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Рахман*** *Рифә*

*(**Харрасова** Рифә Фатхрахмановна)*

**Айлы күлдәвекләр**

Хикәяләр һәм кыйссалар

Мөхәррире *В.Р.Шәрипова*
Рәссамы *А.Р.Таһирова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.07.2006. Форматы 84×108 $_1/_{32}$. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,08 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 11,34. Нәшер-хисап табагы 11,13 + форз. 0,36.
Тиражы 2000 д. Заказ 3-497.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.